# Фәнни Татарстан

ТАТАРСТАН ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
Г. ИБРАҺИМОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

2023 2 (38)

ISSN 2499-9741
КАЗАН

***Журнал «2014–2022 елларга Татарстан Республикасында ТР дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү», «2023–2030 елларга Татарстан Республикасында ТР дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программалары кысаларында 2014 елдан кварталга бер сан нәшер ителә***

*Массакүләм мәгълүмат чарасын Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт тарафыннан регистрацияләү турындагы таныклык ПИ № ФС77-65242 01.04.2016*

► **ЖУРНАЛНЫ ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ**
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ

► **ИДАРӘ:**
МИҢНУЛЛИН К.М., филология фәннәре докторы, профессор, идарә җитәкчесе (Казан)
АЛИШИНА Х.Ч., филология фәннәре докторы, профессор (Төмән)
АРСЛАНОВ М.Г., сәнгать фәннәре докторы, профессор (Казан)
БАҺАВЕТДИНОВ Ф.Н., хокук фәннәре докторы, профессор (Казан)
ВӘЛИЕВ Р.И., тарих фәннәре кандидаты, Татарстанның халык шагыйре (Казан)
ГЫЙЛӘҖЕВ И.А., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ЗАҺИДУЛЛИНА Д.Ф., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
ЗӘКИЕВ М.З., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
ҖАМАЛЕТДИНОВ Р.Р., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
КЕРИМОВ И.А., филология фәннәре докторы, профессор (Симферополь)
МИҢНЕГУЛОВ Х.Й., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
МӨХӘММӘТШИН Р.М., сәяси фәннәр докторы, профессор (Казан)
НАСИПОВ И.С., филология фәннәре докторы, профессор (Уфа)
ӨНӘР МОСТАФА, фән докторы, профессор (Измир)
САЛӘХОВ М.Х., физика-математика фәннәре докторы, профессор, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты (Казан)
САЛИХОВ Р.Р., тарих фәннәре докторы (Казан)
СИБГАТУЛЛИНА Ә.Т., филология фәннәре докторы, профессор (Мәскәү)
СӨЛӘЙМАНОВ Җ.Ш., техник фәннәр докторы, профессор (Казан)
ТӘСИН ҖӘМИЛ, Бабеш-Больяй университетының Тюркология һәм Үзәк Азияне өйрәнү институты директоры (Клуж-Напока, Румыния)
ТИМЕРХАНОВ А.Ә., филология фәннәре докторы (Казан)
ХУҖИН Ф.Ш., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШӘЙДУЛЛИН Р.В., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШАМИЛ-ОГЛЫ ЮЛАЙ, тарих фәннәре докторы, профессор (Астана)

► **БАШ РЕДАКТОР**
Ким Мөгаллим улы МИҢНУЛЛИН

► **БАШ РЕДАКТОР УРЫНБАСАРЛАРЫ:**
МӨХӘММӘТҖАНОВА Л.Х., ШӘРИПОВА А.С. (җаваплы секретарь)

► **РЕДАКТОРЛАР:**
ЗАҺИДУЛЛИН И.К. (тарих), СОЛТАНОВА Р.Р. (сәнгать), МИРХӘЕВ Р.Ф. (тел белеме), ГАРИПОВА Л.Ш. (әдәбият), ЯМАЛТДИНОВ И.И. (фольклор)

► **ЧЫГАРЫЛЫШ РЕДАКТОРЫ:**
ГАЛИУЛЛИНА Д.Р.

► **ГАМӘЛИ ХЕЗМӘТКӘРЛӘР:**
ШӘРИФУЛЛИНА Л.Г., АБДУЛЛИНА Н.Т., СӘЛАХОВА Ә.Ф., ЧУГУНОВ А.С.

## БУ САНДА

### ТЕЛ БЕЛЕМЕ

*Каксин А.Д.* Хакас телендә тартым категориясе һәм аны белдерү формалары турында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .7
*Гыйләҗетдинова Г.Х.* «Хожение купца Федота Котова в Персию» әсәрендә шәркый чыгышлы лексика . . . . . . . . . .16
*Хәбибуллина Л.Г.* Татар телендә *-ып/-еп, -п* һәм *-гач/-гәч, -кач/-кәч* кушымчалы хәл фигыль белән белдерелгән семантик-синтаксик мөнәсәбәтләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .22
*Вәлиева М.З.* XVII–XVIII гасыр иске татар язма истәлекләрендә туганлык терминнары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .29

### ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ

*Хасавнех А.Ә.* Мөхәммәдзакир Камалов әл-Чиставиның тәрҗемәи хәле турында билгесез автор әсәре . . . . . . . . . . . .41
*Миңнуллина Ф.Х.* Сугыш чоры татар драматургиясендә заман һәм герой . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .51

### ХАЛЫК ИҖАТЫ

*Мөхәммәтҗанова Л.Х.* Дастани образга ачыклык – тарихи чыганаклар аша: Чура Нарык улының Казан ханлыгы тарихындагы эшчәнлегенә экскурс . . . . . . . . . . . . . . . . . . .60
*Хөсәенова Г.Р., Шарапова И.Р.* Башкорт чичәнлек сәнгате һәм борынгы кобайырлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .80
*Дәүләтшина Л.Х., Фәхриева Л.М.* Җен турындагы ышануларның татар халкының бүгенге көн мифологик күзаллауларында чагылышы. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .90

### ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕ

*Расулов А.Н., Насретдинова Д.М.* Татар хатын-кызларының Төркестанда агитация-пропаганда эшендә катнашуы (1917–1920 еллар башы) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .98
*Байбулатова Л.Ф.* Урта гасырлар төрки кулъязмаларында «татар» атамасы *(«Тәварих-е гөзидә Носрәт-намә» әсәре буенча)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 106

### СӘНГАТЬ

*Галимова Э.М.* Оренбург татарларының бүгенге заман халыкчан инструменталь сәнгате үзенчәлекләре . . . . . . . . . . . . . . . . 111

### МИЛЛИ МӘГАРИФ

*Гыйләҗева Л.Г., Һадиева Г.В.* Яңартылган дәүләт белем бирү стандарты таләбе буларак эмоциональ интеллект . . . . . . . . 116

## ФӘННИ ЯДКЯРЛӘР

Фатих Әмирханның «Әлислах» газетасында басылган баш мәкаләләреннән . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 122
*Алпаров Г.* Харитонов хәрефләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 130

## ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ

*Йосыпов Ф.Й.* В.В. Радловның Казан чоры фәнни, педагогик эшчәнлеге *(дәвамы)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 135
*Нәбиуллина Г.Ә., Кириллова З.Н.* Флера Сафиуллина: фәнгә багышланган гомер
*(тел галиме Ф.С. Сафиуллинаның тууына 85 ел тулу уңаеннан)* . 142
*Каюмова Г.И.* Олы сәхнә йолдызы
*(Фатыйма Камалованың тууына 120 ел тулу уңаеннан)* . . . . . 148

## ЯҢА КИТАПЛАР

*Габидуллина Ф.И.* Әдәбият фәненә җитди өлеш
*(Ә.М. Закирҗановның «Туфан Миңнуллин драматургиясе» китабына бәяләмә)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 156
*Хәмидуллин С.Р.* А.М. Гайнетдиновның «Казанның Яңа татар бистәсе зираты эпиграфик истәлекләре» китабына рецензия . . . 163
*Герасимова Н.В.* «Виктор Фёдоров. Монументальное искусство, живопись, графика. К 80-летию со дня рождения»
китабына рецензия . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 166

## ФӘННИ-ИҖТИМАГЫЙ ТОРМЫШЫБЫЗДАН

**В НОМЕРЕ**


**ЯЗЫКОЗНАНИЕ**

*Каксин А.Д.* К вопросу о категории притяжательности и формах её выражения в хакасском языке . . . . . . . . . . . . . . .7

*Гилазетдинова Г.Х.* Лексика восточного происхождения в произведении «Хожение купца Федота Котова в Персию» . . . .16

*Хабибуллина Л.Г.* Семантико-синтаксические отношения, выражаемые деепричастиями с окончаниями *-ып/-еп, -п* һәм *-гач/-гәч, -кач/-кәч* в татарском языке . . . . . . . . . . . . . . . .22

*Валиева М.З.* Термины родства в старотатарских письменных источниках XVII–XVIII веков . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .29

**ЛИТЕРАТУРОВЕДЕНИЕ**

*Хасавнех А.А.* Произведение неизвестного автора о биографии Мухаммед-Закира аль-Чистави (Камалова) . . . . . . . . . . . . . .41

*Миннуллина Ф.Х.* Время и герой в татарской драматургии военного периода . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .51

**НАРОДНОЕ ТВОРЧЕСТВО**

*Мухаметзянова Л.Х.* Раскрытие образа героя дастана через исторические источники: экскурс в деятельность Чуры Нарыкова в истории Казанского ханства. . . . . . . . . . . .60

*Хусаинова Г.Р., Шарапова И.Р.* Башкирское сказительное искусство и древние кубаиры . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .80

*Давлетшина Л.Х., Фахриева Л.М.* Современные мифологические представления татар о персонаже нечистой силы *җен* . . . . . . .90

**СТРАНИЦЫ ИСТОРИИ**

*Расулов А.Н., Насретдинова Д.М.* Участие татарских женщин в агитационно-пропагандистских работе в Туркестане (1917 – начало 1920-х гг.) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .98

*Байбулатова Л.Ф.* Употребление термина «татар» в средневековых рукописях *(на примере сочинения «Таварих-е гузида Нусрат-наме»)*. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 106

**ИСКУССТВО**

*Галимова Э.М.* Особенности современного народного инструментального искусства оренбургских татар . . . . . . . . 111

**НАЦИОНАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ**

*Гилязова Л.Г., Хадиева Г.В.* Эмоциональный интеллект как требование обновленного ФГОС ООО . . . . . . . . . . . . . 116

## НАУЧНОЕ НАСЛЕДИЕ


Вводные статьи Фатиха Амирхана в газете «Аль-ислах» . . . . . 122

*Алпаров Г.* Буквы Харитонова . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 130


## ПЕРСОНАЛИИ


*Юсупов Ф.Ю.* Казанский период научной, педагогической деятельности В.В. Радлова *(продолжение)* . . . . . . . . . . . . . 135

*Набиуллина Г.А., Кириллова З.Н.* Флера Сафиуллина: жизнь, посвященная науке *(к 85-летию языковеда Ф.С. Сафиуллиной)* . . . . . . . . . . . 142

*Каюмова Г.И.* Звезда большой сцены *(в связи со 120-летием со дня рождения Фатимы Камаловой)*. . 148


## НОВЫЕ КНИГИ


*Габидуллина Ф.И.* Значительный вклад в литературоведение *(рецензия на книгу А.М. Закирзянова «Туфан Миңнуллин драматургиясе»)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 156

*Хамидуллин С.Р.* Рецензия на книгу А.М. Гайнутдинова «Казанның Яңа татар бистәсе зираты эпиграфик истәлекләре» . 163

*Герасимова Н.В.* Рецензия на книгу «Виктор Фёдоров. Монументальное искусство, живопись, графика. К 80-летию со дня рождения» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 166


## НАУЧНАЯ ЖИЗНЬ

УДК 811.512.153

***А.Д. Каксин***

# ХАКАС ТЕЛЕНДӘ ТАРТЫМ КАТЕГОРИЯСЕ ҺӘМ АНЫ БЕЛДЕРҮ ФОРМАЛАРЫ ТУРЫНДА

В статье освещаются вопросы семантики и формального выражения категории притяжательности в тюркских языках (на примере хакасского языка). Специальные аффиксы признаются основными выразителями грамматического значения принадлежности. Рассматриваются также другие средства формального выражения разных оттенков притяжательности: сочетания типа *минiң ипчiм* ‘моя жена’, изафетные сочетания, имя с показателем -*лыг* + имя в номинативе. Далее в статье обсуждаются и некоторые вопросы (аспекты), связанные с выражением в агглютинативных языках категории притяжательности (посессивности). В частности, рассматривается вопрос разграничения понятий «принадлежность» и «обладание». Семантика притяжательности представляется более общей, широкой по отношению к значениям принадлежности, обладания и другим. Описываются типологические способы формального выражения семантики притяжательности в агглютинативных языках. Делается вывод о том, что более детально разбираемую семантику можно охарактеризовать исходя из формальных средств конкретного языка (группы языков).

**Ключевые слова**: категория притяжательности, значение принадлежности, значение обладания, способы выражения, аффиксация, агглютинативные языки, семантические оттенки, формальные средства, суффиксы притяжательности, хакасский язык

In the article questions of semantics and formal expression of category of possessiveness in Turkic languages are taken up (generally – on the example of the Khakass language). Special affixes admit the main spokesmen of a grammatical meaning of accessory. Also other means of formal expression of different shades of possessiveness are considered: combinations like *минiң ипчiм* ‘my wife’, izafet-combinations, a name to an indicator -*лыг* + a name in Nominative. In the article some questions (aspects) connected with expression in agglutinative language of category of possessiveness are discussed. In particular, the question of differentiation of the concepts «accessory» and «possession» is considered. Semantics of possessiveness is represented to accessory, more general, wide in relation to senses, possession and to others. Typological ways of formal expression of semantics of possessiveness in agglutinative languages are described. The conclusion is drawn that the more detail sorted semantics can be characterized based on the formal means of a particular language (group of languages).

**Keywords:** category of possessiveness, sense of accessory, sense of possession, ways of expression, affixation, agglutinative languages, semantic shades, formal means, possessiveness suffixes, Khakass language.

Хакас телендә башка телләрдәге кебек төрле сүз төркемнәренә караган сүзләр арасында үзенчәлекле бәйләнешләр барлыкка килгән һәм кайбер тел универсалияләрен (аерым алганда, тартым

категориясен) үзенчәлекле чагылдыру ысуллары формалашкан. Тартым категориясе барлык телләргә дә хас, чөнки тел кешеләр өчен һәм кешеләр турындагы мәгълүмат нигезендә тудырылган. Әлеге контекстта кешенең «нәрсәгәдер ия/хуҗа булу» үзенчәлеге дә белдерелергә тиеш булган. Кагыйдә буларак, моның өчен телдә үзенчәлекле сүз төрләнеше системасы оешкан. Тартым белән төрләнеш предметның яисә затның башка предметныкы яисә затныкы булуын, шулай ук нәрсәгә дә булса ия булуны белдерә. Кайбер билгеләре буенча типологик бергәлек тәшкил иткән Урал-Алтай телләрендә әлеге мөнәсәбәтләр исем (шулай ук зат алмашлыклары) нигезенә ялганган махсус зат-тартым кушымчалары ярдәмендә белдерелә. Аларның күбесендә бу күрсәткечләр, зат алмашлыклары һәм фигыль парадигмаларының зат-сан күрсәткечләре арасында материаль корреляция дә күзәтелә. Моннан тыш әлеге телләрдә төрле мәгънәле тамырларга (шул исәптән абстракт, җыйма яки башка шундый мәгънәгә ия сүзләрдә дә) зат-тартым кушымчалары ирекле ялгана. Шул ук вакытта биредә тиешле конструкцияләрдә логик-семантик яктан үзгәрешләр дә күзәтелә. Мәсәлән, тартым кушымчалары ‘күк, һава торышы’ мәгънәсенә ия тамырга ялганган очракта, күбрәк локатив мәгънә белдерелә (= ‘мин / син / ул урнашкан урында’).

Зат-тартым кушымчалары абстракт, субъектив-модаль яки экспрессив мәгънәгә ия сүз тамырларына ялганган очраклар (фразалар) кызыклы. Түбәндә китерелгән материал зат-тартым кушымчаларының төрле (семантикасы буенча) тамырларга, шул исәптән кӧӊнi ‘теләк’ тибындагы сүзләргә, ирекле ялгану мөмкинлеген күрсәтә: КӦӉНI употр. с афф. принадлежности 3 л. 1) желание, стремление, воля; кӧӊнiӊнең ползын пусть будет по-твоему (букв. по твоему желанию) … 2) настроение … 3) в сочет. с кiрерге душа, сердце; кӧӊнiне кiрбеске [ему] не понравиться; [ему] не по душе… [ХРС 2006, с. 201–202].

‘Кӧӊнi + фигыль’ тибындагы тезмәләр эмоциональ эшчәнлек процессының төрле аспектларын характерлыйлар һәм хакас телендә еш кулланылалар. Мондый эшчәнлек фәкать кешегә генә хас булганга күрә, ‘кӧӊнi + фигыль’ тибындагы тотрыклы тезмәләр хакас телендә зат-тартым күрсәткечләре, зат алмашлыклары һәм фигыль парадигмаларының зат-сан күрсәткечләре арасындагы корреляцияне чагылдыралар.

Әгәр дә тартымның (яки посессивлыкның) эчтәлек ягын типологик аспектта карасак, бу күренеш күзәтелгән телләрдә, аның катлаулы, гаять үтеп керүчән һәм төрле дәрәҗәле (белдерү чаралары буенча) булуын күрү авыр түгел. Хакас телендә күзәтелгәннәрне борынгы төрки прототипка тоташтырырга мөмкин (ул шартлы гомумтөрки тип вариациясе, ягъни барлык төрки телләрдә тартымның чагылыш ысулы булып тора). Бу әлеге семьялыкка кергән аерым телләрдә билгеле бер тартым мәгънәләрен белдерү ысулларында һәм чараларында кайбер үзенчәлекләр саклану күренешенә каршы килми.

Башка агглютинатив телләр (мәсәлән, самодий, обь-угор, фин-пермь) белән чагыштырганда, охшашлыкларны да (үзенә бертөрле зат-тартым кушымчаларын файдалану), аермалыкларны да (изафә тибындагы үзенчәлекле төрки тартым конструкциясен булдыру) билгеләп үтәргә мөмкин. Биредә башка пландагы аермалыклар да күзәтелә (аерым алганда, исемнәрнең үзгәреше системасы тышында зат-тартым кушымчаларының яшәеше буенча), ләкин алар әллә ни әһәмиятле түгел (чөнки «тартым/ия булу» төшенчәләре белән бәйле).

Төрки телләрдә тартым категориясе тикшерү объекты буларак XIX гасырның икенче яртысында – XX гасыр башларында А.К. Казем-Бек, О. Бётлингк, Н.И. Ашмарин, П.М. Мелиоранский, Н.Ф. Катанов хезмәтләрендә аерып чыгарыла. Ул беренче грамматикалар төзелү моментыннан башлап өйрәнү өчен билгеләнгән мәҗбүри бүлекләрнең аерылгысыз өлешен тәшкил итә. Аларда, кагыйдә буларак, аны белдерүнең түбәндәге ысуллары аерып чыгарыла: морфологик, синтаксик һәм катнаш [Дмитриев, 1948; Исхаков, Пальмбах, 1961; Мусаев 1964; Грамматика хакасского языка, 1975 һ.б.]. Төрки телләрдә тартым категориясенең мәгънәсе гадәттә ике компоненттан торган тартым конструкциясендә гамәлгә ашырыла, аның беренчесе – субъект (ия булучы), икенчесе – объект.

Телнең өйрәнелә торган характерлы үзлеге (ия булу, кемгә яисә нәрсәгә дә булса карау) аның конкрет берәмлекләрендә (һәм аларның тезмәләрендә) төрлечә чагылыш таба торган киң, күпкырлы күренеш буларак күзаллана. Әлеге категориянең зарурлыгы, мөһимлеге һәм кыйммәте, аның универсаль характеры кебек үк, барлык лингвистик энциклопедияләрдә, белешмәлекләрдә, сүзлекләрдә ассызыклана [кара: мәсәлән, Журинская 1990].

Тартым категориясенең булуы барлык алтай, шул исәптән төрки телләрнең дә иң мөһим характеристикасы санала [Дмитриев, 1956; Грамматика хакасского языка, 1975, с. 62–66; Черемисина, 1992, с. 82–83; Гаджиева, 1997, с. 28–29; Карпов, 1999; Рассадин, 2006; и др.]. Әгәр дә кайбер гомуми характеристикаларга игътибар итсәк, төрки телләрдә аны белдерү чаралары, мәсәлән, монгол яки фин-угор телләрендәгедән әллә ни аерылмый. Бу телләрдә посессив мөнәсәбәтләр махсус иялек аффикслары ярдәмендә дә, тартым алмашлыклары белән дә белдерелә [Тенишев, 1997, с. 11–12; Миндиярова, 2007; Рассадин, 2011, с. 70–73].

Чыннан да, посессив мөнәсәбәтләрне белдерүнең әлеге морфологик-синтаксик ысулы төрки телләрне фин-угор телләре белән дә якынайта, аерма бары шунда: фин-угор телләре системасы флективлык һәм синтез үзенчәлекләренең өстенлек итүе белән характерлана. Төрки телләр системасы шулай ук изафәнең булуы һәм бер үк суффиксларны (шул исәптән – тартым) исем сүз төркеме өлкәсендә дә, фигыльнең аналитик формаларын ясау өчен дә куллану мөмкинлеге белән аерылып тора [Широбокова, 2005, с. 238–240].

Тартым конструкцияләрен без аергыч мәгънәле конструкцияләрнең билгеле бер төре итеп карыйбыз. Бу очракта *билге мәгънәсе, атрибутив мөнәсәбәтләр, посессивлык* терминнары үзара синонимнар була һәм семантик бәйләнешнең күрсәтелгән тибы һәрвакыт төп нигез, тел универсалиясе итеп карала [Кручинина, 1990; Николаева, 1990, с. 535; Плунгян, 2000, с. 242–245].

Бу фикерне үстереп, шуны әйтәсе килә: семантиканы өйрәнгәндә, ‘тартым’ һәм ‘посессивлык’ терминнары өчен дефиницияләрнең туры килү фактына таянып эш итәргә мөмкин. Шулай итеп, тартым – универсаль тел категорияләренең берсе (күплек, билгелелек һәм билгесезлек, бәяләү һ.б. кебек), аның төп мәгънәсе – объектның «сыйфатын» аның билгеле бер затка яисә предметка мөнәсәбәте аша билгеләү. Алга таба исем һәм фигыль сүзләр (сүз формалары) белән белдерелә торган тартымны аеру сорала. Исем сферасында партитивлык, атрибутивлык, семантик релятивлык кебек төсмерләр чагыла. Фигыль (предикатив) сферасында исем сферасындагы тартым мөнәсәбәтләре (минем атым = миңа караган ат), шулай ук детерминация, локативлык, предикативлык (безнең күгебез = безнең өстәге күк йөзе; безнең һава торышы – без булган урындагы һава торышы) кебек төсмерләр чагыла.

Шулай итеп, эчтәлек ягыннан тартым («кемнеке?» соравына җавап бирә торган билгеләү аергычы) конструкцияләрен семантиканы репрезентацияләү сәләте берләштерә. Ул түбәндәге схемаларга туры килә:

– нәрсәдер кемгәдер карый, кемдер нәрсәнеңдер хуҗасы, милекчесе булып тора (нәрсәгәдер ия була): *аал малы* ‘авылда яшәүчеләрнең терлеге’, *тура ээзі* ‘йорт хуҗасы’, *минің китабым* ‘минем китабым’, *хакас чирі* ‘хакас җире’, *Азарханның туразы* ‘Азарханның йорты’ һ.б.;

– нидер кемнеңдер (нәрсәнеңдер) аерылгысыз сыйфаты, билгесе, аерым очракта атамасы булып тора: *кізі ады* ‘кешенең исеме’, *адамның ады* ‘атамның исеме, *адай ады* ‘этнең кушаматы, *минің холым* ‘минем кулым’ һ.б.;

– кемдер туган, үз, якын кеше, таныш, хезмәттәш һ.б. кебек башка җанлы субъект белән бәйләнештә карала: *Катяның пабазы* ‘Катяның әтисе’, *минің танызым* ‘минем танышым’, *ағамның нанҷызы* ‘өлкән абыемның дусты’, *хонҷыхтың оолғы* ‘күршенең улы’, *ööремнің апсаа* ‘иптәш кызымның ире’, *минің ипчім* ‘минем хатыным’, *минің нанҷыларым* ‘минем дусларым, *театрының актёры* ‘театр актеры’ и т.д.;

– нәрсәдер (кемдер) берәр әйбернең (кемнеңдер) өлеше булып тора: *аал азағы* ‘авыл чите’, *аал клубы* ‘авыл клубы’, *ит кизегі* ‘ит кисәге’, *торғы кизегі* ‘ефәк кисәге’ һ.б.

Тартым семантикасының вариативлыгына телнең атап үтелгән мәгънәләрне һәм аларның төсмерләрен белдерү өчен хезмәт итә торган формалары челтәре салына. Башкача әйткәндә, тартым мәгънәсен белдерү ысулы төрле телләрдә типологик гомуми категория

(тел универсалиясе) күренешләрендә сыйфат аерымлыкларының үрнәге булып тора. Шулай да нәрсәдер ~ кемнеке яки кемдер ~ кемнеке схемасы буенча төзелгән конструкцияләр прототипик характерга ия.

Хакас телендә, башка төрки телләрдәге кебек үк, әлеге күренешнең формаль ягы барыннан да элек «исемнәргә, шулай ук субстантив функцияләрдәге башка сүзләргә кушылган, зат һәм сан ягыннан аерыла торган аффиксларда чагылыш таба: *паба-м* ‘атам’, *паба-быс* ‘атабыз’, *пабалар-ыбыс* ‘аталарыбыз’, *киме-ң* ‘көймәң’, *парган-ы* ‘китүе’ һ.б.» [Донидзе 1997, с. 464].

Биредә беренче рәткә тартым алмашлыклары һәм сыйфатларның синтетик сүз формаларын да куярга мөмкин. Хакас телендә тартым мәгънәләрен бирә торган берничә сүзьясалыш аффиксы бар; алар ярдәмендә барлыкка килгән сүз формалары еш кына киңәйтелгән тартым конструкцияләренең нигезен тәшкил итә: *-тии*; *-тың*; *-тырых*; *-тых*; *-ха*; *-хай*; *-хан*; *-хах*; *-чы*; *-чыл*; һ.б.

*-тии* (*-нии*, *-ии*, орфографик яктан *-ти*, *-ни*, *-и*) кушымчасы тартым сыйфатлары, алмашлыклары барлыкка китерә: *аални* сельский (*аал* село, населённый пункт); *аңни* звериный (*аң* зверь); *кізіни* человечий, человеческий (*кізі* человек); *палани* детский, ребячий (*пала* ребенок, дитё); *сугни* водный, водяной (*суг* вода, река) [ХРС, 2006, с. 1072]. Мондый мисаллар тартым төсмерләрен чагылдырган төп форманы аерырга мөмкинлек бирә – номинативтагы исемне + генитивтагы исемне.

Еш очрый торган тартым конструкцияләре алмашлык яки исемаергыч һәм зат-тартым аффикслы исем кушылмасы белән барлыкка килә.

***Аналитик форма: -лыг күрсәткечле исем + номинативтагы исем.*** *-лыг* формантының *-ліг, -ныг*//*-ніг, -тыг*//*-тіг* фонетик вариантлары бар; әлеге аффикс сүзнең семантикасына түбәндәгеләрне өсти:

а) конкретлык-предметлык мәгънәсен: *чахайахтыг чазы* ‘чәчәкләр үскән дала (сүзгә-сүз: чәчәкле дала)’, *палалыг сӧбіре* ‘балалы гаилә’, *аарлыг колода* ‘бал кортлы бүрәнә’, *яблахтыг ӱгре* ‘бәрәңгеле аш’, *аарлыг чирлер* ‘бал кортлары күп булган урыннар’ һ.б.;

ә) ия булуның абстракт мәгънәсен: *хос хулахтыг ат* ‘ике колаклы ат’; *Кемнің парганы (ылгааны)*? – Кемнең китүе (елавы)? *Минің парганым* – Минем китүем. *Аның ылгааны* – Аның елавы. *Хызычах ылгаанынаң узубысхан* – Кыз шулкадәр елады, йоклап киткән. ***Минің чуртымны*** *кізі чуртабазын,* ***минің чобаамны*** *кізі кӧрбезін* ‘Минем тормышымны беркем дә яшәмәсен, минем кайгымны беркем дә күрмәсен’ һ.б.

Посессивлык (тартым) төшенчәсен бу рәвешле аңлату барлык телләрдә дә чагыла, әмма формаль яктан белдерелү аерыла, әлбәттә. Күп кенә телләрдә махсус проприетив (ия булу мәгънәле) аффикслар бар. Ф. Эбата фикеренчә: «Еш кына мондый аффикслар ия булуны

гына түгел, ә билгеле бер коннотацияләр (мәсәлән, субъект ия булган әйбернең махсус үзлекләре яки вакытлыча ия булу, ягъни билгеле бер моментта ия булу) белән баетылган поссесивлыкны да белдерәләр» [Эбата, 2014, с. 11].

Биредә эчтәлек белән тутырылу бертөрле: нәрсәгә дә булса ия булу факты раслана; телдә «ия булу» тибындагы сүзләр ярдәмендә тасвирлана торган мәгънәләр комплексы барлыкка килә. Ия булу мәгънәләрен белдерүнең махсус формасы (мәсәлән, махсус аффикс) булган күпчелек телләрдә бу форма реаль яшәештә ия булу семантикасы белән турыдан-туры бәйләнмәгән чиктәш мәгънәләр дә бирә. Әйтик, якут телендә (*-лаах* аффиксы), башка күп кенә төрки телләрдәге кебек (хак. *-лыг*, башк. *-лык*), бу семантик кырга предмет өлешчә генә ия булган материал (*көмүстээх холбуйа* ‘көмеш йөгертелгән шкатулка’), берәр нәрсәне салып саклау урыны (*бутулкалаах уу* ‘су бутылкасы’, сүзгә сүз ‘сулы бутылка’; *тымтайдаах балык* ‘кузовтагы балык’, ‘кузовка урнаштырылган балык’), җыелмалылык («ские»га беткән рус исемнәре: *Балансаптаах* ‘Баланшевские’), ниндидер оешмада тору (*колхозтаах* ‘колхозчы’, ‘колхозда торган’) мәгънәләре дә керә [Убрятова, 2011, с. 243–246].

Төрки телләрне тартым категориясе морфологик белдерелгән башка агглютинатив телләр белән тагын еш кулланыла торган зат-тартым аффиксларының һәрвакытта да затныкы булу («затның ия булуы») мәгънәсен белдермәве дә якынайта. Бу еш кына әлеге кушымчалар нинди дә булса гамәл кыла торган затны гына белдергәндә күзәтелә, ләкин әлеге очракта, тел чараларын яисә сөйләм хәрәкәтләрен экономияләргә омтылу аркасында, зат алмашлыгы төшеп кала: *харындазымны удурлапчам* – карендәшемне каршылыйм; *ирік чох тоғызыбысты тоостыбыс* – эшебезне тәмамларга туры килде, *сағызым сыхханҷа хорыхтым* – шундый курыктым, аздан гына акылымны җуймадым.

Шул ук вакытта ниндидер теләкләргә, ихтыяҗларга, сәләтләргә ия булу тиешле мәгънәгә ия сүз ясалышы суффикслары ярдәмендә белдерелә: *кӱстіг кізі* – көчле кеше һ.б.

Шулай итеп, теләсә кайсы телдә тартым конструкцияләренең әһәмияте, беренче чиратта, һәрбер табигый телнең тере «физиономиясен» билгели. Күпчелек телләрдә, шул исәптән төрки телләрдә дә, поссессивлык категориясе шактый өйрәнелгән. Әмма шул ук вакытта яңа тикшеренүләрнең кайбер когнитив һәм типологик юнәлешләрен билгеләргә мөмкин. Шунысы кызык: аерым алганда, барлык исемнәргә дә тартым аффикслары «ирекле» кушыламы икән? Уйланылганча, хакас телендә, башка телләрдәге кебек үк, бу үзлеккә абстракт һәм гомуми мәгънәгә ия сүзләр (йолдызны атаган сүз кебек) ия түгел. Мәсәлән, *Солбан* – Венера. *Солбаннығ – Венера белән* дияргә ярамый. Аның ‘һава торышы’ дигән мәгънәсе дә бар.

Бу мәсьәлә алга таба тикшеренүләр үткәрүне таләп итә. Формаль як турында тагын шуны да әйтергә мөмкин: инвентарь – шактый

күптөрле, ә аның башлангыч классификациясен (яки эчке типологиясен) катлаулылык дәрәҗәсе буенча эшләргә мөмкин (синтетиклык / аналитика билгесе белән бергә). Тулаем алганда, тартым категориясенең формаль ягы барлык агглютинатив телләрдә дә күп кенә уртаклыкларга ия.

Хакас телендә, кайбер төрки һәм фин-угор телләрендәге кебек үк, төрләнешнең ике төре бар: абсолют (төп) һәм зат-тартым (билгелезатланышлы). Абсолют төрләнештә килеш кушымчалары турыдантуры исемнәргә ялгана. Зат-тартым төрләнеше абсолют төрләнештән зат-тартым кушымчаларының кулланылуы белән аерыла. Әлеге очракта сүз формасында килеш кушымчасы зат-тартым кушымчасыннан соң ялгана. Мәсәлән, *чазыларында* сүзендә, *чазы* ‘кыр’ тамырыннан соң, күплек кушымчасы -*лар*, тартым кушымчасы -*ы* һәм килеш кушымчасы -*(н)да* бар [Патачакова 1987, с. 108].

Төрки телләрдә исемнәр төркемендә посессивлык шулай ук изафә конструкцияләр рәвешендә дә белдерелә ала. Мондый конструкцияләрнең төрле вариантлары очрый: *аттың кӱзі* ‘атның күче’, *аар чыдазы* ‘бал корты угы’, *ханның наместнигі* ‘хан наместнигы’, *сööк нандырды* ‘әни ягыннан туганга өйләнү’, *ат ніңірті* ‘атларның ерактагы тояк тавышы’, *öскі тӱгі* ‘кәҗә йоны’ һ.б. Алга таба изафетка аерым тикшерү багышлау күздә тотыла һәм аны иран телләрендәге аналогик күренеш белән чагыштыру формасында гамәлгә ашырырга мөмкин.

В.А. Плунгян исемнәрдәге төп синтаксик граммемаларны тикшергәндә [Плунгян 2000, с. 167–172, 184–187], дөньядагы телләрдә килешләр инвентаре мәсьәләләренә һәм изафә, һәм аларга охшаш конструкцияләрне төзү ысулларына җентекләп туктала.

Фигыльләр өлкәсендә теге яки бу телдә посессив конструкциянең өстенлек итүче тибы турында сөйләргә кирәк (мондый конструкцияне «ия булу» мәгънәсендәге фигыль предикатлары төзи). Бу конструкция *ия булу* фигыле катнашында төзелә торган телләр habeo-тел (лат. *habeo* ’ия булу’), ә *булу* (рус. *есть*) фигыле ярдәмендә ясала торган телләр esse-тел дип атала (латинча *esse* ’булу’).

Лингвистик типология аспектында тартым категориясенең синтетик һәм ярымсинтетик морфологик формалары аеруча зур кызыксыну уята. Алар, билгеле булганча, алтай телләрендә генә түгел, урал телләрендә дә бар. Һәм бу формалар аеруча күптөрле. Мәсәлән, самодий телләрендә, затланышлы һәм затланышсыз тартымны билгеләүнең үзгә белдерелү формалары бар. Аны иялек килеше формасы буларак карау – табигый күренеш. Хакас телендә дә генитив бар, һәм анда да әлеге килеш формасы шулай ук төрле тартым төсмерләрен бирү системасында катнаша.

Башка күп кенә агглютинатив телләрдәге кебек үк, хакас телендә иялек мөнәсәбәтләрен белдерү системасында төп рольне тартым аффикслары уйный. Төрле телләрдә билгеле бер семантик чикләүләр яши. Мәсәлән, тартым суффикслары иректе кушыла торган исем төркемнәренең (сүзләрнең) күләме буенча. Бу аспектта Урал телләре

материалы аеруча кызыклы: аларда посессив аффикслар, ия булу мәгънәсен киң планда белдереп, теләсә нинди лексик эчтәлекле исемнәргә кушылалар. Хакас тел белемендә бу мәсьәлә әле куелмаган, шуңа күрә яңа тикшеренүләр генә зат-тартым аффикслары кушыла (яки кушылмый) торган лексик берәмлекләргә кагылышлы кыйммәтле материал бирергә мөмкин.

**Әдәбият**

*Гаджиева Н.З.* Тюркские языки // Языки мира: Тюркские языки. М.: Изд-во «Индрик», 1997. С. 17–34.

Грамматика хакасского языка / редкол.: М.И. Боргояков, А.И. Грекул, Г.И. Донидзе, Д.Ф. Патачакова / под ред. проф. Н.А. Баскакова. М.: Наука, 1975. 420 с.

*Дмитриев Н.К.* Грамматика башкирского языка. М.-Л.: Издательство АН СССР, 1948. 276 с.

*Дмитриев Н.К.* Категория принадлежности // Исследования по сравнительной грамматике тюркских языков. Ч. II: Морфология. М.: Изд-во АН СССР, 1956. С. 22–37.

*Донидзе Г.И.* Хакасский язык // Языки мира: Тюркские языки. М.: Изд-во «Индрик», 1997. С. 459–470.

*Журинская М.А.* Посессивность // Лингвистический энциклопедический словарь / гл. ред. В.Н. Ярцева. М.: Советская энциклопедия, 1990. С. 388–389.

*Исхаков Ф.Г., Пальмбах А.А.* Грамматика тувинского языка. Фонетика и морфология. М.: Издательство восточной литературы, 1961. 470 с.

*Карпов В.Г.* Сопоставительная характеристика существительных русского и хакасского языков // Ежегодник Института саяно-алтайской тюркологии. Выпуск III. 1999. С. 15–20.

*Кручинина И.Н.* Определение // Лингвистический энциклопедический словарь / гл. ред. В.Н. Ярцева. М.: Советская энциклопедия, 1990. С. 348–349.

*Миндиярова Э.Р.* Морфолого-синтаксический способ выражения категории притяжательности в хантыйском и татарском языках // Вестник Томского государственного педагогического университета. 2007. Вып. 4 (67). С. 86–88.

*Мусаев К.М.* Грамматика караимского языка. Фонетика и морфология. М.: Наука, 1964. 343 с.

*Николаева Т.М.* Универсалии языковые // Лингвистический энциклопедический словарь / Главный редактор В.Н. Ярцева. М.: Советская энциклопедия, 1990. С. 535–536.

*Патачакова Д.Ф.* Морфемная структура слова в хакасском языке // Лексикология и словообразование хакасского языка / Хакасский НИИ языка, литературы и истории. Абакан, 1987. С. 108–122.

*Плунгян В.А.* Общая морфология: Введение в проблематику. М.: Эдиториал УРСС, 2000. 384 с.

*Рассадин В.И.* Аффиксальное словообразование именных основ бурятского языка: Сравнительный аспект // Вестник Бурятского университета. 2006. Серия 18. Вып. 2. С. 139–157.

*Рассадин В.И.* Местоимения в монгольских и тюркских языках // Урало-алтайские исследования. 2011. № 1 (4). С. 63–75.

*Тенишев Э.Р.* Алтайские языки // Языки мира: Тюркские языки. М.: Изд-во «Индрик», 1997. С. 7–16.

*Убрятова Е.И.* Аффикс обладания -*лаах* в якутском языке // Убрятова Е.И. Избранные труды: Исследования по тюркским языкам / Институт филологии СО РАН. Новосибирск: РИЦ НГУ, 2011. С. 242–247.

Хакасско-русский словарь = Хакас-орыс сӧстiк / Коллектив авторов. Новосибирск: Наука, 2006. 1114 с. (ХРС)

*Черемисина М.И.* Языки коренных народов Сибири: Учебное пособие / Новосибирский государственный университет. Новосибирск, 1992. 92 с.

*Широбокова Н.Н.* Отношение якутского языка к тюркским языкам Южной Сибири / Институт филологии СО РАН / отв. ред. Л.А. Шамина. Новосибирск: Наука, 2005. 269 с.

*Эбата Ф.* Аффиксы проприетива в языках Северо-Восточной Евразии: обзор // Томский журнал лингвистических и антропологических исследований. 2014. № 1. С. 9–14.

***Каксин Андрей Данилович,***
*филология фәннәре докторы, Н.Ф. Катанов исемендәге*
*Хакас дәүләт университеты Гуманитар тикшеренүләр*
*һәм Саян-Алтай тюркологиясе фәнни-тикшеренү институтының*
*әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

УДК 81’373.45

***Г.Х. Гыйләҗетдинова***

# «ХОЖЕНИЕ КУПЦА ФЕДОТА КОТОВА В ПЕРСИЮ» ӘСӘРЕНДӘ ШӘРКЫЙ ЧЫГЫШЛЫ ЛЕКСИКА

Статья посвящена исследованию восточных лексических элементов в «Хожении купца Федота Котова в Персию», памятнике путевой литературы XVII столетия. Купца Котова интересовали не только вопросы экономики, торговли, но и повседневной жизни персиян. В ходе анализа выявляется довольно внушительный пласт ориентализмов, функционирующих в исследуемом хожении. Показательно, что автор знал персидский и турецкий языки. В памятнике насчитывается около 100 лексем восточного происхождения, не считая перечисления букв алфавита и числительных. Котов использует восточные заимствования, которые уже адаптировались в лексической системе русского языка первой четверти XVII века и воспринимались как слова русские. Особую значимость в создании своеобразной картины мира хожения приобретают ориентализмы-экзотизмы, характеризующие разнообразные реалии восточной жизни – быт, денежные отношения, средства передвижения, наименования сооружений, религиозные праздники и др.

**Ключевые слова:** восточные лексические элементы, ориентализмы, хожение, русский язык, заимствование, словарный состав языка.

The article is devoted to the study of oriental lexical elements in «The Journey of the Merchant Fedot Kotov to Persia», a monument of travel literature of the 17th century. Merchant Kotov was interested not only in questions of the economy, trade, but also in the everyday life of the Persians. It is significant that the author knew Persian and Turkish. There are about 100 lexemes of Eastern origin in the monument, not counting the enumeration of letters of the alphabet and numerals. In the course of the analysis, a rather impressive layer of Orientalisms is revealed, functioning in the walk under study. Kotov used Eastern borrowings which were already adapted to the lexical system of the Russian language of the first quarter of the 17th century and were perceived as Russian words. Of particular importance in creating a picture of the world of wandering are orientalisms-exoticisms that characterize the various realities of Eastern life – everyday life, monetary relations, transport, names of structures, religious holidays, etc.

**Keywords:** oriental lexical elements, orientalisms, wandering, Russian language, borrowing, vocabulary of the language.

XVII гасыр сәяхәтнамәләре арасында «Хожение купца Федота Котова в Персию» әсәре аерым урын алып тора. Бу, барыннан да элек, әсәрдә ерак Көнчыгыш илләренең берсе – Фарсы иленең (Персия, Иран) үзенең бөтен милли үзенчәлекләре белән тасвирлануына бәйле. Федот Афанасьевич Котов сәүдәгәрләр нәселеннән булган һәм берничә дистә еллар Көнчыгыш илләре белән сәүдә иткән һәм фарсы һәм төрек телләрен дә яхшы белгән. 1623 елда ул патша Михаил Федорович һәм патриарх Филарет указы ниге-

зендә Әстерхан аша Фарсы иленә дәүләт казнасы товарлары белән җибәрелгән.

Котов сәяхәтенең тасвирламасы беренче тапкыр 1852 елда «О ходу в Персидское царство и из Персиды в Турскую землю и в Индею, и в Урмуз, где корабли приходят» дигән исем белән «Временник Императорского московского общества истории и древностей Российских» басмасында дөнья күрә. Котовның игътибар үзәгендә сәүдә мәсьәләләре генә булмаган, аны сәясәт, икътисад, тарих, география дә кызыксындырган. Ул фарсыларның гореф-гадәтләрен тасвирлый: «При написании заметок купец часто использовал слова “говорят”, “рассказывают”, то есть для получения информации применял не только метод наблюдения, но и опроса, выступая в роли любознательного журналиста-исследователя» [Федоркова, с. 58].

Котов әсәренең теле төгәл һәм чикләнгән, аңлаешсыз формулировкалардан азат булуы белән аерылып тора. Бу Илчелек приказы өчен билгеләнгән эш документларына куелган таләпләргә тулысынча туры килгән. Сәяхәт турында кечкенә генә хисапта ориентализмнарның киң катлавы урын алган. Котов аларны әсәргә аерым бер милли колорит биргән Шәрык чынбарлыгының үзенчәлекләрен тасвирлау өчен куллана. Ориентализмнар дигәндә, без Шәрык телләреннән (төрки, гарәп, кытай, фарсы телләре) кергән алынмаларны күз алдында тотабыз. Безнең исәпләүләр буенча, Котовның әсәрендә, алфавиттагы хәрефләрне һәм саннарны санап чыгуны исәпләмәгәндә, шәркый чыгышлы 100 ләп лексема бар.

Аның маршрутының шактый өлеше елга һәм диңгезләр буйлап хәрәкәт итү белән бәйле булганлыктан, әсәрдә су транспорты атамалары очрый. Мәсәлән, судно исемнәре арасында Шәрык телләреннән алынмалар очрый: *сандал* «бер мачталы төрек каботаж судносы». Чагыштыр, мәсәлән: *«А товары возят з бус в Астрохань и из Астрохани сандалы и павоски»* [Хожение…, с. 32].

Сәүдә юлы ул вакытта яхшы билгеле булган һәм ул күп кенә эре шәһәрләр (Түбән Новгород, Казан, Царицын, Әстерхан, Дәрбәнд, Казбин һ.б.) аша узган. Котов өчен шәһәрләр арасындагы ераклыкны күрсәтү мөһим була, моның өчен ул шәркый чыгышлы *агач* сүзен (төрек, азәрб. аүаč «6 чакрымнан җиде чакрымга кадәрге аралык») куллана: *«От Низовой ходу до Шаврина четыре агача ... а по русскому во всякой агачи по 5 верст. А итти полями и мокрым местом»* [Хожение…, с. 33].

Моннан тыш, ул юлның нинди булуын һәм бу урыннар буйлап хәрәкәт итү ысулын күрсәтә: *«А от Низовой ход в Шемаху по горам высоко ... а ходят на конях, и на верблюдех ... на вьюках, а тележного пути нет»* [Хожение… с. 32–33]. Биредә Шәрык телләреннән алынган *вьюк* (төрек, чагат., алт., уйг. «йөк, авырлык») сүзе йөк хайваннарын, барыннан да элек, үтеп йөрүе авыр булган таулы урыннарда, дала һәм чүлләрдә алыштыргысыз ишәк һәм дөяләрне белдерә.

Әсәрдә Фарсы илендәге таможня пошлиналары турындагы мәгълүматлар аерым урын алып тора. Әйтик, Тарка һәм Дәрбәндтә, Котов хәбәр итүенчә, сәүдә итүчеләрдән *«бөек пошлиналар»* алалар, ә Кураны кичкәндә *«рахтаны емлют с верблюда по две абасы»* [Хожение… с. 36]. Шәрыктан кергән *рахтан* сүзе юл пошлиналары җыючыны (чагыштыр: фарс. *раһдан* «үткәреп торучы», *раһдар* «юл сакчысы», «юл пошлиналары җыючы»), *абаса* – фарсыларның көмеш тәңкәсен (20 тиен чамасы) аңлата.

Котовны, сәүдәгәр буларак, барыннан да элек икътисад һәм сәүдә мәсьәләләре кызыксындырган. Әсәрдә әлеге өлкәләргә караган атамаларның төп өлешен Шәрык алынмалары тәшкил итә – *батман* «үлчәү берәмлеге», *деньги*, *товар*, *казна* һ.б. Чагыштыр: *«А все продают в вес в батманы: дрова, и траву, и муку, и пшеницу, и масло… и всякие овощи»* [Хожение…, с. 44].

Аның өчен шулай ук үзе килгән илдә нинди товарлар белән сату итү, анда ниләр җитештерелү, нинди товарлар һәм аларның кайсы илләрдән китерелүе турында хәбәр итү дә мөһим була. Сәүдә предметлары арасында тукыма (*дороги* «Көнчыгыш ефәк тукымасы», *киндяк* «киҗе-мамык тукыманың бер төре», *миткаль* «мамыктан юка тукыма»), салкын корал (*сабля*) атамаларын, көнкүреш әйберләрен (*сундук, шатер*) белдергән Шәрык алынмалары бар. Сәяхәтче сүзләренә караганда, *«Тут делают дороги кашанские, и бархаты, и кизылбашские камочки … а миткали привозят из Индеи и из арап и в том ряду товары торгуют… и сабли и шатры делают у шаховых ворот»* [Хожение…, с. 41–42].

Чит ил шәһәрләре турында сөйләгәндә, Котов кәрвансарайларга – Якын һәм Урта Көнчыгыш сәүдә юлларындагы юлаучылар йортларына зур игътибар бирә: *«А по дороги от Шаврани до Шамахи стоят три карасамраи, а по руски – гостиные дворы, каменные, крепки и добры, с амбары и конюшнями и с вороты…»*. Әсәрдә *кәрвансарай* ориентализмы төрле фонетик вариантларда бирелгән *(«карасамраи», «карамсараи», «карамраи»).* Бу исә ядкәр язылган вакытта – XVII гасырның беренче чирегендә әлеге сүзнең рус телендә әле үзләштерелеп бетмәве турында сөйли. Әлеге лексеманың «Хожение гостя Василья»да (1466 ел) беренче тапкыр теркәлгән варианты белән чагыштыр: *«Рѣка великы Евфрантъ сквозь его идетъ да разведена подо всѣ и торги по улицам и по кѣрмасараемъ»* [Хожение гостя Василья, с. 103]. Рус телендә алынманың фонетик-график адаптациясе XVII гасырның икенче яртысында гына тәмамлана. Мәсәлән, Арсений Сухановның «Проскинитария»сендә түбәндәге юлларны укыйбыз: *«Въ 17 день приѣхали въ Генджу въ обѣдъ, стали въ караванъсараѣ»* [Проскинитарий… с.103].

Котов үзен кызыксындырган башка экзотик корылмалар турында да яза. Әйтик, *кафа* – «Шәрык каһвәханәсе», *киюз* – «киоск, павильон», *мечеть* – «мөселманнарның гыйбадәт йорты». Уеп-кисеп бизәк төшереп, алтын йөгертеп эшләнгән таш мәчетләр сәяхәтчегә аеруча

матур булып тоела. Исфаханда төзелеп килгән зур мәчет хакында ул менә нәрсә ди: *«А величеством мечеть от больших дверей 80 сажен, а поперег и с приделы ...со 100 сажен, а камен делан розной, и делом и каменем строино...уряжена что ...невеста... и в мечети выписано золотом»* [Хожение..., с. 43].

Фарсы иленең иң борынгы шәһәрләреннән берсе булган Казвинны тасвирлаганда, аның урам тамашалары (*тамаша*) уза торган үзәк мәйданы (*майдан*) турында сүз бара. Котовның юл язмаларында *майдан* алынмасы шактый еш (30 лап) очрый. Бу исә Шәрык шәһәрләре тормышында базар мәйданнарының мөһим роль уйнавы хакында сөйли: анда «төрле товарлар» белән сату итеп, бәйрәмнәр, тантаналы йөрешләр уздырып кына калмаганнар, хөкем дә иткәннәр, җәза да биргәннәр һ.б. *Майдан* лексемасы, академик Н.К. Дмитриев фикеренчә, фарсы теленнән кергән: «Перс. *меидан* «площадь, арена», откуда тур., тат. и др.» [Дмитриев, с. 28]. Шунысы игътибарга лаек: *майдан/мойдан* ориентализмы «мәйдан, җыен урыны; базар мәйданы» мәгънәсендә беренче мәртәбә XVII гасыр башында Мәскәү Русенең Фарсы иле белән дипломатик багланышлары яктыртылган «Посольство князя М.П. Барятинского» (1619) истәлегендә теркәлгән: *«Подлинно де я про тоѣ статью самъ не вѣдаю, а слышал де я про тоѣ статью на мойданѣ»* [Словарь русского языка...].

Котов әсәрендә билгеләнгән *тамаша/томаша* алынмасы да шәркый чыгышлы (чагыштыр: фарс. тӓмāшā, тат. тамаша) һәм «халыкка махсус әзерләп күрсәтелә торган күренеш, уен яки сәхнә әсәре»н белдерә. Сәяхәтче берничә тапкыр үзе керткән *тамаша* лексемасын һәм *тамаши делать* сүзтезмәсен эш көннәрендәге, мөселман бәйрәмнәрендәге һ.б. тамашаларны тасвирлаганда куллана. Мәсәлән, сәяхәтче рамазан аенда (мөселман календаре буенча тугызынчы ай – ураза ае) фарсыларның төнге тормышын түбәндәгечә бәян итә: *«И пост у них таков: в день ни пьют, ни ядят, а как солнце заидет и они пьют и ядят мясо ... и в кафах и на маидане играют, пляшут, и всякие тамаши делают»* [Хожение..., с. 48].

Котов әсәрендә төрле кабиләләр һәм халыклар – кабардалылар, лезгиннар, татарлар, яһүдләр, нугайлар турында этнографик мәгълүматлар да китерелә. Ул алар белән сәяхәт вакытында очрашкан: Мәсәлән: *«А за станицею ходят стрелцы, и татарове юртовские для оберегания от казаков и от казыевских тотар»* [Хожение..., с. 32]. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: автор фарсыларны *кизылбаши,* ягъни кызылбашлар (кызыл төстәге чалма кигән фарсыларның борынгы кушаматы) дип атый. Мәскәү Русендә фарсыларны хәтта рәсми документларда да кызылбашлар дип теркәгәннәр. Әсәрдә *Кизылбаш* топонимы да (кызылбашлар яшәгән территория, ягъни Фарсы иле) очрый: *«А от Астрохани ходят в Кизылбаши и в мелких стругах»* [Хожение..., с. 35]. Котов үзенең юл язмаларында Фарсы илен «кизылбашские земли», «персицкая земля», «шахская земля» дип тә исемләгән.

Культурологик планда фарсыларның тормыш-көнкүрешен күзәтү язмаларда аерым урын алып тора. Котов фарсыларның киемсалымын, аяк, баш киемнәренең исемнәрен тәфсилләп тасвирлаган, алар арасында Шәрык алынмалары зур төркемне тәшкил итә: *башмак, кафтан, колпак, кушак, чулки, штаны* һ.б. Алар бу вакытка инде үзләштерелгән гомумрус лексикасына караган. Көнкүреш лексикасы рәтендә түбәндәге ориентализмнарны билгеләп үтәргә мөмкин: *ковер*, *пьяля* «пиала», *хамъян* «карман», *чирак* «шәмдәл», *чихир* «көчле шәраб». Шәрык сүзләренең күбесе социаль мөнәсәбәтләр өлкәсе белән бәйләнгән (*бек* «төрки халыкларда югары дәрәҗәле түрәләр титулы», *дорога* «хөкүмәт чиновнигы», *салтан*, *тюфянчей* «укчы», *хан*, *шах*): *«И выедет дорога, а по нашему городовой боярин»* [Хожение…, с. 49].

Котов әсәрендә табылган кайбер Шәрык алынмалары дин өлкәсенә карый. Бу – башлыча гарәп чыгышлы сүзләр. Алар арасында руханиларның (*абдал* «дәрвиш, монах», *мулла,* кешит/кешиш «рухани»), дога («Фатха» «Әл-Фатиха» – Коръәннең беренче сүрәсе), мөселман бәйрәмнәренең (*байрам рамазан*, *байрам курбан, баирам наурус*) атамалары. Мәсәлән: *«Первой у них праздник год починают марта месяца, как в небе увидят млад месяц. И тот у них праздник зовут баирам наурус, а по нашему новои год»* [Хожение…, с. 47].

Шунысын да билгеләп үтү мөһим: генетик состав (чыганак тел) күзлегеннән караганда, әсәрдәге фарсылар тормышының сәүдә, көнкүреш һ.б. аспектларын тасвирлаган Шәрык алынмаларын күбесенчә төрки-татар чыгышлы сүзләр тәшкил итә. Чагыштыр, мәсәлән, *байрам* «бәйрәм», *башмак, бек, казна, киндяк* «киҗе-мамык тукыма», *колпак, миткаль* «юка тукыма», *тюфянчей, чулки, шал* «тукылган зур яулык», *чирак* тюркизмнары, алар арасында *ковер, шатер, штаны* һ.б. кебек борынгы төрки алынмалар аерылып тора. Мәсәлән: *«А жонки ходят закрывшися в тонкие миткали… А у всех жонок штаны и у девок»* [Хожение…, с. 55].

Алынма шәркый сүзнең телгә үтеп керү ысуллары һәм алымнары төрле булырга мөмкин. Ул еш кына рус теленә тәрҗемәсе белән бергә бирелгән: *«А у обоих ворот стоят беки да тюфянчеи, а по рускому дети боярские да стрелцы»* [Хожение…, с. 42]. Чит тел лексемасының мәгънәсе ул аңлаткан чынбарлыкны тасвирлау аша да ачыла: *«По обе стороны поделаны полаты каменные, а зовут кафы»* [Хожение…, с. 43]. Котов еш кына Шәрык алынмаларын чагыштыру ярдәмендә аңлаткан: «*А по обе стороны татарские юрты, чтобы наши русские деревни*» [Хожение…, с. 31]. Кайвакыт алынма сүзләр аңлатылмаган, һәм укучы ориентализмның мәгънәсен контекстка таянып кына чамалый алган. Чагыштыр: *«Собралися весь народ на майдан против шаховых болших ворот, а все с куфшины, и с пьяли, и с чарки»* [Хожение…, с. 48].

Шулай итеп, Котов Фарсы патшалыгына сәяхәтен бәян итеп, Шәрык дәүләте чынбарлыгының төрле якларын – социаль, көнкүреш,

дини тормышын характерлап бирә. Ореньализмнарның тематик һәм тел ягыннан төрлелеге, шулай ук әсәр текстында аларны шәрехләү ысуллары, бер яктан, авторның Шәрык дөньясын ничек кабул итүе, аның белеме һәм сәяхәт кылу максатлары турында сөйли, ә икенче яктан, сәяхәтнамә жанрының стилистик үзенчәлеге булып тора. Шул ук вакытта Котов XVII гасырның беренче чирегендә рус теленең лексик системасына инде кереп урнашкан Шәрык алынмаларын (*башмак*, *казна*, *ковер*, *товар* һ.б.) куллана. Сәяхәттә Шәрык дөньясының милли үзенчәлекләрен характерлаган ориентализм-экзотизмнар (*абаса*, *кешиш*, *рахтан*, *тюфянчей* һ.б.) аерым культурологик кыйммәткә ия. Мондый эквивалентсыз сүзләр, башка этносның (бу очракта фарсыларның, Фарсы иле территориясендә яшәүче башка халыкларның) чит реалияләрен һәм төшенчәләрен билгеләп, реципиент тел системасында ассимиляцияләнмәгән килеш калган, аның пассив лексикасы составында гына сакланган.

**Әдәбият**

*Дмитриев Н.К.* О тюркских элементах русского словаря // Лексикографический сборник. М.: ГИС, 1958. Вып. 3. С. 3–47.

Проскинитарий Арсения Суханова // Православный палестинский сборник. СПб., 1889. Т. 7. Вып. 3. С. 3–300.

Словарь русского языка XI–XVII вв. Вып. 9. М.: Наука, 1982. 357 с.

*Федоркова И.Р.* Образ русского купца: стереотипы и реальность // Научные труды Московского университета. 2019. № 5. С. 49–72.

Хожение гостя Василья 1465–1466 гг. // Православный палестинский сборник. СПб., 1896. Т. 2. Вып. 3. С. 1–25.

Хожение купца Федота Котова в Персию. Публикация Н.А. Кузнецовой. М.: Изд-во восточной литературы, 1958. С. 25–60.

***Гыйләҗетдинова Гөлинә Хәйретдин кызы,***
*филология фәннәре докторы, профессор,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*ареаль лингвистика бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 811.512.145’367

*Л.Г. Хәбибуллина*

# ТАТАР ТЕЛЕНДӘ *-ЫП/-ЕП, -П* ҺӘМ *-ГАЧ/-ГӘЧ, -КАЧ/-КӘЧ* КУШЫМЧАЛЫ ХӘЛ ФИГЫЛЬ БЕЛӘН БЕЛДЕРЕЛГӘН СЕМАНТИК-СИНТАКСИК МӨНӘСӘБӘТЛӘР

Статья посвящена исследованию выражения смысловых отношений при помощи деепричастных форм в татарском языке. Особое внимание акцентировано на выявлении глубинной семантической составляющей синтаксических категорий, синкретизма семантико-синтаксических отношений. Материал для исследования привлекался из текстов татарской художественной литературы, малых жанров татарского фольклора. Установлено, что деепричастные формы на *-ып/-еп, -п* и *-гач/-гәч, -кач/-кәч* могут выражать временные, причинно-следственные, условные и уступительные отношения, образовать синкретичные значения.

**Ключевые слова:** деепричастие, темпоральная, каузальная, уступительная семантика, синкретичная семантика, татарский язык.

The article is devoted to the study of the expression of semantic relations using adverbial forms in the Tatar language. Special attention is focused on identifying the deep semantic component of syntactic categories, syncretism of semantic-syntactic relations. The material for the study was taken from the texts of Tatar fiction, small genres of Tatar folklore. It is established that the adverbial forms on -*yp/-ep, -p* and -*gach, -kach* can express temporal, causal, conditional and concessive relations, form syncretic meanings.

**Keywords:** adverbial participle, temporal, causal, concessive semantics, syncretic semantics, Tatar language.

«Татар грамматикасы»нда хәл фигыльгә түбәндәге билгеләмә бирелгән: «Хәл фигыль – ул фигыльнең эш-хәлне башка бер эш-хәлгә мөнәсәбәттә белдерүче махсус формасы» [Татар грамматикасы, 2016, б. 246]. Аның формалары ярдәмендә төрле мәгънәви мөнәсәбәтләр белдерелә. Әлеге мәкаләдә *-ып/-еп, -п* һәм *-гач/-гәч, -кач/-кәч* кушымчалы хәл фигыль белән белдерелгән семантик-синтаксик мөнәсәбәтләр өйрәнелә. Мәкаләнең фәнни яңалыгы шуннан гыйбарәт: моңа кадәр татар тел белемендә, башлыча «Татар грамматикасы» хезмәтендә, мәгънәви мөнәсәбәтләргә урын бирелсә дә, синкретик мәгънәле синтаксик берәмлекләрне өйрәнү игътибардан читтә кала бирде. Хәл фигыльнең өйрәнелә торган формалары белән төрле мәгънәләр белдерелү шактый тулы яктыртылуга карамастан [Татар грамматикасы, 2016, б. 249–253], сәбәп-нәтиҗә һәм вакыт, шарт һәм вакыт семантикасының үзара керешүе, ягъни синкретик каузаль-темпораль һәм синкретик кондициональ-темпораль мәгънәләр барлыгы күрсәтелми, аерып чыгарылмый.

Синкретизмны, ягъни бер синтаксик конструкциядә төрле мөнәсәбәтләрнең дифференциаль билгеләренең керешүен өйрәнү арадаш мәгънәви мөнәсәбәтләрнең асылын ачыкларга ярдәм итә. Әлеге тикшеренү лингвистик структур-семантик алым кысаларында, системалы рәвештә В.В. Бабайцева [Бабайцева, 2000] тарафыннан эшләнгән синхрон күчеш (синкретизм) теориясенә нигезләнеп үткәрелде. Бу теория М. Фуко, Дж. Холтон, Н. да Коста, Н. Васильев, Н. Бор, Л. Заде һ.б. фәлсәфи идеяләренә нигезләнә һәм логик яктан Л.В. Щербаның системаларны төп төшенчәләр һәм башка төшенчәләргә хас өстәмә төсмерләр дә булган әйләнмәләр формасында күзаллаган фикерләрен дәвам итә.

Үткәрелгән тикшеренүдән күренгәнчә, татар телендә *-ып/-еп, -п* кушымчалы хәл фигыль иң күпмәгънәле булып тора. Аның төп семантикасы бер күренешнең икенче күренештән алда яки бер-берсе белән бер үк вакытта булуын күрсәткән таксис мәгънәсен белдерүдән гыйбарәт. Мәсәлән: *Соңыннан минем абый ниндидер ике еллык курслар бетер**еп**, юрист булып китте* (Ә. Еники. Вөҗдан) (әлеге мисалда бер күренешнең икенче күренештән алда үтәлүе белдерелә); *...Тын, якты авыл өстенә кара**п**, булачак очрашу турында уйлан**ып** барам* (Ә. Еники. Вөҗдан) (бер-берсе белән бер үк вакытта булган процесслар белдерелә). Гомумән, лингвистик хезмәтләрдә хәл фигыль бәйле таксис формасы буларак билгеләнә [Типология..., 2009, с. 15].

*-ып/-еп, -п* кушымчалы хәл фигыль ярдәмендә эшнең үтәлү рәвеше мәгънәсе белдерелә. Мәсәлән: *Йокы күптән качкан, тән җиңеләеп киткән, аяклар үзләреннән-үзләре ашыг**ып**, рәхәтлән**еп** атлыйлар* (Ә. Еники. Вөҗдан); *Юл буенча үземне тиргә**п** кайттым* (Ә. Еники. Вөҗдан).

Әлеге формадагы бер үк хәл фигыльнең кабатлануы процессның интенсивлыгы, дәвамлылыгы семантикасын күрсәтә. Мәсәлән: *...Хафазамны кыста**п**-кыста**п** сыйларга тотындым* (Ә. Еники. Вөҗдан).

Тикшерелә торган кушымчалы хәл фигыль белән каузаль семантика, максат, кире шарт мәгънәсе дә ассызыклана. Анализ барышында ачыкланганча, сәбәп-нәтиҗә мөнәсәбәтләре булганда, хәл фигыль белән эш-хәлне үтәүченең психо-эмоциональ, физиологик халәте белдерелә. Кагыйдә буларак, мондый конструкцияләрдә контрольдә тотып булмаган нәтиҗәләргә китергән сәбәпләр күрсәтелә. Мәсәлән: *Албуга уңайсызлан**ып** кып-кызыл булды* (Н. Фәттах. Сызгыра торган уклар); *Кырда кулын ярала**п**, эшкә чыга алмаган* (Г. Сабитов. Өч күңел); *Радиола кыз**ып**, өйгә резин исләре чыккан иде* (Х. Сарьян. Паку!..); *Килмәгән болыттан курк**ып**, чатыр кормыйлар* (Мәкаль); *Тапмаган малга ышан**ып**, кулдагын бетерү ахмаклык* (Мәкаль); *Шуннан соң гармунчы Салих күренмәде. Ул, үзенең җиңелүенә үртәл**еп**, уеннан бөтенләй киткән иде бугай* (М. Хуҗин. Ак колын); *Ул ирен беренче кабат, үч ит**еп** алдады* (Х. Сарьян. Тукран тәүбәсе).

Кайбер җөмләләрдә сәбәп-нәтиҗә һәм вакыт семантикасының үзара керешүе күзәтелә. Сәбәп, барлыкка китерүче фактор буларак,

вакыт буенча нәтиҗәдән алда үтәлә. Еш кына кушма җөмләнең ике компонентлы хәбәре дә бер үк вакыт формасында була, әмма җөмлә семантикасыннан вакыйгаларның бер-бер артлы үтәлүе аңлашыла. Гомумән, каузаль һәм темпораль семантика синкретизмы башка хәл мөнәсәбәтләре арасында аеруча еш очрый. *-ып/-еп, -п* кушымчалы хәл фигыль белән белдерелгән каузаль-темпораль конструкцияләрдә вакыйгаларның бер үк вакытта үтәлүе күрсәтелә. Мәсәлән: *Битарафлыкны күр**еп** борчылам*. Әлеге җөмләдә берьюлы ике семантика кушылган: *Битарафлыкны күргәнгә борчылам* (сәбәп-нәтиҗә) һәм *Битарафлыкны күргәч борчылам* (вакыт).

Хәл фигыль белән максат мәгънәсе белдерелгәндә, эш-хәлнең билгеле бер максат белән аңлы рәвештә үтәлүе семантикасы тапшырыла. Мәсәлән: *Ул, дәрес хәзерләргә җыен**ып**, өстәл артына утырды; Әнкәй, бәлеш пешерергә җыен**ып**, мичкә ягып җибәрде* (Р. Вәлиев. Иске сәгать дөрес йөри).

Әлеге мисалларда процесс субъектларының конкрет ниятләре күрсәтелә: ул өстәл артына билгеле бер максат белән утыра; бәлеш пешерү максаты белән мичкә ягып җибәрә. Моннан тыш җөмләләрдә ‘җыенып’ дигән сүз бар, максат семантикасын белдергәндә, иярчен предикациянең лексик мәгънәсе мөһим роль уйный. Шулай итеп, ике вакыйга арасындагы мәгънәви мөнәсәбәт хәл фигыль белән генә түгел, ә нәкъ менә процесс субъектының теләген белдерүче ‘җыенырга’ фигыленең хәл фигыль формасы белән белдерелә.

А.Р. Губанов билгеләгәнчә, теләк, субъектның мәҗбүри булмаган барлык ирекле эшчәнлегенең мотивы булып, кеше психикасы атрибутлары системасы үзәгендә тора, «теләк» концепты мөмкинлек сыйфатында була [Губанов, 2016, с. 62].

*-ып/-еп, -п* кушымчалы хәл фигыль кире шарт конструкцияләрендә дә кулланыла ала. Бу, гадәттә, мәкальләрдә еш очрый. Мәсәлән: *Кырык ел көтү көт**еп**, чыбыркы шартлата белмәгән; Ишәк юргала**п** бәйге алмас; Яңгырдан кач**ып**, дәрьяга төшкән.*

Мондый конструкцияләрдә кире шарт семантикасы *та/тә, да/дә* кисәкчәсе белән дә ныгытыла ала. Мәсәлән: *Хәер, аның начар укы**п та**, шәп сөйләүче булуына артык исем китмәде* (Ә. Еники. Вөҗдан).

*-ып/-еп, -п* кушымчалы хәл фигыль *-мыйча/-мичә* (*-мый/-ми*) юклык формасында да кулланыла. Мәсәлән: *Атның, яңа киемгә күнегә ал**мыйча**, тәне чымырдап торды* (М. Хуҗин. Кубыз); *Ташкын көченә түзә ал**мыйча**, тегермән буасы ерылган* (Н. Әхмәдиев. Мөнирстан); *Егет авыртуына түзә ал**мый** ыңгырашып куйды* (Р. Сибат. Инабәт). Әлеге мисалларда сәбәп-нәтиҗә мәгънәсе белдерелә.

Түбәндәге җөмләләрдә темпоральлек күрсәтелә. Мәсәлән: *Идел кич**мичә**, аягыңны киптермә* (Мәкаль); *Кич бул**мыйча**, бүгенге көнне мактама* (Мәкаль).

Мондый төр конструкцияләрдә темпоральлек төсмерле кондициональ мәгънә дә күрсәтелә ала. Мәсәлән: *Аю күр**мичә**, айга сикермиләр* (Мәкаль); *Кыйнал**мый**, бирәү дә сый алмый* (Мәкаль);

*Гөнаһ кыл**мый** тәүбә итмисең* (Мәкаль); *Үзең шатлана бел**мичә**, башкаларны сөендерә алмыйсың шул...* (М. Хуҗин. Кеше күңеле – үзе бер кояш).

Фигыльнең шарт формасының шарт-вакыт мәгънәсен белдерүе – гомумтөрки үзенчәлек, ул борынгы төрки язма истәлекләрдә үк күзәтелә. М. Эрдальнең «Борынгы төрки тел грамматикасы»нда («Грамматика древнетюркского языка») билгеләнгәнчә, *-sar* формасының төп мәгънәсе – шарт семантикасы, әмма мондый конструкцияләр темпораль мөнәсәбәт тә (бу очракта аффикс үзе 'кайчан' дип тәрҗемә ителә), кире шарт бәйләнешен дә белдерә ала [Erdal, 2004, с. 480; 484]. Мәсәлән: *Taydyn jynaq(qa) kör**sär** m(ä)n tör tä ärklig qan olurur.* 'Кайчан мин өскә карадым, алда Эрклигхан утырганын күрдем' [Исследования…, 1961, с. 215].

Табигате буенча синкретик булган шарт-вакыт мәгънәсе структур яктан паремиологик системада ныгыган. Паремияләрдә һәм гомумиләштергән әйтелмәләрдә кондициональ конструкция компонентлары мөнәсәбәтләренең абстракт вакытлы характеры күзәтелә. Мондый җөмләләрдә хәзерге яки киләчәк заман формасы кулланылса да, фраза үзе вакытка бәйле булмаган характерда, гомуми закончалык рәвешендә була, типик күренешләргә ишарәли, вакыт семантикасы исә даимилек мәгънәсен белдерү белән бәйле була.

Күргәнебезчә, *-п* формалы хәл фигыль контекстуаль, чөнки конструктив, лексик, контекстуаль, экстралингвистик факторларга бәйле рәвештә таксис мәгънәсен генә яки өстәмә рәвештә хәл мәгънәләренең берсен дә белдерә ала. Соңгы очрак булганда, таксис мәгънәсе төп мәгънә булудан туктый һәм нибары фонга әверелә [Типология..., 2009, с. 768].

*-гач/-гәч, -кач/-кәч* кушымчалы хәл фигыль, кагыйдә буларак, вакыт мөнәсәбәтен күрсәтә. Мәсәлән: *Суның кадере чишмә кыры**гач** беленә* (Мәкаль); *Ат урлан**гач**, абзар ныгытмыйлар* (Мәкаль). М.З. Зәкиев билгеләгәнчә, «*-гач* кушымчалы хәбәрле иярчен җөмлә барлык формасында булганда, баш җөмләдәге эш-хәл башланганчы тәмамлана торган процессны белдерә» [Закиев, 1995, с. 441].

Өйрәнелә торган формалы хәл фигыль алдан булган эш-хәлне, процессларның бер-бер артлы булуын белдерә. Мәсәлән: *...Дәрес бет**кәч**, артык бер минут та тормыйча, китеп тә бара* (Ә. Еники. Гөләндәм туташ хатирәсе); *Арба ватыл**гач**, юл күрсәтүче күп булыр* (Мәкаль); *Теш чык**кач**, бала еламый* (Мәкаль).

Хәл фигыльләр белән билгесез бер-бер артлы үтәлү белдерелә, процесслар арасындагы вакыт интервалы дифференцияләнми, контекст буенча яки лексик-грамматик конкретизаторлар булу белән билгеләнә. Мәсәлән, *-гач/-гәч, -кач/-кәч* кушымчалы хәл фигыльнең *ук/үк, да/дә, та/тә* көчәйткеч кисәкчәләр белән килүе эш-хәлнең тизлеге, кинәтлеге, моментальлеге мәгънәсен көчәйтә. Мәсәлән: *Кинодан чык**кач та**, мин туры Вафага киттем* (Ә. Еники. Вөждан); *Эштән кайт**кач та**, һичнигә карамыйча, иң элек юынып, өстен алышты-*

*ру – бу аның көндәлек кагыйдәсе* (Ә. Еники. Вөждан). Гадәттә, алдан булган эш-хәл, сирәгрәк бер үк вакытта булган вакыйгалар күрсәтелә ала. Мәсәлән: *Аның янында эшли башла**гач**, мин башта бик аптырый идем...* (Ә. Еники. Вөждан).

*-гач/-гәч, -кач/-кәч* кушымчалы хәл фигыль сәбәп-нәтиҗә конструкцияләрендә дә кулланыла ала. Бу очракта хәл фигыль белән өстәмә эш-хәлдә күрсәтелгән сәбәп белдерелә. Мәсәлән: *Күздән нурны, ә йөрәктән рухны берничек тә ала алма**гач**, чишендереп, дымлы камерада калдырдылар безне ялангач* (Р. Харис. Җәлилчеләр); *Әтиләренә сүзе үтмә**гәч**, шул тәкъдимен әнисе Мирсәет аша һәм аның апалары аша әйттерергә омтыла иде* (Р. Мөхәммәдиев. Сират күпере).

Күпчелек очракта алар гади җөмләне катлауландыручы аерымланган кисәк тәшкил итә, аерымланган хәл синтаксик функциясен башкара. Мәсәлән: *Мин үзем, гомер буе ялгыз яшәгән кеше бул**гач**, аш-суга тәмам өйрәндем диярлек* (Ә. Еники. Вөждан). Әлеге мисалда төп процесс – *өйрәндем* фигыль хәбәр белән белдерелгән. Төп эш-хәлдән алда булган һәм аның сәбәбен тәшкил иткән өстәмә процесс – *ялгыз яшәгән кеше булгач*, хәл фигыль белән белдерелгән.

Вакыт һәм сәбәп-нәтиҗә мөнәсәбәтләрен аерудагы кыенлык башлыча темпоральлек күрсәткече булган *-гач/-гәч, -кач/-кәч* кушымчалы хәл фигыльнең каузаль конструкцияләрдә дә кулланылу мөмкинлеге белән дә бәйле. Шуны да искәртергә кирәк: хәл фигыль составында юклык кушымчасы булганда, әлеге форма белән һәрвакыт каузальлек белдерелә. Мәсәлән: *Стипендия алып укы**<u>ма</u>гач**, Сәгыйтьнең матди хәле бик мөшкел була* (Р. Мөхәммәдиев. Сират күпере); *Буш вакытың бул**<u>ма</u>гач**, ял итәргә өлгермисең*; *Ләкин озак еллар күреш**<u>мә</u>гәч**, мондый дуслык та әкренләп суына, сүнә бара, әмма бөтенләй үк онытылмый...* (Ә. Еники. Вөждан).

Шулай да хәл фигыль барлык формасында булганда да сәбәп-нәтиҗә мөнәсәбәте күрсәтелә ала. Мәсәлән: *Хәер, авылдан читтә яшә**гәч**, һәркемне дә хәтергә төшерергә җае да чыкмагандыр* (М. Хуҗин. Кубыз); *Ял көне бул**гач**, иртә торасы юк; ...Кул куйдыр**гач**, бирәү дә китмәгән* (Ә. Еники. Вөждан); *Үзең койты бул**гач**, көзгене хурлама* (Мәкаль).

*-гач/-гәч, -кач/-кәч* кушымчалы хәл фигыльле конструкцияләрдә синкретик каузаль-темпораль мәгънә дә белдерелә ала. Мәсәлән: *Читлеккә эләк**кәч**, ерткыч та юашлана* (Мәкаль). Җөмләнең мәгънәсен болай аңлатырга була: *Ерткыч читлеккә эләгә, шуңа күрә юашлана* яки *Читлеккә эләккәннән соң, ерткыч та юашлана. Кешенең, акылы камилләнгә**ч**, сүзе азая* (Мәкаль), ягъни *Кешенең, акылы камилләнгәннән соң* (яки *акылы камилләнгәнгә*), *сүзе азая. Бу чорда, сугыштан кайткан егетләр гаилә корып җибәр**гәч**, кичке уеннарда егетлек вазифасы тугызынчы-унынчы класс укучыларына төште* (М. Хуҗин. Йолдызлардан ары – йолдызлар), ягъни *Егетләр гаилә корып җибәргәннән соң* (яки *гаилә корып җибәргәнгә*).

Каузаль-темпораль синкретизмны белдерүнең мондый юлы шактый еш очрый. Мәсәлән: *Эшләр болай булып кит**кәч**, минем Казанда һич каласым килми башлады* (Ә. Еники. Вөҗдан); *Бала-чага арт**кач**, сәке тактасы тарая* (Мәкаль); *Тавис, тәпие ямьсезлеген күр**гәч**, койрыгы белән каплаган* (Мәкаль); *Мамыгын бушат**кач**, юрганым бар дип хыялланма* (Мәкаль).

*-гач/-гәч, -кач/-кәч* кушымчалы хәл фигыльдә вакыт семантикасының сәбәп мәгънәсенә күчүен академик М.З. Зәкиев тә билгели [Татар грамматикасы, 2017, б. 364].

А.Р. Губанов билгеләгәнчә, каузаль конструкцияләрнең синкретизмы әлеге структураларның сыгылмалылыгын дәлилли, бу аларның төрле мәгънәләрне берләштерү мөмкинлегендә чагыла [Губанов, 2016, с. 28].

Вакыт планында нәтиҗә һәрвакыт сәбәптән соң яки сәбәп белән бер үк вакытта була. Шулай итеп, каузальлек темпоральлек белән тыгыз бәйләнгән. Сәбәп-нәтиҗә мөнәсәбәте – компонентларның эчке бәйлелеге, ә вакыт мөнәсәбәте – тышкы бәйлелек икәнен исәпкә алырга кирәк.

Кагыйдә буларак, вакыт семантикасын белдерә торган *-гач/-гәч, -кач/-кәч* кушымчалы хәл фигыль шарт мәгънәсен дә белдерә ала. Мәсәлән: *Гөлен ярат**кач**, тикәнен дә ярат* (Мәкаль); *Белмә**гәч** – язмагыз* (Т. Миңнуллин. Моңлы бер җыр); *Боткасын пешер**гәч**, маен җәлләмә* (Мәкаль); *...Телә**гәч** сынасыннар* (Р. Миңнуллин. Әнкәйләр тәрбиясе).

Мондый төр конструкцияләрдә, кагыйдә буларак, синкретик кондициональ-темпораль семантика белдерелә. Мәсәлән: *Җиле бул**гач**, бураны булыр* (Мәкаль). (*Җиле булса, бураны булыр* яки *Җиле булган вакытта, бураны булыр* дип аңлашыла); *Чын күңелдән ела**гач**, сукыр күздән яшь чыгар* (Мәкаль); *Угын ат**кач**, җәясен яшермә* (Мәкаль).

Үткәрелгән тикшеренү нәтиҗәләре күрсәткәнчә, *-ып/-еп, -п* һәм *-гач/-гәч, -кач/-кәч* кушымчалы хәл фигыль контекстка бәйле рәвештә төрле мәгънәви мөнәсәбәт белдерә ала. Темпоральлекнең төп квалификаторы булсалар да, алар каузаль, кондициональ, кире шарт һ.б. мөнәсәбәтләрне белдерүдә дә актив кулланылалар, кайвакыт синкретик каузаль-темпораль, кондициональ-темпораль семантика хасил итәләр.

Болар барысы да татар телендәге күп мәгънәви мөнәсәбәтләр грамматик бирелеше буенча түгел, ә семантик эчтәлеге белән аерыла, дип әйтергә мөмкинлек бирә.

**Әдәбият**

*Бабайцева В.В.* Явления переходности в грамматике русского языка. М.: Дрофа, 2000. 640 с.

*Губанов А.Р.* Каузальность в ментальной организации национальной картины мира (на материале русского и чувашского языков) / А.Р. Губанов, Н.И. Рец. Чебоксары: Изд-во Чуваш. ун-та, 2016. 136 с.

*Дружинина С.И.* Синкретизм в системе сложноподчиненных предложений. Орел: Изд-во Орел ГАУ, 2008. 435 с.

*Закиев М.З.* Татарская грамматика. Т. III: Синтаксис. Казань: ИЯЛИ АНТ, 1995. 576 с.

Исследования по сравнительной грамматике тюркских языков. Ч. III. Синтаксис / под общ. ред. Н.К. Дмитриева, Н.А. Баскакова, Е.И. Убрятовой. М.: Изд-во АН СССР, 1961. 232 с.

Татар грамматикасы: өч томда / проект җит. М.З. Зәкиев. Т. II. Тулыландырылган 2 нче басма. Казан: ТӘһСИ, 2016. 432 б.

Татар грамматикасы: өч томда / проект җит. һәм автор М.З. Зәкиев. Т. III. Тулыландырылган 2 нче басма. Казан: ТӘһСИ, 2017. 536 б.

Типология таксисных конструкций / отв. ред. В.С. Храковский. М.: Знак, 2009. 906 с.

*Erdal Marcel.* A grammar of Old Turkic. Leiden; Boston; Brill, 2004. XII, 575 p.

***Хәбибуллина Лениза Газинур кызы,***
*филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының ареаль лингвистика бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 811.512.145

***М.З. Вәлиева***

# XVII–XVIII ГАСЫР ИСКЕ ТАТАР ЯЗМА ИСТӘЛЕКЛӘРЕНДӘ ТУГАНЛЫК ТЕРМИННАРЫ

Статья посвящена изучению лексико-стилистических особенностей функционирования терминов родства в старотатарских письменных источниках XVII–XVIII веков. Данные лексические единицы в указанных текстах выполняют различные функции. Большинство из них выражают не только родственные и семейные отношения, но и социальные. Все это позволяет утверждать, что термины родства также представляют собой тот языковой материал, который носит в себе этнокультурный код татарского народа.

**Ключевые слова**: письменные источники, старотатарский письменный литературный язык, лексика, стилистика, термины родства.

The article is devoted to the study of lexical and stylistic features of the functioning of kinship terms in the Old Tatar written sources of the XVII–XVIII centuries. These lexical units in these texts perform various functions. Most of them express not only kinship and family relationships but also social ones. All this allows us to assert that the terms of kinship also represent the linguistic material that carries the ethnocultural code of the Tatar people.

**Keywords:** written sources, Old Tatar written literary language, vocabulary, stylistics, kinship terms.

Туганлык атамалары кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне генә түгел, ә җәмгыятьтә барган тарихи-иҗтимагый процессларны, гасырдан гасырга күчеп килә торган гореф-гадәтләрне дә чагылдыралар, буыннар арасындагы мөнәсәбәтләр, милләтнең дөньяга карашы турындагы этномәдәни мәгълүмат чыганагы булып торалар. Туганлык атамаларының язма текстлардагы кулланылыш үзенчәлекләрен тикшерү халыкның тел һәм мәдәни үзенчәлекләрен тирәнрәк ачарга булыша, кешене дөньяның үзәгендә торган зат буларак бәяләргә, татар халкының дөньяга карашын ачыкларга ярдәм итә. Бу җәһәттән, Мәүла Колый хикмәтләре, билгесез автор тарафыннан язылган «Дәфтәре Чыңгызнамә», Мөслиминең «Тәварихе Болгария», фарсы теленнән тәрҗемә ителгән «Мәҗмүгъ әл-хикәят» кебек XVII–XVIII гасыр язма истәлекләрендә кулланылган башка төр ономастик һәм лексик берәмлекләрне тикшерү белән бергә [Валиева, 2017, 2022], аларда туганлык атамаларының кулланылыш үзенчәлекләренә лексик-стилистик яктан анализ ясау да зур әһәмияткә ия.

Төрки тел белемендә туганлык терминнары, аларның формалашу тарихы узган гасыр урталарыннан ук тел галимнәренең хезмәтләрендә чагылыш таба. Л.А. Покровская, Э.В. Севортян, В.И. Цинисус һ.б. галимнәрнең хезмәтләрендә төрки телләрдә туганлык атамаларының

формалаша башлавы, аларның этимологиясе, бу терминнарга хас гомуми үзенчәлекләр һ.б. мәсьәләләр анализлана [Покровская, 1961; Севортян, 1974; Цинисус, 1972]. Татар телендә исә туганлык атамалары диалектолог-галим Д.Б. Рамазанова тарафыннан монографик планда тикшерелә. Ул үзенең хезмәтләрендә туганлык терминнарының килеп чыгышын, хәзерге әдәби телдә кулланылыш үзенчәлекләрен, аларның теге яки бу диалекттагы вариантларын һ.б. өйрәнә [Рамазанова, 1991; 2014]. Туганлык атамалары галимнәр тарафыннан иске татар язма истәлекләренең сүзлек хәзинәсен, метрика кенәгәләрен тикшерү барышында да игътибарга алына [Зайнуллина-Маннапова, 1988, с. 27–34; Алеева, 1989, б. 23–96; Хисамиева, 1990, б. 62–69; Хисамова, 1999, б. 162; Кадирова, 2021, б. 7–15 һ.б.]. Әлеге лексик берәмлекләрне өйрәнү хәзерге татар тел белемендә дә дәвам итә. Бүген галимнәр игътибарын туганлык атамаларының сүзлекләрдә бирелеше, халык авыз иҗаты текстларында кулланылышы кебек проблемалар җәлеп итә [Денмухамметова, Юсупова, 2012, с. 62–65; Нурмухамметова, Мугтасимова, 2019, с. 172–175].

Галимнәр фикеренчә, тарихи яктан караганда, туганлык белән бәйле атамалар беренче булып формалаша башлаган һәм әлеге лексик берәмлекләр күпчелек төрки телләр өчен уртак булып тора. Алар арасыннан XVII–XVIII гасыр язма истәлекләрендә *ир, хатын, ата, ана, баба, ага* һ.б. кебек киң кулланылышка ия лексик берәмлекләр очрый. Әлеге туганлык атамалары ике зур төркемгә бүлеп тикшерелде.

**1. Никах туганлыгы атамалары.** *Ир* – төрки-татар сүзе. Безнең тарафтан тикшерелгән чыганакларда әлеге лексик берәмлекнең семантикасына салынган туганлык-никах төшенчәләре, нигездә, *иргә бирү, үз ире, ир углан* кебек сүзтезмәләрдә чагылыш таба. Мәсәлән, *иргә бирү* сүзтезмәсе аша кыз баланы ‘кияүгә бирү, башлы-күзле итү’ мәгънәсе белдерелә: *Имде моны бу йирдә иргә биреб булмас, аның өчен адәм углы шайтан берлән бәрабәрдер* [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 70].

*Ир йөзе* сүзтезмәсе исә «Дәфтәре Чыңгызнамә» әсәрендә ир-атларны, аларга хас сыйфатларны гомумиләштереп, җыйнап атап кына калмый, хатын-кызның каршы җенес вәкиленә мөнәсәбәтен, күпмедер дәрәҗәдә хис-кичерешләрен дә чагылдырып килә: *Гомеремдә ир йөзен күргәнем йук торыр, бу көн кич сине күрдем, – тиде* [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 70].

*Ир углан* сүзтезмәсе язма истәлекләрдә ‘ир бала, малай кеше’ төшенчәсен чагылдыра: *Андин йәнә бер анча көнләрдән соң мескин тезләб игән ул хатын күзе йарылды, бер ир углан тугырды* [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 82].

Алга таба *ир* лексемасының *үз ире* сүзтезмәсе составында килүе хәзерге татар әдәби телендә дә, шулай ук язма чыганакларда да ‘хатынның бергә тормыш итә торган иптәше, хәләл җефете’ төшенчәсен аңлата: *Кызның башын күтәрде, бакды, үз хатынын та-*

*ныды wә хатыны белде: үз ире торыр* [Мәҗмүгъ әл-хикәят, 1963, б. 520].

*Хатын* – төрки-татар сүзе. XVII–XVIII гасыр иске татар язма чыганакларыннан тупланган фактик материалда әлеге лексик берәмлекнең сүзлекләрдә теркәлгән ‘ир җенесенә капма-каршы җенестәге кеше’ мәгънәсе очрамый дисәк тә, ялгышмабыз. Чыганакларда бу берәмлек барыннан да бигрәк ‘ир хатыны’ төшенчәләрен белдереп килә: *Бикчура ханның унике wәзире илән башларын кистерде, қызларын wә хатынларын қол итеб, ғаскәрләренең рәисләренә бирде* [Мөслими, 1999, б. 45]; *Бу пәри қызының хөсен wә җәмалының ләтафәтидин тәмам хатынларын wә кәнизәкләрен оныттды, чөн бу нәүғы зиба йуқ ирде* [Мәҗмүгъ әл-хикәят, 1963, б. 507].

Кагыйдә буларак, *хатын* лексемасының да семантикасы сүзтезмәләр составында тагын да киңәя. Текстларда безнең тарафтан әлеге лексик берәмлеккә зат алмашлыгы һәм тартым кушымчасы өстәлеп тә ‘гаилә корган ир хатыны’ төшенчәсе белдерелү очраклары теркәлде, биредә ирнең хатынына карашы, мөнәсәбәте дә чагылыш таба: *Минем алған хатыным Аланғуым берлә бергә үләрем дигән ирдем...* [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 71].

‘Никахлы тормыш иптәше’ мәгънәсе чыганакларда *үз хатыны* сүзтезмәсе ярдәмендә дә җиткерелергә мөмкин: *Қызның башын күтәрде, бақды, үз хатынын таныды wә хатыны белде: үз ире торыр* [Мәҗмүгъ әл-хикәят, 1963, б. 520].

Алга таба «Тәварихе Болгария» әсәрендә *хатын* лексик берәмлеге гарәби чыгышлы *хәмилә* сүзе белән бергә кулланылып, ‘бала көткән көмәнле хатын’ төшенчәсен белдерә: *Өченче бармағы ишарәтдер, хамилә хатынлар wә хайwанатлар хәмелендә уланлар иркәкме йа тешиме, қарамы-қызылмы булмақларыны Аллаһы Тәғаләдән ғайре белмәсләр* [Мөслими, 1999, б. 17].

‘Кияүдәге хатын’, ‘ирнең никахлы никахлы’ төшенчәләре текстларда фарсы чыгышлы *җефет, хәләл җефет* лексемалары ярдәмендә бирелә: *Хәләл җефет булғалы мондайын ойат эш килгәне йуқ ирде, қызымызға бер бәла булыбдыр, нә қылсайық булыр? – диде* [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 70].

*Хатын* лексемасына синоним буларак кулланыла торган *җефет* берәмлеге *җефет булу, хәләл җефет булу* сүзтезмәләре составында килеп, кияүгә чыгу мәгънәсен чагылдыра: *Бәлқыйс, падишаһлыққа ултырыб, ғақыйбәт Сөләйман пәйғамбәрнең җефете булды* [Мәҗмүгъ әл-хикәят, 1963, б. 512].

Ә менә түбәндәге мисалда *хәләл җефет булу* дигәндә хатын-кыз гына күз алдында тотылмый, бу сүзтезмә гомумән ‘өйләнешү, парлашу’ төшенчәләрен белдерә: *Андин соң Чыңғыз ханның күңеле эреде, икүесе бер беринә қабул булыб хәләл җефет булдылар* [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 78]. Әйтергә кирәк, әлеге сүзтезмә хәзерге татар әдәби телендә хатын-кызга мөнәсәбәттә генә кулланыла.

‘Хатын-кыз’, ‘ир хатыны’ мәгънәләрен белдерә торган төрки-татар чыгышлы *бичә* лексемасы чыганакларда ‘хан, би, бәкләрнең хатыны’ мәгънәсендә генә кулланыла һәм күпмедер дәрәҗәдә ‘хөрмәткә лаек, олпат хатын’ кебек коннотацияләр белән баетыла: *Җанибәк ханның бичәсе Тайдулы ханшаның ай-көне иңгән ирде* [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 88].

Тарихи планда *бичә* лексик берәмлеге татар телендә актив кулланылган терминнардан санала. Бу сүз әдәби текстларда гына түгел, XVII–XVIII йөзләргә караган эш кәгазьләрендә чагылыш тапкан [Зайнуллина-Маннапова, 1988, б. 30; Фасеев, 1982, б. 153–155].

*Җиңгә* – конкрет мәгънәле төрки-татар сүзе. Хәзерге татар әдәби телендә никах туганлыгы атамасы буларак кулланыла торган *җиңгә* сүзе ‘үзеннән олы ир туганның хатыны’ мәгънәсенә ия. Без тикшергән язма чыганакларда да әлеге лексеманы шушы төшенчәдә очратабыз: *...Ағамыз Дуйын Бәйан үлде, җиңгәмез Аланғу тол қалды тибүдәргә, утыз өч мең нәүкәрләре берлә үдәрин үдәрләделәр* [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 71].

*Килен* сүзе Мәүла Колый әсәрләрендә теркәлде. Биредә ул ‘улының яки энесенең хатыны’ мәгънәсендә очрый. Шулай ук шагыйрь бу лексик берәмлекне образлы чагыштыру чарасы буларак куллана һәм аның ярдәмендә киленнәр өчен хас булган аерым сыйфатларны дөнья масштабына күчерә: *Килен кебек бизәнеб алдағучы бу дөнйа* [Мәүла Колый шигырьләре, 1963, б. 483].

**2. Кан туганлык атамалары.** *Ата* – гомумтөрки сүз. Әлеге лексик берәмлек ярдәмендә күп кенә төрки телләрдә [Покровская, 1961, с. 25], борынгы төрки [Малов, 1951, с. 361; Древнетюркский словарь, 1969, с. 65, 97] һәм иске татар язма истәлекләрендә, шул исәптән безнең тарафтан тикшерелгән текстларда да, ‘балалары булган, бала тәрбияләп үстергән ир кеше; әти’ төшенчәләре белдерелә. Галимнәр фикеренчә, ул аларның барысында да диярлек очрый [Хисамова, 1981, б. 84; Фасеев 1982, с. 149; Махмутова, 1982, с. 83; Алеева 1989, с. 38; Зәйнуллина-Маннапова, 1988, б. 30].

«Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә бу лексик берәмлекнең сигез мәгънәсе теркәлгән. Шулар арасыннан XVII–XVIII гасыр иске татар язма истәлекләрендә берничә мәгънәнең генә чагылыш табуы күзәтелә. Мәсәлән, түбәндәге мисалларда *ата* сүзе ‘балалары булган, бала тәрбияләп үстергән ир кеше; әти кеше’ мәгънәсен белдерә: *Башында ултырмаға атасы йуқ* [Мәүла Колый шигырьләре, 1963, б. 495]; *Байағы күргән көндин қорсағыма бала булды, имде атама нә дийеб әйтерсез – диде* [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 69]; *Йәнә бер анча көнләрдин соң Тумаwыл Мәргәннең атасы Турымтай Чәчән үлде* [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 71].

Тартым кушымчасы өстәлгән очракта *ата* лексемасы ‘баланың үз әтисен атау, аңа мөрәҗәгать итү, эндәшү сүзе’ буларак файдаланыла: *Нийаз Хуҗаға әйтде, йа атам, бер қол алдым Дауд әфәндедән, диде* [Мөслими, 1999, б. 40].

Язма истәлекләрдә аның ‘өлкән буын кешеләр, ата-бабалар, нәсел-ыруг’ мәгънәсендә кулланылышын да очратырга мөмкин: *Падишаһ хәзрәте бик сабыр әһлендән ирде, қараwылчыларға чағырмайыб, ақрын әдәб берлә, йа фәлән, сән бәнем тәхетемнең айақларыны кисмәгел, зира ки аталарымыздан қалған мирасдыр, зиннәте китмәсен, диде* [Мөслими, 1999, б. 16].

*Ата* сүзенең мәгънә спектры аның нигезендә барлыкка килгән сүзтезмәләрдә, парлы сүзләрдә тагын да киңәя. Мәсәлән, Мөслиминең «Тәварихе Болгария» әсәрендә *ата* лексемасы *Адәм ғаләйһиссәлам* сүзтезмәсе белән мәгънәви бәйләнешкә кереп, ‘кешелекнең нәсел башы, кешелекнең башлангычы’ төшенчәсен белдереп килә: *Атамыз Адәм ғаләйһиссәлам ул көндә тәүбә әйләде* [Мөслими, 1999, б. 10].

Язма истәлекләрдә *ата, ана* лексемалары катнашында формалашкан *ата-ана* парлы сүзенең актив кулланылуын да искәртергә кирәк. Ул аеруча Мәүла Колдый әсәрләрендә еш очрый: *Ата-ана тугырды безне, мөхиб дуслар* [Мәүла Колый шигырьләре, 1963, б. 491]; *Һәр угыл-кыз ата-ананы белер булса* [шунда ук]; *Андин соң йәнә Ақсақ Тимернең атасы-анасы үлде* [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 82].

Әлеге мисалларда *ата-ана* парлы сүзе ‘балалалары булган, бала тәрбияләп үстергән кешеләр, гаилә’ төшенчәсен белдерсә, алдагы җөмләдә ул күпмедер дәрәҗәдә нәсел-нәсәпне дә күз алдында тотып, җыйма мәгънәдә кулланылган. Биредә *ата-ана* парлы сүзенең күплек санда килүе дә аңа җыймалык мәгънәсен өсти: *Ата-аналары, қарендәш-ыруглары тәфәккердә булдылар* [Мәҗмүгъ әл-хикәят, 1963, б. 515].

Түбәндәге җөмләдә *ата-ана* лексемасында ‘нәсел-нәсәп’ төшенчәсе дә күпмедер дәрәҗәдә чагылыш таба: *Ғазраил ғаләйһиссәлам әйде: «Мән сәнең кебек қол мән, илля Мәләкел-мәүт див бәне әйтерләр, йәгни барча мәхлуқатлар җаныны wә һәм атаң-анаң җаныны бән алдым, див әйтде* [Мөслими, 1999, б. 16].

Шулай итеп, *ата* сүзенең семантикасы язма истәлекләрдә шактый киң ачыла: ул ‘бала тәрбияләп үстергән ир кеше’ төшенчәсен генә түгел, ә ‘кешелекнең нәсел башы’, ‘нәсел-нәсәп, ыруғ’ мәгънәләрен дә белдерә.

*Ана* – конкрет мәгънәле гомумтөрки сүз. Хәзерге татар телендә ‘бала тапкан, бала тәрбияләп үстергән хатын’ мәгънәсен белдерә [Татар теленең аңлатмалы ..., II т., 2015, б. 168]. Ул борынгы төрки язма истәлекләрдән үк билгеле [Малов, 1951, с. 358; Древнетюркский словарь, 1969, с. 43]. «Кодекс Куманикус» әсәрендә [Махмутова, 1982, с. 81], XVII–XIX гасырлар язма эш кәгазьләрендә [Хисамова, 1982, б. 84; Зәйнуллина-Маннапова, 1988, б. 30; Фасеев, 1982, б. 150–151] һ.б. язма истәлекләрдә дә *ана* лексемасы шушы мәгънәсендә очрый.

Төп мәгънәсеннән тыш, «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә әлеге лексеманың тагын сигез мәгънәсе күрсәтелә. Хәзерге татар

телендә бу семаның мәгънә төрләре шактый киңәйсә дә, без тикшергән язма истәлекләрдә *ана* сүзе үзенең борынгы, ягъни ‘бала тудыручы, бала тәрбияләп үстерүче’ мәгънәсендә генә кулланыла: *Өстендә хәсрәт йыйар анасы йуҡ* [Мәүла Колый шигырьләре, 1963, б. 495]; *Бән анамдан айырыласым килмәде, өнем див белдем* [Мөслими, 1999, б. 40]; *Ағаларының үгет-wасыйәт сүзен тотмадылар, анасын санға санамадылар* [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 73].

Мисаллардан күренгәнчә, *ана* сүзе үзендә гаилә учагын сүндерми саклаучы, үзендә җылылык, изгелек кебек сыйфатларны туплаган хатын-кыз образын чагылдыра.

Борынгы һәм Урта гасыр язма истәлекләрендә теркәлеп калган *уғыл* лексик берәмлегенең хәзерге татар телендә ‘ир бала’ мәгънәсендә *ул* варианты кулланылышта йөри. Әмма шунысын да искәртергә кирәк: язма истәлекләрдә *уғыл* берәмлегенең лексик һәм коннотатив мәгънәләре шактый табыла. Фактик материалдан күренгәнчә, күп очракта әлеге сүз үзенең туры мәгънәсендә очрый, ягъни ‘ата-ананың ир баласы’ төшенчәсен белдереп килә һәм бу мәгънәгә кайчак ‘сабый, кечкенә ир бала’ мәгънәви төсмерләре дә өстәлә: *Уғлан икән төн-көн ғыйлем тәхсил ҡылыр* [Мәүла Колый шигырьләре, 1963, б. 496]; *Аңа Ходаwәндәи ғаләм бер уғыл биреб ирде, ғаҗәйеб зирәк wә ғаҡыйль wә камил* [Мәҗмүгъ әл-хикәят, 1963, б. 505].

Өлкән яшьтәге ир кешенең атасы ягъни кем баласы булуы ачыкланган җөмләләрдә *уғыл* сүзенең *уғлы, уғлыдыр* формалары кулланыла: *Ул дөнйа wә ахирәт падишаһы улыр, исеме Мөхәммәд улыр, Ғабдуллаһ уғлыдыр* [Мөслими, 1999, б. 17]; *Берсе Бүдән Чар уғлы ирде, икенчесе Ҡағыйн Чар уғлы ирде, өченчесе Салчут уғлы ирде, дүртенче Ҡунғрат би уғлы ирде* [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 77]; *Уғлыны ҡулыйға алыб үбеб, йәнә пәри ҡызыйға бирде* [Мәҗмүгъ әл-хикәят, 1963, б. 507].

Югарыда китерелгән мисаллардан күренгәнчә, мондый очракларда *уғыл* сүзе гадәттә ир-ат исеме белән янәшә йөри: *Ғабдуллаһ уғлы, Ғаднан уғлы, Һашим уғлы* һ.б. Әлеге җөмләләрдә *уғыл* дигәндә, буй җиткән, өлкән, нинди дә булса дәрәҗәгә ирешкән яисә кабилә, гаскәр башлыгы башлыгы булган ир кеше күз алдында тотыла. Хәтта биредә *уғыл* берәмлеге нәсел-нәсәп җепләрен, шәҗәрәне, ягъни буыннар чылбырын ачыклау вазифасын үти дисәк тә дөрес булыр.

Сүзтезмә составында килгәндә, *уғыл* лексемасының семантикасы тагын да киңәя. Мәсәлән, *уғыл бала* дигән очракта ул ‘ата-ананың балигъ булмаган ир баласы’ мәгънәсенә ия: *Йаранлар, йуҡ ирсә безнең бер уғыл баламызны алыңыз, безгә бу кийекне биреңез, без ач үлмәйек* [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 72]; *Тәфтазан аwылында уҡыб тордыҡы бәне бер Төркстани хаҗи ағу биреб алдаб, сине уғыл бала идәрмен диб алыб китде* [Мөслими, 1999, б. 38].

«Дәфтәре Чыңгызнамә» әсәрендә *ир уғлан, ҡыз уғлан* сүзтезмәләре киң кулланыла. Димәк *уғлан* лексемасы ‘ир бала’ төшенчәсен генә белдереп калмый, гомумән ‘бәби, нарасый, сабый’, ‘ба-

лигъ булмаган ир яисә кыз бала’ мәгънәләрен тулаем атый булып чыга: *Андин йәнә бер анча көнләрдән соң мескин тезләб игән ул хатын күзе йарылды, бер ир уғлан туғырды* [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 82]; *Әй, ханша, мин аудан кайты, килгәнчә уғлан туғса, қыз уғлан туғса үлтергел, әгәр ир уғлан булса төшлек йирдән үзең сүгән кешене сөқенче йибәргел, – тиде* [шунда ук, б. 88].

Шулай ук «Дәфтәре Чыңгызнамә» әсәрендә еш очрый торган сүзтезмәләрнең берсе – *халық уғлы.* Язма истәлекнең эчтәлегеннән чыгып фикер йөрткәндә, безнең фикеребезчә, бу сүзтезмә ‘халыкның хөрмәтле биләре, ихтирамлы сугышчылар, дөнья-ил тотардай ир-атлар’ төшенчәсен җыеп аңлата. Әмма шунысы кызыклы бу сүзтезмә берлек санда кулланылса да, аңа ияргән хәбәр гадәттә күплектә килә: *Анда халық уғлы әйделәр, һай, Чыңғыз, сез өчәwегездин йортка лайық – рәва охшайдыр, халыққа файдалығдыр, бу Чыңғызны сезгә үлтерергә бирмәсбез, диделәр* [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 74]; *Иртәгәсен халқы уғлы күренешкә килделәр ирсә Чыңғызны күрмәделәр, тәқый сорадылар* [шунда ук, б. 74].

Мәүла Колый кешеләрне, аларга хас сыйфатларны гомумиләштереп әйтергә теләгәндә, *адәм уғлы* сүзтезмәсен куллана: *Адәм уғлы бизәнер, дөнйаны бақый санаб* [Мәүла Колый шигырьләре, 1963, б. 488]. Биредә сүз гомумән кеше, адәм баласы хакында бара.

Төрки-татар сүзләреннән тыш, язма истәлекләрдә ‘ир бала’ мәгънәсен аңлаткан гарәп-фарсы сүзләре дә очрый. Мәсәлән, ‘сабый, ир бала’ төшенчәсе фарсы чыгышлы *фәрзәнд* алынмасы белән җиткерелә: *Шаһзадәнең фәрзәндегә бисийар мәхәббәте wә шәфқате барындин мозтарабел-халь wә рәнҗү пәр хатыр булды* [Мәҗмүгъ әл-хикәят, 1963, б. 507].

Гарәп теленнән кергән *ғолям* лексемасы исә ‘ир бала, үсмер егет’ төшенчәсен белдереп килә: *Пәри җәванмәрд падишаһзадәнең қулын тотыб, алтын тәхетнең өстигә чықарыб ултырғызды wә ғолям wә кәнизәк саф-саф хезмәт тордылар* [Мәҗмүгъ әл-хикәят, 1963, б. 507].

Тупланган материалдан күренгәнчә, язма истәлекләрдә *уғыл* лексемасының семантик һәм коннотатив мәгънә үзенчәлекләре сүзтезмәләр составында аеруча киңәя һәм төрләнә. Алар арасыннан *ир уғлан, қыз уғлан* кебек сүзтезмәләр диалектларда кулланылса да, *халық уғлы* сүзтезмәсе, *фәрзәнд, ғолям* кебек алынмалар хәзерге әдәби телдә очрамый.

*Кыз* – конкрет мәгънәле төрки-татар сүзе, туганлык атамасы. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә бу лексик берәмлекнең дүрт мәгънәсе теркәлгән. Шулар арасыннан язма истәлекләрдә барыннан да бигрәк ‘ата-ананың шул женестәге баласы’ мәгънәсендә кулланылышы киң таралган: *Әл-қыйсса, бер көн Айдар ханның қызы Туйбикәгә фалиҗ зәхмәте пәйда булды* [Мөслими, 1999, б. 26]; *Хәзрәте Нух пәйғамбәр ғаләйһиссәламнең дүрт уғлы, тәқый дүрт қызы вар иде* [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 69].

Мисаллардан күренгәнчә, ‘кемнең дә булса кыз баласы’ төшенчәсен белдергән очракта, *қыз* сүзе кыз баланың әтисенең исеме (*Айдар ханның қызы, Алтын хан қызы* һ.б.) яисә *үз* алмашлыгы белән янәшә килә, тартым кушымчасы ала: *Бер көн Алтын хан үз қызын күрмәгә килде ирсә, күрер кем хамилә улыбдыр* [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 69].

Әгәр вакыйга беренче заттан сөйләнә икән, бу очракта сүзгә шушы затка караган тартым кушымчалары өстәлеп, ‘сөйләүченең кыз баласы’ төшенчәсе белдерелә: *Нәсры ғайиәргә кеше җибәрделәр кем, қызымызның гөнаһе нә торыр, безләргә мәғлүм булғай, аның җәзасын бирәлең диб, ант эчделәр* [Мәҗмүгъ әл-хикәят, 1963, б. 515].

Текстларда ‘кемнең дә булса қыз баласы’ төшенчәсе *қыз бала* сүзтезмәсе белән дә белдерелергә мөмкин. Мондый очракларда кыз образы ниндидер бер җылылык, якынлык, самимилек белән тасвирлана, биредә атаның баласына булган җылы мөнәсбәте дә чагылыш таба: *Хан әйде, бәнем дөнйада күрдегем ошбу қыз балам ирде, ғайре балам йуқдыр, аңа шифа қылсаңыз wә йаңа чаwыл йафрағы илә дүркә бағласаңыз, бән сезнең динегезне қабул идәрмен, диде* [Мөслими, 1999, б. 26].

Башка төр туганлык терминнары кебек үк, *қыз* атамасының да сүзтезмәләр эчендә семантик мөмкинлекләре тагын да киңрәк ачыла. Мәсәлән, кыз лексемасы гомуми туганлыкны белдерә торган *қардәш, қарендәш* сүзләре белән бәйләнешкә кергән очракта туган тиешле кыз кеше, ягъни апа яисә сеңел турында сүз барганлыгы аңлашыла: *Мәнең бер қыз қарендәшем бар, аны сәңа бирермен* [Мәҗмүгъ әл-хикәят, 1963, б. 519]; *Әмма ул wакытда Қунграт бинең бер қыз қарендәше бар ирде, Бүртә Күчин атлығ ирде* [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 77].

«Мәҗмүгъ әл-хикәят» әсәрендә без ‘кыз туган’, ‘кыз кардәш’ мәгънәләрен җиткерү өчен фарсы теленнән кергән *хаһәр* берәмлегенең кулланылышы белән дә очрашабыз: *Имди белгел wә агяһ бул, мәннең бер хаһәрем бар, тәмам ғаләмдә андыйн җәмилә йуқ торыр, аны кәнизәклеккә қабул қылсаң* [Мәҗмүгъ әл-хикәят, 1963, б. 506].

*Эне* – конкрет мәгънәле төрки-татар сүзе. Әлеге атама татар әдәби телендә бертуганга карата гына түгел, сөйләүчедән яше белән кечкенә булган башка ир туганнарны атау өчен дә кулланыла. Язма истәлекләрдә бу лексема сирәк очрый. Түбәндәге мисалда ул кан туганлык мөнәсәбәтләрен белдерү өчен файдаланыла: *Әмма Дуйын Бәйан дөнйадин үткәнен қалмақдағы ике энесе Будәнә Тай, Билге Тай ишетде* [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 71].

*Қайын* сүзе белән семантик бәйләнешкә кереп, бу сүз хәзерге татар телендә, диалектларда һәм язма истәлекләрдә дә никах туганлыгы белән бәйле ‘иренең энесе’ төшенчәсен белдерә: *Аһ, әй қайын энеләрем, Будәнә Тай, Билге Тай, бер анча көнгә сабыр итсәгез булыр ирде* [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 72].

Мисаллардан күренгәнчә, *эне* лексемасы XVII–XVIII гасырлар иске татар язма истәлекләрендә ике төшенчәне белдерү өчен файдаланылган һәм әлеге күренеш хәзерге татар әдәби телендә һәм диалектларда да күзәтелә.

*Аға* – конкрет мәгънәле төрки-татар сүзе. Хәзерге татар телендә сүзлекләрдә әлеге лексик берәмлекнең дүрт мәгънәсе теркәлгән. Туплаган материаллар *ага* сүзенең XVII–XVIII гасырлар иске татар язма истәлекләрендә ике төшенчә белдерүен күрсәтә. Түбәндәге җөмләдә ул 'сөйләүчедән олы булган ир туган, абый, кан қардәш' төшенчәсен аңлатуда катнаша: *Ағамыз Дуйын Бәйан үлде, җиңгәмез Аланғу тол қалды тибүдәргә, утыз өч мең нәүкәрләре берлә үдәрин үдәрләделәр* [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 71].

Гомумән, *аға* берәмлегенең туганлык атамасы буларак кулланылышы «Кодекс Куманикус»тан ук билгеле [Махмутова, 1982, с. 72], иске татар язма истәлекләрендә [Зәйнуллина-Маннапова, 1988, б. 30; Фасеев 1982, б. 148–150 һ.б.] һәм каберташ язмаларында да *ага* сүзе 'өлкән ир туган' төшенчәсен белдереп килә [Ахметзянов, 1983, с. 79].

Болардан тыш, әлеге сүзнең язма истәлекләрдә 'өлкән яшьтә булган хөрмәтле ир кеше', хәтта 'аксакаллар' төшенчәсендә килүе дә күзәтелә. Мәсәлән: *Әйтди ки, йа ағалар, вармыдыр ки араңызда хат танғучы, диде* [Мөслими, 1999, б. 40].

*Аға* лексемасы әлеге мәгънәсендә Ибраһим хан ярлыкларында [Фасеев, 1982, б. 148–150], әрмән язулы кыпчак телле документларда [Абдуллин, 1985, б. 40–41], иске татар язма истәлекләрендә [Алеева, 1989, б. 76] теркәлеп калган һәм ул хәзерге әдәби телдә дә киң кулланыла.

*Баба* / *бабай* – конкрет мәгънәле, төрки атама. Татар телендә ул кан туганлыкны да, никах туганлыгын белдерү өчен дә кулланыла. *Баба* лексемасының килеп чыгышы борынгы төрки чорга барып тоташа дип фаразлана, аның иске татар язма истәлекләрдә [Зәйнуллина-Маннапова, 1988, 30; Фасеев, 1982, 151 һ.б.], каберташ язмаларында теркәлеп калуы шуның бер дәлиле булып тора [Ахметзянов, 1983, с. 79]. Әмма XVII–XVIII гасырлар иске татар язма чыганакларында әлеге лексема хәзерге татар әдәби телендә татар теленең аңлатмалы сүзлегендә теркәлгән беренче төп, ягъни 'бабай, дәү эти' мәгънәсендә бик сирәк кулланыла. Мәсәлән, түбәндәге мисалда 'дәү эти, бабай' мәгънәсе киңәеп, 'нәселнең хөрмәтле вәкиле, аксакалы' төшенчәсен аңлатып килә: *Бабаң Ибраһим галәйһиссәлам китабы «Зәндә» исемледер, андаг бондаг моуқутдыр, диде* [Мөслими, 1999, б. 18].

*Баба* атамасы сүзтезмәләр составында килгәндә, тагын да киңрәк мәгънә төсмерләренә ия була. Чыганакларда ул *бөйек баба, бабаларым йорты* кебек сүзтезмәләр составында очрый. Без тикшергән язма истәлекләрдә *бөйек баба* сүзтезмәсе 'халык-милләтнең баш кешесе, башлыгы, аксакалы' төшенчәсендә кулланыла: *Вәҗһе тәсмийә бил-гарәбийә улдыр кем, пәйғамбәрләремезнең Кәнанә исемле бөйек бабасы вар иде, ғарәбләр шаһы ирде* [Мөслими, 1999, б. 11]; *Вәҗһе*

*тәсмийә бил-ғарәбийә улдыр кем, Пәйғамбәремез ғаләйһиссәламнең җаһилийәт заманында Һашим дидеге бөйек бабасы вар иде, ғарәб қабиләләренең ғазый шаһы ирде* [шунда ук, 1999, б. 13].

Дөрес, ‘кабилә-ыруг башлыгы’ мәгънәсендә, ягъни *баба* сүзенең югарыда китерелгән мәгънәсенә синоним буларак *қарт* лексемасының кулланылышын да очратырга мөмкин: *Тәтеш қарты ыруғы берлә Ақ идел йарына төшде, Тәтеш аwылы булды* [Мөслими, 1999, б. 45]; *Анда ул қарт ыруғына әйде: «Әй, егетләр, бу Ақсақ уғылның сезнең қулыңыздин борын башы йитебдер, моны хан қылайың», – тиде* [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 87].

*Бабаларым йорты* дигән очракта ‘тулы бер нәсел-ыруг, кабилә һәм шул нәсел яшәгән ил-җир’ төшенчәсе күз алдында тотыла: *Иске бабаларым йортыға барырмын, мәқам-йорт тотармын, – тиде* [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 86].

Язма чыганаклардан күренгәнчә, *баба* лексемасы XVII–XVIII гасырда, нигездә, ‘кабилә-ыругның баш кешесе’, ‘аксакал’ төшенчәләрендә, хәтта кайбер очракта тулы бер нәселне чагылдырып килә торган җыйма исем буларак та кулланылыш тапкан.

*Қарендәш*, *қардәш* лексемалары бертуганлыкны, берничә буын туганлыгын аңлата. Әлеге лексик берәмлекләр язма чыганакларда еш кына туганнар арасындагы якын мөнәсәбәтләрне тасвирлау өчен кулланылалар: *Қарендәш мәхәббәте бал-шикәрдин ләззәтледер қыйммәтене белер булсаң* [Мәүла Колый шигырьләре, 1963, б. 493]; *Йуқ аның гүргә қуйар қарендәше* [шунда ук, б. 495]; *Қарендәшсез кешеләргә йуқдыр сәбат* [шунда ук, б. 493].

Түбәндәге мисалда исә *қардәш* лексемасының мәгънәсе тагын да киңәя. Тексттан күренгәнчә, биредә ‘туганлык, нәселдәшлек’ төшенчәләренә ‘иптәш, дус, уртак мәнфәгатьләр буенча якын кешеләр’ мәгънәләре дә өстәлә: *Имде, бу көндин соң сине тәмам углың-қызың, қардәшләрең берлә йарлықадым, һәр қанда сөйсәң, шул тарафқа киткәйсез* [Дәфтәре Чыңгызнамә, 2011, б. 86]; *Олуғ қардәш қыла алмаз сәне ғани* [Мәүла Колый шигырьләре, 1963, б. 495].

Йомгаклап әйткәндә, XVII–XVIII гасырлар иске татар язма истәлекләрендә туганлык терминнары төрле мәгънәләрне белдереп, күпсанлы функцияләр башкарып киләләр. Аерым алганда, әлеге лексик берәмлекләр, бер яктан, конкрет мәгънәгә ия булып, билгеле бер затларны атасалар, икенче яктан, кешенең җәмгыятьтә тоткан урыны, башкарган вазифалары, ягъни социаль статуслары белән бәйле мәгълүматны да җиткерәләр. Болар барысы да туганлык терминнарының башка сүзләр кебек үк татар халкының этномәдәни кодын ачып бирергә ярдәм итә торган тел материалы булуын күрсәтеп тора.

**Әдәбият**

*Абдуллин И.А.* Социально-политическая терминология языка армяно-кыпчакских памятников (тюркский пласт) // Историко-лингвистический анализ старописьменных памятников. Казань, 1985. С. 40–56.

*Алеева Ә.Х.* Исмәгыйль ага сәяхәтнамәсе // Эзләнүләр, уйланулар, табышлар. Казан, 1989. Б. 23–96.

*Ахметзянов М.И.* О лексике эпитафий XVII–XVIII вв. // Историко-лингвистический анализ старописьменных памятников: Сб. ст. Казань, 1983. С. 75–84.

*Валиева М.З.* Особенности синонимической парадигмы тюрко-татарского письменного памятника XVIII века «Маджмугыл-хикаят» // Вестник Чувашского государственного педагогического университета им. И.Я. Яковлева. Чебоксары, 2017. № 1 (93). С. 37–43.

*Валиева М.З.* Ономастикон татарских письменных источников (на примере письменного памятника «Дафтар-и Чингиз-наме») // Филологические науки. Вопросы теории и практики. Тамбов: Грамота, 2022. Т. 15, вып. № 2 (128). С. 449–453.

Дәфтәре Чыңгызнамә // Мирастан биш сәхифә: XVII–XIX гасырлар әдәби-тарихи ядкярләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. Б. 37–96.

*Денмухамметова Э.Н., Юсупова А.Ш.* Термины родства в двуязычных словарях татарского языка // Филологические науки. Вопросы теории и практики. Тамбов: Грамота, 2012. С. 62–65.

*Зайнуллина-Маннапова А.Х.* О лексике деловых документов старотатарской письменности XVII в. // Истоки татарского литературного языка. Казань, 1988. С. 27–34.

*Кадирова Э.Х., Файзуллина Г.Ч.* Тубыл губернасының XIX гасыр һәм XX гасыр башы метрика кенәгәләрендә туганлык атамалары // Фәнни Татарстан. 2022. № 1. Б. 7–15.

*Малов С.Е.* Памятники древнетюркской письменности. М.-Л., 1951. 452 с.

*Махмутова Л.Т.* Татарский язык в его отношении к древнеписьменному памятнику СС по данным лексики (краткий анализ и приложение) // Исследования по исторической диалектологии татарского языка. Казань, 1982. С. 68–153.

Мәүла Колый поэмалары / төз. Р.Ф. Мәрданов. Казан: Милли китап, 2008. 88 б.

Мәүла Колый шигырьләре // Борынгы татар әдәбияты. Казан: Татар. кит. нәшр., 1963. Б. 487–503.

Мәҗмүгъ әл-хикәят // Борынгы татар әдәбияты. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1963. Б. 503–522.

*Мөслими.* Тәварихы Болгария / басмага әзерләүче С. Гыйләҗетдинов. Казан: Иман, 1999. 100 б.

*Нурмухамметова Р.С., Мугтасимова Г.Р.* Термины родства в текстах татарского фольклора // https://www.google.com/url?sa=t&rct=j&q=&esrc=s&source=web&cd=&ved=2ahUKEwjn6cD98b__AhUR_CoKHWxiBO04ChAWegQIIhAB&url=https%3A%2F%2Flibweb.kpfu.ru%2Fpublication%2Fpapers%2Fkls%2F2019-1%2Fkls-2019-1-172-175.pdf&usg=AOvVaw20C12s2wps5-lWAPAsWqEA

*Покровская Л.А.* Термины родства в тюркских языках // Историческое развитие лексики тюркских языков. М., 1961. С. 11–81.

*Рамазанова Д.Б.* Термины родства и свойства в татарском языке: в двух книгах. Казань, 1991. Кн. I. 87 с. Кн. II. 192 с.

*Рамазанова Д.Б.* Родственные и семейные отношения в названиях. Казань: Татар. кн. изд-во, 2014. 287 с. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: I т.: А–В. Казан: ТӘһСИ, 2015. 712 б.

*Севортян Э.В.* Этимологический словарь тюркских языков (Общетюрские и межтюркские основы на гласные). М.: Наука, 1974. 767 с.

*Фасеев Ф.С.* Старотатарская деловая письменность XVIII века. Казань, 1982. 171 с.

*Хисамова Ф.М.* XVIII йөздәге татарча эш кәгазьләренең тел үзенчәлекләре. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1981. 162 б.

*Хисамиева З.А.* Семантическая классификация лексики дастанов Кадыр Гали Бека // Язык утилитарның и поэтических жанров памятников татарской письменности. Казань, 1999. С. 62–69.

*Цинциус В.И.* К этимологии алтайских терминов родства // Очерки сравнительной лексикологии алтайских языков. Л.: Изд-во «Наука». Ленингр-е отд-е, 1972. С. 15–70.

***Вәлиева Миләүшә Зәки кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 81'25

*А.Ә. Хасавнех*

# МӨХӘММӘДЗАКИР КАМАЛОВ ӘЛ-ЧИСТАВИНЫҢ ТӘРҖЕМӘИ ХӘЛЕ ТУРЫНДА БИЛГЕСЕЗ АВТОР ӘСӘРЕ

В статье представлен литературный анализ марсии-элегии неизвестного автора на смерть татарского накшбандийского шейха М.-З. Камалова. В произведении рассказывается о примечательных фактах жизни и деятельности М.-З. Камалова, его личных достоинствах, излагаются эпизоды последних минут перед его кончиной, а также сведения о дальнейшей судьбе некоторых из детей, последователей и муридов прославленного шейха.

**Ключевые слова:** марсия, Мухаммад-Закир ишан Камалов, суфизм, накшбандийский шейх.

The article presents a literary analysis of marsi-elegy of an unknown author on the death of the tatar naqshbandi shaykh M.-Z. Kamalova. The work describes the remarkable facts of the life and activity of M.-Z. Kamalova, his personal merits, outlines the episodes of last minutes before his death, as well as information about the fate of some of the children and the followers and murids of the famous sheikh.

**Keywords:** marcie, Muhammad-Zakir ishan Kamalov, sufism, naqshbandi shaykh.

Шәех Мөхәммәдзакир Камалов әл-Чистави (1804–1893) шәхесенә, аның тормыш юлы һәм эшчәнлегенә карата соңгы елларда үзебезнең галимнәрнең дә, чит ил тикшеренүчеләренең дә игътибары бермә-бер арта бара. Чөнки XIX гасырда Идел-Урал төбәгенең көньяк-көнчыгыш өлешендә Зәйнулла Рәсүлев (1833–1917) Троицкида «Рәсүлия», ә Урта Иделдә Мөхәммәдзакир әл-Чистави Чистайда «Камалия» мәдрәсәләре оештырып, бу ике төп мөселман мәгърифәт учагына Россиянең төрле почмакларыннан гына түгел, ә Урта Азиядән, Кавказдан, Казакъстаннан меңнәрчә шәкертләр килеп белем ала.

Мөхәммәдзакир Камаловның биографиясенә килгәндә исә, аны җентекләп өйрәнүчеләрдән берләнбер галим – мөгаен, Р.Г. Әмирхановны (1946–2006) гына атарга мөмкин [Амирханов, 2001; Амирханов Р.У. Знаменитость...; Амирханов Р.У. Путь шейха]. Соңгы ике елда безнең тарафтан да мәкаләләр бастырылды. Аларда татар рухани эшлеклесенең тормышына караган яңа детальләр ачыклана, аеруча игътибар аның суфичылыкның нәкышбәндия тарикатендә булучыларның этикасын һәм ритаул практикасын бәян иткән күләмле «Табсирәт әл-мөршидин мин әл-мәшәих әл-халидийин» [Абу ‘Абдуррахман] дигән хезмәтен анализлауга юнәлтелә [Хасавнех А.А. Биографические сведения; Хасавнех А.А. Биография; Хасавнех А.А. Сочинение].

Олуг шәех, имам Мөхәммәдзакир Камаловка исән вакытында ук күп кенә касыйдәләр (мактаулар) багышланган булса, вафатыннан соң мәрсияләр иҗат ителә. Шундый әсәрләрнең берсе 1983 елда археография экспедициясе вакытында әдәбиятчы Шакир Абилов (1915–2004) тарафыннан Бөгелмә районында табылган [Мәрсия-и дамелла Мөхәммәдзакир хәзрәт]. Кулъязманың күләме – 20 кәгазь, мәйданчыгы 22,5×18 см, һәр биттә 14 юл, пагинация тасвирланганда куелган. Кулъязманың кырыйларында аның авторының язмалары очрый. 2а биттәге штемпельдән күренгәнчә, кәгазь 1886–1901 еллар аралыгында Россиядә, Волын губернасындагы фабрикада эшләнгән [Клепиков, с. 103].

Мәрсия авторы, кызганыч ки, нindидер сәбәпләр аркасында үзенең исемен күрсәтмәгән. Әмма эчтәлектән аңлашылганча, ул, һичшиксез, ишан мөритләренең берсе булса кирәк. Бу фаразны Мөхәммәдзакир Камаловның остазы сыйфатында макталган дагстанлы нәкышбәндия тарикате шәехе Мәхмүд әфәнде әл-Алмали әд-Дагстани (1853–1919) турындагы юллар да раслый. Автор аны «безнең остазымыз остазы» дип бәяли: *Хак риза улсын Чистай ишан хәзрәтдин вә-с сәлам, / Остазымыз остазыдыр Мәхмуд әфәнде галәйһи-с-сәлам* [Мәрсия-и дамелла Мөхәммәдзакир хәзрәт, б. 9а].

Шунысы үзенчәлекле: мәрсия дүрт вариантта язылган. Әмма аларның һәрберсендә кабатлаулар очраса да, алар яңа детальләр белән дә тулыландырылганнар. Фикеребезчә, автор әсәрен яхшырту максатында шулай эшләгән. Шулай итеп, без 177 шигъри юлдан гыйбарәт булган төп вариантны аерып чыгардык, ә астөшермәләрдә аларның кайсы битләрдән алынганлыклары күрсәтеп барылды.

Шәрык мөселман әдәбиятында канунлашкан традиция нигезендә мәрсиянең беренче тугыз юлы барлык уңайлыкларны булдырган, кешелек дөньясына олуг бүләк сыйфатында ислам динен иңдергән Аллаһны, ахырзаманда мөселманнарны яклап чыгачак Мөхәммәд пәйгамбәрне, шулай ук аның итагатьле хатыннарын мактау белән башлана. Аннары автор мәрсиянең төп өлешенә күчә, анда шәех Мөхәммәдзакир Камаловның яхшы сыйфатлары һәм изге гамәлләре искә алына, теге яки бу мәсьәләгә карата автор позициясе белдерелгән чигенешләр белән аралаштырыла.

Традицион башламнан соң автор укучыны үлемнең кичектергесезлеге, Аллаһ тарафыннан кешегә җирдә яшәү өчен билгеләнгән вакытны бернинди чит көчләр, хәтта, дәвалау ысулы белән дә үзгәртеп булмау турындагы беренче фәлсәфи чигенешкә алып керә: *Тордыгынча гарше көрси, ләүхе калям, арзы-сәма / Вәҗиб улды безә мәүте Зө-л-җәлал, Зө-л-кәмал* [Мәрсия-и дамелла Мөхәммәдзакир хәзрәт, б. 1а]. Көнчыгыш әдәбиятларында да, Көнбатыш әдәбиятларында да мәрсия жанрына андый ысул хас. Анда автор яшәү һәм үлем, шатлык һәм кайгы, мәхәббәт һәм нәфрәт һ.б. антитезалар турында сөйли. Шуңа күрә әлеге әсәрдә мәңгелек сорауларга шактый гына урын бирелү бер дә гаҗәп түгел. Шагыйрь, үлем турындагы теманы дәвам ит-

тереп, матди кыйммәтләрнең узгынчы гына булулары турында фикер йөртә. Шуңа күрә дә мәрсиянең контекстына «әл-Гыймран» сүрәсенең 185 аятендәге эпитафия кертелү гаҗәп түгел: *Көлл-е нәфс зәъик әл-мәүт, би-гыйләҗдер би-мәҗал («Һәр җан үлем татый», һәм аны дәвалау урынсыз).* Кешенең җирдә яшәү вакыты билгеләнгән булу Коръәндә шулай әйтелгән: «Һәр җан үлем татый, ә соңыннан Безгә кире кайтачаксыз» (29: 57); «Аллаһы тарафыннан бирелгән вакыттан һәм Аның ихтыярыннан башка бер кеше дә үлмәячәк» (3: 145) һ.б. Пәйгамбәрнең билгеле хәдисендә әйтелгәнчә, кеше туганда аңа дүрт нәрсә язылган була: аның язмышы, гомер озынлыгы, гамәлләре һәм аның бәхетле яки бәхетсез булачагы.

Әсәр авторы язганча, хәтта камил инсан булган пәйгамбәр дә бакыйлыкка күчкән. Кешенең бу дөньялыкта яшәү вакыты чикләнгән булу турындагы фикерләү канвасына мигъраҗда булган һәм «унсигез мең галәмнең горурлыгы»на әверелгән пәйгамбәр образын кертеп, шагыйрь шундый чагыштыру ясый: үлем шулкадәр кичектергесез, ул, хәтта, пәйгамбәрне дә читләтеп узмагач, гади кешегә нәрсә була? *Унсигез мең галәм фәхре кәлде, күрдең рихләте, / Алды җанын, китде, дус ирде, аңа нәүбәте* [Мәрсия-и дамелла Мөхәммәдзакир хәзрәт, б. 1 б]. Ислам фикере тарихында унсигез мең галәм исәпләнә. Аларга кешелек дөньясы, фәрештәләр дөньясы, шайтаннар дөньясы һ.б. керә. Суфичылык әдәбиятында да унсигез мең галәм турында мәгълүмат китерелә [Саджади, с. 567]. Шулай ук И. Асими, Ш. Хаттаи кебек мәшһүр Шәрык шагыйрьләренең әсәрләрендә дә «унсигез мең галәм» термины очрый.

Әдәби әсәрләргә Коръән сүрәләре яки хәдисләрдән аерым өземтәләр кертү мөселман әдәбиятларында да, татар әдәбиятында да канунлашкан традициягә әверелә. Әдәбият галиме Х.Й. Миңнегулов язганча, «мөселман дине аеруча әдәбиятта тирән эз калдырган. Күп кенә сюжетлар, мотивлар, образлар «Коръән»нән алынган. Без моны Кол Гали, Мөхәммәдьяр, Утыз Имәни, Тукай һәм башка бик күп әдипләрнең әсәрләрендә ачык күрәбез. «Коръән», андагы идея-эстетик байлык татар язучыларын илһамландырган, иҗатларында төп юнәлешне билгеләгән, кешене, тормыш күренешләрен яктыртуда, бәяләүдә идеал, үзенә күрә бер өлге булып хезмәт иткән» [Миңнегулов, б. 112].

Мөхәммәдзакир Камалов турында хикәяләүне шартлы рәвештә өч өлешкә бүлеп карарга мөмкин: ишан тормышындагы һәм эшчәнлегендәге күркәм гамәлләр һәм мөһим детальләр; аның вафатының тәфсилле тасвирланышы һәм шәехнең күпсанлы варислары, кайбер балаларының һәм мөритләренең алдагы язмышлары турындагы йомгаклау өлеше. Мәрсия жанрында булуына карамастан, үзенең рухы белән әсәр башка жанрда иҗат ителгән суфичыл әсәрләр рухына тәңгәл килә, әйтик, Каландар Руминың «Каландарнамә» әсәрендәге кебек, әсәрдә суфичыл традицияләр саклана [Хасавнех, Мөхәммәтҗанова].

Р.Г. Әмирханов тикшеренүләреннән күренгәнчә, Мөхәммәдзакир Камалов ярты гасырга якын Чистай мәчетендә имам-хатыйп булган,

шунда ук «Камалия» мәдрәсәсе оештырган. Аны тәмамлаучылар арасында Ризаэддин бине Фәхреддин (1859–1936), Фатих Кәрими (1870–1937), Галиәсгар Гафуров-Чыгтай (1867–1942), Гаяз Исхакый (1878–1954) һәм татар халкының башка күренекле затлары бар [Амирханов Р.У. Путь...]. Бу мәгълүмат мәрсия авторы тарафыннан да раслана: *Хәмде бәгъдә башлайалым бер тәбарәк, и әхи, / Чистай илендә улыбды бер гаҗәйеб хуш сәхи. / Исме мәшһүр Закир иде, әткәсе Габделваһһаб, / Чиставидыр, Саснавидыр, бу сүзә тотың колак* [Мәрсия-и дамелла Мөхәммәдзакир хәзрәт, б. 1 б].

Сасна авылында туган Мөхәммәдзакир Камалов киң танылган Мәчкәрә мәдрәсәсендә яхшы гына укый. Бу мәдрәсә мәрсиядә һәрьяклап мактала. Анда шәкертләр мөселман фәннәре буенча ныклы белем алганнар, алар арасында дустанә мөнәсәбәт хөкем сөргән. Текстан күренгәнчә, мәдрәсә Идел-Урал төбәге мөселманнары өчен төп мәгърифәт үзәкләренең берсе булган: *Дәрсе гыйльмен укымыш иде Мәчкәрәдә би-тәмам, / Мәчкәрәдә сигез иде мәдрәсә, фәнә тәмам. / Мәдрәсә гадәденчә иде, кафиләр (?) йәшьләре фирка-фирка белер иде һәр берен заһир-гайан* [Мәрсия-и дамелла Мөхәммәдзакир хәзрәт, б. 5 б].

Әлеге мәдәрәсәдә укуын тәмамлагач, ул, билгеле булганча, Чистай мәчетенә имам-хатыйп итеп билгеләнә һәм анда үзенең киңкырлы эшчәнлеген башлап җибәрә. Бер үк вакытта сәүдә белән уңышлы шөгыльләнеп, икенче гильдия сәүдәгәр була. Үз хисабына «Камалия» мәдрәсәсен төзетә. Р.Г. Әмирханов язганча, ул дүрт бинадан торган үзенчәлекле дини комплекс булган. Бу «уку йорты Россиянең төрле губерналарыннан һәм өязләреннән ислам гыйлеме алырга килгән йөзләрчә яшь егетләргә тормышка юллама биргән» [Амирханов Р.У. Путь...]. Әмма мәрсиядә ишан мөритләренең йөзләп кенә түгел, ә меңләп исәпләнүе әйтелә. Әсәрдә шулай ук Мөхәммәдзакир ишанның даны Россиянең барлык тарафларына таралганлыгы ассызыклана: *Җәһед йек саль үтде гомре илдә имамлык кылыб, / Мәсҗед-мәдрәсәләр, ханәләр ташдин йавыб. / Гариф иде, гамил иде, гыйльмедер гыйрфан илә, / Шәех иде, мөршид иде нәчә мең мөрид илә. / Уфа, Казан һәм Ырынбур һәм Троиски каласы, / Дагыйстани, Әчтерхани – канда булды сайәсе* [Мәрсия-и дамелла Мөхәммәдзакир хәзрәт, б. 9а].

Мөхәммәдзакир ишанның күпсанлы уңай яклары, шәхси холкы турындагы мәгълүмат шундый шигъри юллар белән башлана: *Хәмде бәгъдә башлайалым бер тәбарәк*[1]*, и әхи.* Мөхәммәдзакир ишанга менә шундый сыйфатлар хас булган: *гаҗәеп, хуш сәхи; гариф, гамил, гыйльмедер гыйрфан илә; җөмләсендин фазыйл иде шул заман; мөхтәсибдер, могтәбәрдер; һимам һәм суфилар иерархиясендә иң югары дәрәҗә – шәйхе котыб.* Күренгәнчә, шәехнең күркәм сыйфатлары арасында аеруча аның укымышлылыгына, дин гыйле-

[1] Тәбарәк – «Мөлек» сүрәсе.

мен тирән үзләштерүенә, суфиларга хас булган аерым мистиканы белүенә игътибар юнәлтелә. Ул үзе дә гарәп телендәге «Табсирәт әл-мөршидин...» дигән хезмәтендә «чын шәехнең сыйфатлары шундый була: фани дөньядан читләшү, [җәмгыятьтә] югары дәрәҗәгә ирешү омтылышы булмау; ул барыннан да элек ашауда, эчүдә, сөйләшүдә һәм йокыда аз гына микъдар белән канәгатьләнергә, догада, садака бирүдә һәм уразада зур тырышлык куярга тиеш» [Абу ‘Абдуррахман, б. 46]. Суфи остазларның иң яхшы сыйфатлары итеп, ул аларның гамәлләре әйткән сүзләре белән тәңгәл килүне аерып күрсәтә. Чөнки Мөхәммәдзакир Камалов фикеренчә, гыйлем уй-ниятләр, тормыш рәвеше һәм гамәлләр белән ныгытылырга тиеш [Абу ‘Абдуррахман, б. 34]. Шуңа күрә дә мәрсия авторы шәехнең күркәм сыйфатларын тасвирлаганда аеруча «гамил» сүзен куллана. Бу шәехнең оста вәгазьче генә түгел, ә үзенең мисалында әйләнә-тирәдәгеләргә ислам этикасы күзлегеннән караганда чын мәгънәсендә яшәү рәвешен дәлилләп күрсәткән. Мәрсиядә Мөхәммәдзакир ишан ислам фәннәрендә югары гыйлемгә ирешкән галим, әмма гади күркәм кеше буларак тасвирлана. Р.Г. Әмирханов язганча, «тырыш хезмәте өчен аны хөкүмәт зур көмеш медаль белән бүләкли» [Амирханов, 2001, с. 70]. Дөрес, хөкүмәт органнары тарафыннан Мөхәммәдзакир ишанга булган яхшы һәм ихтирамлы мөнәсәбәт аның руслаштыру сәясәтенә, мәктәп һәм мәдрәсәләрдә рус телен укытуны кертүгә актив каршылык күрсәтә башлаганчы булуы турында мәрсиядә дә әйтелә: *Шунча галим булды аның фазыйләте, хуш холкыны, / Әмиринләр, хакиминләр сакладылар кадерене* [Мәрсия-и дамелла Мөхәммәдзакир хәзрәт, б. 9а].

Мәрсиянең икенче өлеше шәехнең вафатын тасвирлауга багышланган. Ул аерым хисләрнең тирәнлеге, нечкә психологизм һәм эмоциональлек белән аерылып тора. Автор шәехнең күп кенә тикшеренүчеләргә мәгълүм булган вафат булу датасын хәбәр итү белән бергә аның җаны бакый дөньяга төнге намаздан соң күчкәнлеген яза: *Сәна бең дә сигез йөз дә ки туксан өченче румийа / Җиһандин кәчде бер шәех, мең өч йөз унберенче тарихда / Шәрәф зөлкагъдә аенда егерме өченче йәүмендә / Әманәт рух-ы тәслимат көч атна кич йәсигъ бәгъдә* [Мәрсия-и дамелла Мөхәммәдзакир хәзрәт, б. 1 б]. Мәрсиядә шулай ук Мөхәммәдзакир Камаловның әүвәл дәвалап булмаслык авырганлыгы һәм ике көн, бер төн үткәннән соң вафат булганлыгы бәян ителә. Шәехнең соңгы минутларын автор тирән психологизм белән тасвирлый. Аның янында хатыны Бибифатыйма һәм кызы Гандәлиб булалар. Бибифатыйма ханым аңа иң ягымлы, иң гүзәл сүзләр белән эндәшеп, үзенең җылы хисләрен белдерә. Ул Аллаһка ялварып, иренә һәм балаларының әтисенә төрле яхшылыклар тели: *Җәлис улды баш тарафда Гандәлиб – рәис кызы / Һәм садыр тарафында улды Бибифатыйма зәүҗәсе. / Кәримәсе йалварды хуш мәкаль лотфилә: / Вай фәрзәндәләрем пәнаһы, гомеремнең сәрмайәсе дийүбән аһлә. / И, кәримем, зө-л-вафа, хөсне-р-риза, сәмма риза, / Ике җиһан шаһы*

*хушнуд улса иде һәб сәңа* [Мәрсия-и дамелла Мөхәммәдзакир хәзрәт, б. 2а]. Мөхәммәдзакир ишан, хәле авыр булуга кармастан, зур түземлелек күрсәтә. Ул үзенең якыннары, беренче чиратта бергәләп ундүрт бала тәрбияләп үстергән хатыны белән зур канәгатьләнү хисләре аша хушлаша: *Чук ризалык күстәреб рифкылә диде аңа: / Халеме хуш беленңез, димәңез тәкрар бәңа. / Рифкылә миһрилә бакды күзене Гандалибә, / Сыййхәтендә сүнәр (?) иде ул гаҗәб тәхәммел* [Мәрсия-и дамелла Мөхәммәдзакир хәзрәт, б. 2а].

Шәехнең вафат булу моментын автор символик деталь белән сурәтли: *Кабзә улынды рухы аның, калды кафәс фанәсе* [Мәрсия-и дамелла Мөхәммәдзакир хәзрәт, б. 6б]. Бу контекстта читлек җирдә каласы тәнне белдерә, ә җан кош рәвешендә күккә күтәрелә (гәрчә текстта кош образы булмаса да ул күзаллана). Гомумән, үлемне образлы тасвирлау төрки шигърияттә киң таралган. Аны без Йосыф Баласагуниның (1018–1075) «Котадгу белек» поэмасында ук очратабыз:

eḍizlik yiledi suzuk can turuġ
uçup bardı can ḳaldı kalbüd ḳuruġ.

[Arat, p. 169]

(Саф рухы югарыга, иң биек урынга омтылды,
Җаны очты, коры гәүдәсе калды).

Бу мотивны Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәрендә Йосыфның атасы Ягкуб вафаты тасвирланган моментта да күрәбез:

Шәриф тәндин айырулдый газиз җаный,
Коша бәңзәп оҗмах таба очар имди.

[Кол Гали, б. 208]

Алтын Урда шагыйре Котб та үзенең «Хөсрәү вә Ширин» әсәрендә җанның тәннән аерылуы турында шулай уйлана:

Бу сүз әйгинчә, нәгяһ вакты йитте,
Кафәсдин җаны кош тик, очты китте.

[Хисамов, б. 128]

Шулай итеп, мәрсиянең шәех Мөхәммәдзакир Камаловның соңгы минутлары тасвирланган икенче өлеше якты образ, бер яктан тирән суфичыл тамырлары булган, икенче яктан Урта гасырлар Шәрык мөселман әдәбияты традицияләренә барып тоташкан үзенчәлекле терминнар һәм символлар белән тулыландырылган.

Мәрсиянең күләмле өченче өлешендә Мөхәммәдзакир Камаловның күпсанлы варислары, кайбер мөритләре һәм аларның шәехнең вафатыннан соңгы язмышлары сурәтләнә. Тексттан күренгәнчә, шәехнең балаларыннан ике улы һәм ун кызы кала. Өлкән улы Ибраһимның вазифасына җомга вәгазе уку керә. Ул әле шактый яшь булу сәбәпле, мәрсия авторы аның янында тиешле юнәлеш биреп торучы атасы

булмаганга борчыла; ул, Аллаһтан аңа гыйлемен тирәнәйтүдә ярдәм итүен сорап, дога кыла: *Углы Ибраһим ки йәшьдер, хале дәгел фанәсе, / Мәсҗед-минбәрдә*[1] *хазир укый җомга хөтбәсе. / И Хода, нөсрәт вир аңа гыйльме-хикмәт хиссасы, / Анда мәүҗүд улса иде шәйхемезнең бәһрәсе* [Мәрсия-и дамелла Мөхәммәдзакир хәзрәт, б. 6б].

Шәехнең икенче улы Мөхәммәдисмәгыйльгә килгәндә исә, атасы вафат булганда аңа әле ике яшь тә тулмаган була. Мәрсия авторы аны болай тасвирлый: *Бер мөбарәк углы Мөхәммәд Исмәгыйль тәсмисе, / Әткәсенә охшайыбдыр сыйфаты һәм һийәте. / Гомер вирсен Хак Тәгалә, сакласын һәр афәте, / Ике йәше йитмәйенчә калды мәхрүм ул сабый* [Мәрсия-и дамелла Мөхәммәдзакир хәзрәт, б. 6 б].

Ишанның күпсанлы балаларының сыйфатлары турында сүз алып барып, автор сокланып болай ди: *Фазлы Хакдыр җан-күзең ач вә-с-сәлам, / Бу нә мәнзил, бу нә җәннәт бу мәкам!* [Мәрсия-и дамелла Мөхәммәдзакир хәзрәт, б. 9а]. Чынлап та, шәехнең байтак кызлары уңышлы кияүгә чыгалар; аларның ирләре югары белем алып, татар халкының билгеле шәхесләре булып җитешәләр.

Мәрсиядә Мөхәммәднәҗиб Әмирхановка шактый урын бирелгән һәм бу очраклы гына түгел. Билгеле булганча, ул – Мөхәммәдзакир Камаловның Мәчкәрә мәдрәсәсе буенча якын дусты Мөхәммәдхөсәен Әмирхановның (1814–1893) улы. Р.Г. Әмирханов мәгълүматына күрә, «1893 елда Чистайга Мөхәммәднәҗиб килә... Ул вакытта Мөхәммәдзакир каты авырый һәм аңа кешеләр белән җитәкчелек итү авырлаша. Үзенең вафатыннан соң рухани экренләп җитәкчелекне кемгә калдыру турында уйлана башлый. Февральдә Мөхәммәднәҗиб һәм шәех кызының туе була[2]... Шәехнең хәер-фатихасы белән Мөхәммәднәҗиб Чистай мөселманнары арасында актив эшчәнлек җәелдерә. Озакламый ул шәех Мөхәммәдзакир Чиставиның дәвамчысына әверелә» [Амирханов Р.У. Путь...]. Мөхәммәднәҗиб Әмирханга бәйле бу мәгълүмат берникадәр мөһим тулыландырулар белән мәрсиядә дә чагылыш тапкан. Әсәр авторы сүзләренә караганда, Мөхәммәднәҗиб, чынлап та шәехнең дәвамчысы (хәлифәсе) була. Чөнки ул төпле, ышанычлы һәм ныклы кеше буларак характерлана. Ул Мөхәммәдзакир ишанның мәхәббәтен һәм ышанычын казана, аңардан иҗазәт ала. Бу аңа мөритләр булдырырга хокук бирә. Шәех вафатыннан соң, Мөхәммәднәҗиб мәчеттә имам вазифасын башкара, остазы башлаган эшләрне дәвам иттерә. Мәрсиядән күренгәнчә, Мөхәммәднәҗиб Әмирхановның да Россиянең барлык тарафында да мөритләре күп була: *Имди калды ул мәкандә кияү мулла Нәҗиб, / Гыйльмелә, хыйльмелә мәүсуф булды хәзрәткә хәбиб. / Дәрсе мәшгуль калды, аны изен вирде би-тәмам, / Мәсҗед-михрабда хазир кылды аны ул имам... / Көлли әтрафдин мөридләр димәгә, хәдд, йук саны* [Мәрсия-и дамелла Мөхәммәдзакир хәзрә, б. 4а].

[1] Минбәр – кафедра, трибуна.

[2] М. Камаловның икенче хатыныннан туган кызы Камиләтенниса истә тотыла.

Мәрсиядән шулай ук Мөхәммәдзакир Камаловның Закир муллага кияүгә чыккан кызы Хәдичәнең бәхетсез язмышы турында да беләбез[1]. Тумышы белән Чистайдан булган Закир мулла мәдрәсәдә мөгаллимлек итә, ишан мәхәлләсендәге икенче мәчеттә имамлык итә. Әсәрдә бәян ителгәнчә, ул ишанның башка кияүләре кебек үк мөрите була һәм аңа буйсына; дин гыйлемен яхшы үзләштерә, Коръәнне яттан белә. Әмма Мөхәммәдзакирның вафатына өч ай калганда бакыйлыкка күчә. Мәрсиядә Хәдичәнең кичерешләре тирән психологизм белән сурәтләнә. Ишан үзе дә киявенең үлемен авыр кичерә, бу хәбәр аның йөрәгенә начар тәэсир итә: *Вафаты өч ай мөкаддәм иде шәйхдин шул заман, / Шәйхемезнең йөрәгенә гассә йагъды рәдд һаман* [Мәрсия-и дамелла Мөхәммәдзакир хәзрәт, б. 4а]. Хәдичәнең тормышында беренче кайгыдан соң икенчесе дә килә – атасы вафатыннан күп тә үтми ике яшен генә тутырган улы да үлә.

Мәрсиянең бу йомгаклау өлешендә Мөхәммәдзакир Камаловның остазы (мөршиде), тумышы белән Дагстанның Алмалы авылыннан булган Мәхмүд әфәнде әд-Дагстани әл-Алмалы (1810–1877) турында да мәгълүмат китерелә. Әсәргә шәех Мәхмүд әфәнденең могҗиза (карәмәт) күрсәтергә сәләтле булуы, вафатыннан соң Әстерхан төбәгендә җирләнүе турында бәян ителә. Автор Мөхәммәдзакир ишанның үз вакытында бик күп фәннәрдән камил остазда гыйлем алганлыгын әйтә: *Шәех Мәхмүд әл-Фәгал улдыр әһле камәл, / Камил остаз улмакыдин сабак алды би-мәҗал. / Нәчә фәндин хасыйл итмеш ул ирәнләр сөрүре, / Һәм кәрамәт садир улмыш, кабере идүр Әчтерхани* [Мәрсия-и дамелла Мөхәммәдзакир хәзрәт, б. 9а].

Мәрсиядә авторның суфичыл рухлы әйтемнәре теркәлгән. Алар кыска афоризмнар ролен башкаралар һәм, һичшиксез, әсәргә тәмамланган форма һәм сыгылмалылык биреп торалар. Мәсәлән: *Нитәккем җан тәндәдер, и мөмкинәт, / Җан кидәчәк, малың улыр би-сәбат* [Мәрсия-и дамелла Мөхәммәдзакир хәзрәт, б. 7 б], яки: *Раббенә, Раббе Кәрим, Могтыйәт! / Хөббе дөнйа илә итмә бези мат* [Мәрсия-и дамелла Мөхәммәдзакир хәзрәт, б. 12 б] һ.б. Бу афоризмнар урыны белән текстның аерым бүленешләренә «йомгак» ролен дә башкаралар. Мәсәлән, Мөхәммәднәҗиб Әмирхан мулла турындагы мәгълүматтан соң укыйбыз: *Нә өчен кәлдең вөҗүдә, бел, үзең, / Мәгърифәтлә, бел, нә җәүһәрең сүзең* [Мәрсия-и дамелла Мөхәммәдзакир хәзрәт, б. 14а], яки: *Әгәр гәрчәк ир исәң, мәрдра ул, / Фәна ул әүвәл, андин патша ул* [Мәрсия-и дамелла Мөхәммәдзакир хәзрәт, б. 15а]. Бу афоризм билгеле бер дәрәҗәдә Закир мулланың шәхесен ача. Ул суфичылык юлында булганда үз хезмәте белән үзенә икмәк табу өчен дөньяви эшләрдән дә читтә калмаган, күрәсең. Билгеле булганча, нәкышбәндиянең төп принцибы шулай: «Күңел – мәгъшукка (ягъни Аллаһка), кул – эшкә». Күп кенә татар суфи шагыйрьләре (Мәүла Колый, Әбелмәних Каргалый, Әхмәтҗан Тубыли һ.б.),

[1] Кызганыч ки, мәрсиядә Закир мулланың тулы исеме китерелми.

нәкышбәндия тарикате вәкилләре буларак, үзләренең югары гыйлемгә ия булуларына һәм җәмгыятьтә югары дәрәҗә биләүләренә карамастан, гади крестьян хезмәте белән шөгыльләнгәннәр, ә җир эшкәртү аларның шигырьләрендә игелекле шөгыль итеп җырланган. Мөхәммәдзакир Камаловның яшәү рәвеше дә шушы принципны ачык күрсәтә.

Әлеге мәрсия шәех Мөхәммәдзакир Камаловның, аның туганнарының һәм мөритләренең тәрҗемәи хәлләрендәге, эшчәнлекләрендәге фактларның зур булмаган өлешен генә чагылдыра. Галимнәрнең алга таба тикшеренүләре безнең бу өлкәдәге белемнәребезне тагын да киңәйтер һәм баетыр дип ышанасы килә. Чөнки Мөхәммәдзакир Камалов, Зәйнулла Рәсүлев, Галимҗан Баруди (1857–1921) кебек татар халкының үзенчәлеген саклап калуда, рухи мәдәният үсеше өчен көрәштә, милләттәшләренең шул замандагы һәм киләчәктәге бәхете өчен актив көрәшүчеләрнең хезмәтләрен өйрәнү хәзерге вакытта актуаль һәм зур әһәмияткә ия.

**Әдәбият**

*Абу ‘Абдуррахман Мухаммад б. ‘Абдулваххаб ал-Чистави.* Табсират ал-муршидин мин ал-маша’их ал-халидийин // Шуайб б. Идрис ал-Багини. Табакат ал-Хваджакан ан-Накшбандийа вас адат ал-маша’их ал-Халидийа ал-Махмудийа (на арабском языке). Дамаск: Дар ан-ну‘ман ал-‘улум, 1999. С. 5–76.

*Амирханов Р.У.* Закир ишан Камалов и татарское просвещение // Гасырлар авазы – Эхо веков. 2001. № 1/2. С. 69–78.

*Амирханов Р.У.* Знаменитость всероссийского масштаба (Закир ишан Камалов) [Электронный ресурс]. URL: http://www.tataroved.ru/institut/novhist/publ/3/ (Мөрәҗәгать ителде: 20.01. 2015).

*Амирханов Р.У.* Путь шейха Мухаммад Закира Чистави. URL: http: // www. sufizm.ru / lib/douknow/chistavi/ (Мөрәҗәгать ителде: 03.06.2018).

*Баласагунский Юсуф Хасс-Хаджиб.* Наука быть счастливым / пер. Наума Гребнева. М.: Худ. лит., 1971. 160 с.

*Клепиков С.А.* Филиграни и штемпели на бумаге русского и иностранного производства XVII–XX вв. М.: Изд-во Всесоюзной книжной палаты, 1959. 304 с.

*Кол Гали.* Кыйссаи Йосыф. Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. 443 б.

*Миңнегулов Х.* Татарларда ислам дине // Мирас. № 4. 1998. Б. 112–115.

Мәрсия-и дамелла Мөхәммәдзакир хәзрәт // ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге. 39 ф., 1 тасв., 3251 сакл. бер.

*Саджади, Саид Джа’фар.* Словарь мистических слов, терминов и выражений. Тегеран, 1971. 734 с. (Фарсы телендә).

*Хасавнех А.А.* Биографические сведения о татарском шейхе Мухаммад Закире ал-Чистави в дагестанских арабоязычных рукописях // Известия Дагестанского государственного педагогического университета. Общественные и гуманитарные науки. 2012. № 1(18). С. 78–81.

*Хасавнех А.А.* Биография татарского накшбандийского шейха Мухаммад-Закира ал-Чистави (Камалова) в дагестанских арабоязычных сочинениях // Суфизм: идеи, практики, институты. Традиции и современность (Международный научно-методологический семинар). Киев, 2012. С. 10–13.

*Хасавнех А.Ә.К., Мөхәммәтҗанова Л.Х.* Әбү Бәкер Каландар Руминың «Каландар-намә» исемле суфичыл әсәрендә мәхәббәт классификациясе // Фәнни Татарстан. 2022. № 3 (35). С. 36–45.

*Хасавнех А.А.* Сочинение татарского шейха Мухаммад-Закира ал-Чистави «Табсират ал-муршидин»: краткий обзор // Суфизм: идеи, практики, институты. Традиции и современность (Международный научно-методологический семинар). Киев, 2012. С. 13–15.

*Хисамов Н.* Бөек язмышлы әсәр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. 336 б.

*Arat A.A.* Kutadgu Bilig. I. Metin. 2 baskı. Istanbul: Turk Dil Yayınları, 1979. 432 s. (Төрек телендә).

***Хасавнех Алсу Әхмәдулла кызы,***
*филология фәннәре докторы, Болгар ислам академиясе*
*Ислам мирасы үзәгенең өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 82-2

***Ф.Х. Миңнуллина***

# СУГЫШ ЧОРЫ ТАТАР ДРАМАТУРГИЯСЕНДӘ ЗАМАН ҺӘМ ГЕРОЙ

В статье проведен краткий обзор общих тенденций развития татарской драматургии 1941–1945-х гг.. Определены изменения концепции героя, основная тематика и идейно-эстетические особенности татарской советской драматургии изучаемого периода.

**Ключевые слова:** татарская драматургия, герой, конфликт, драма, трагедия.

The article provides a brief overview of the general trends in the development of Tatar drama in the 1941–1945's. Changes in the concept of the hero, the main theme and ideological and aesthetic features of the Tatar Soviet dramaturgy of the studied period are determined.

**Keywords:** Tatar drama, hero, conflict, drama, tragedy.

Сугыш еллары татар драматургиясенең тематик-проблематик колачын заман таләбе билгеле. Бу елларда язылган сәхнә әсәрләренең үзәгенә совет халкының илбасарларга каршы бердәм көрәше куела, гуманизм, фашизмга нәфрәт, Ватан азатлыгы, халыкның җиңелмәс көче, героик сыйфатлары, саф мәхәббәт, фидакяр хезмәт кебек мәсьәләләрне яктыртуга игътибар бирелә. Бу елларда «Ватан өчен!», «Җиңү өчен!» лозунглары гомумән әдәбиятны иңләп ала. Патриотик пафос алга таба да сугыш темасына язылган әсәрләрнең үзәгендә тора. Батыр солдат, тыл тормышында хезмәт куйган, ил өчен үз гомерен аямаган каһарман образлар алгы планга чыга. Ә. Фәйзинең «Шәмгун Тависов», «Үз ялганнарының корбаны» (1942), «Юләрләр йортындагы вакыйга», «Акчарлаклар» (1941–1949) пьесалары сугыш вакыйгалары турында сирәк комедияләр буларак игътибарны җәлеп итәләр. Совет халкының 1941–1945 елларда немец-фашистларга каршы алып барган көрәше М. Әмир («Миңлекамал», «Тормыш җыры»), Т. Гыйззәт («Төнге сигнал», «Изге аманәт»), Н. Исәнбәт («Мәрьям»), Ф. Кәрими («Шакир Шигаев»), Р. Ишморат («Кайту») һ.б. авторларның драмаларында урын ала.

Сугышның башлангыч чорында язылган пьесалар, нигездә, совет кешесенең героизмын, батырлыгын, тырышлыгын, фидакярлеген романтик рухта һәм поэтик яңгырашта бирүләре белән үзенчәлекле (Т. Гыйззәт. «Төнге сигнал»; М. Әмир. «Партизан Иван»; Н. Исәнбәт. «Мәрьям»; Р. Ишморат «Ватан кызлары»; Г. Насрый. «Таныш кешеләр», «Патриотлар семьясы»). Героик эчтәлекле әсәрләрнең поэтик күтәренкелеге, лиризмы ватандашларның оптимистик рухына, җиңүгә ышанычына, матур киләчәккә зур өмет белән яшәвенә нигезләнә. Р. Ишморатның «Кайту» (1942), М. Әмирнең «Миңлекамал» (1944) пьесалары, К. Нәҗминең «Фәридә» (1944) драматик поэмасы кебек

әсәрләр бу яктан иң характерлы үрнәкләр булып торалар [Ханзафаров,1989, б. 345].

Бөек Ватан сугышы еллары пьесаларын тематик яктан түбәндәге төркемнәргә бүлеп карарга мөмкин:

1. Фронт: Н. Исәнбәт. «Мәрьям»; Ф. Кәрим. «Шакир Шигаев».

2. Дошман тылындагы көрәш: М. Әмир. «Партизан Иван»; Т. Гыйззәт. «Ил агасы» (1941), «Төнге сигнал» (1941).

3. Тыл тормышы: Р. Ишморат. «Кайту» (1942); М. Әмир. «Миңлекамал».

4. Фольклор материалларына нигезләнеп иҗат ителгән сәхнә әсәрләре: Н. Исәнбәт. «Җирән Чичән белән Карачәч Сылу», «Түләк» һ.б.

5. Тарих һәм тарихи шәхесләр: Н. Исәнбәт. «Мулланур Вахитов», «Гөлҗамал» һ.б.

Т. Гыйззәтнең 1930–1950 еллар иҗаты Бөек Ватан сугышы фаҗигаларын, Ватанны саклау темасын яктыртуы белән үзенчәлекле. Драматургның «Таймасовлар», «Төнге сигнал», «Изге әманәт», «Чын мәхәббәт» драмаларында әдип фашизмга каршы көрәшкә күтәрелгән халык вәкилләренең сугыш кырындагы һәм тылдагы батырлыкларына дан җырлый. Т. Гыйззәтнең ак финнар белән сугыш башлану көннәрен чагылдырган «Таймасовлар» (1939) пьесасында фашистларның совет иленә һөҗүм итү ихтималлыгына ишарә бар. Г. Кутуй фикеренчә: « Таймасовлар семьясында без үзебезне, үзебез белән бергә яшәгән дусларыбызны, иптәшләребезне күрәбез... Совет патриотизмы чиксез: бездә бөтен халык – бер кеше өчен, бер кеше бөтен халык өчен яши... Таҗи Гыйззәт иптәшнең патриотик хис белән язылган бу яңа әсәре Татар дәүләт академия театрында әнә шулай яңгырады» [Кутуй, 1941]. Ә. Закирҗанов фикеренчә, драматургның «Мактаулы заман» (1935), «Таймасовлар» (1941) кебек пьесалары заман рухын чагылдыруы һәм чорга туры килгән геройларны сәхнәгә менгерүе белән игътибарга лаек» [Закирҗанов, б. 345]. Совет патриотизмы темасын калку итеп күтәргән бу әсәр өч бертуган Таймасовларның, фин сугышы фронтында батырлыклар күрсәтеп, җиңү яулап әйләнеп кайтуларын сурәтли. Яңа гына мәктәп тәмамлаган Марат Таймасов исә аеруча зур каһарманлык күрсәтә. Ул кышкы салкын көнне агымсуны йөзеп, чолганыштан чыга, машинага утырып, дошман тылына керә. Дошманны җиңел генә тар-мар итеп, батырлыклар кылу – шул чорга хас күренеш. Сугыш пьесада гадиләштереп, беркатлырак итеп бирелә. Дөрес, анда совет кешеләренең матур уйлары, «Таймасовлар танк экипажы»н төзегән гаиләнең героик эшләре турында шактый мәгълүмат бар. Әмма сәхнә әсәренең спецификасы ноктасыннан караганда, пьесаны көрәшсез тасвирлау, геройларның батырлыгы башка персонажлар сөйләменнән генә билгеле булуы аны шактый ук кызыксыз итә, ярлыландыра.

Сугыш елларында татар халкы, совет иленең барлык тугандаш халыклары белән бер сафта дошманга каршы көрәште. Т. Гыйззәт-

нең «Ил агасы», «Төнге сигнал» (1941), М. Әмирнең «Партизан Иван» кебек сәхнә әсәрләре дә – шуның мисалы. Әсәрләрдә Бөек Ватан сугышы еллары героизмы партизаннар хәрәкәтен сурәтләү аша тергезелә. Дөрес, бу әсәрләр сугыш хакыйкатен һәм дәһшәтен реалистик чагылдыруда беренче адым гына булып тора һәм геройларның кылган батырлыклары да ышандыру көченә ия түгел. Т. Гыйззәтнең «Төнге сигнал» драмасында да батырлык бик җиңел эшләнә: дошман тылына әйләнгән авылдагы Антон картның өендә, яшерен мич куышында качып калган яралы кызылармияче Мансур немец солдатларын берүзе юк итә, партизаннарга авылга һөҗүмгә кучәргә сигнал бирә. Әсәр, әлбәттә, фронт чынлыгыннан байтак ерак тора. Әмма вакыйгалар динамикасы, кителмәгән маҗаралар тамашачыны киеренкелеге белән мавыктыра, халыклар дуслыгы идеясе, дошманга чиксез нәфрәт аңа сәхнә тормышын тәэмин итә. М. Әмирнең «Партизан Иван» дип исемләнгән пьесасында кискен интригалар ярдәмендә характерлар шактый ук тулы ачылалар. Дударь Иван гаиләсендәге бердәмлек, дошманга карата аяусыз булу — совет партизаннарының көчен, аларның аң һәм физик сәләтләрен билгеле бер дәрәҗәдә ачып бирә. Биредә Иван Дударьлар гаиләсенең кыюлыкларын, Бойкодагы җитезлекне, Васюк, Мостафа кебек Кызыл Армия сугышчыларының батырлыкларын, колхоз хуҗалыгы белән оста җитәкчелек итүче, сугыш шартларында кешеләрне үз артыннан ияртә алучы Иван Дударьның эш-гамәлләрен мисал итеп китерергә мөмкин. Шулай да, бу М. Әмирнең «Партизан Иван» (1941), Т. Гыйззәтнең «Төнге сигнал» (1941) пьесалары чынбарлыктан ерак торган сәхнә әсәрләре буларак кабул ителәләр.

Я. Агишев фикеренчә, Т. Гыйззәтнең Бөек Ватан сугышы темасына караган «Изге әманәт» (1945) драмасы язучы иҗатында мөһим урын алып тора. Мәкалә авторы язганча, әсәрдә Ватанны саклауда халкыбызның патриотик батырлыгы, бердәмлеге реаль образлар ярдәмендә ачып бирелә [Агишев, 1946]. Т. Гыйззәт әлеге пьесасын иҗат итү максатын күздә тотып, 1944 елның май-июнь айларында Донбасста, татар шахтерлары яшәгән шәһәрләрдә була. Биредә күргәннәрен, үз фикерләрен очеркларында да язып чыга. «Татарлар» дип аталган язмасы – шуларның берсе. «Ватан сугышы башланып, Донбасска куркыныч туу белән, татарларның кайберләре эчке Россиягә кайтканнар. Кайберләре, немец оккупациясе астында калып, төрле авырлыклар кичергәннәр. Оккупация вакытында татарларның бер өлеше, Германия командованиясенең аерым приказлары буенча, завод, шахталарда эшләргә мәҗбүр ителгәннәр... Бик күп кенә яшьләр Германиягә эшкә көчләп озатылган. Икенче өлеше – Германиягә озатылу, завод-шахталарда эшләү каторгасыннан котылу теләге белән, массовый рәвештә авыл хуҗалыгы районнарына китеп эшлиләр....» [Гыйззәтов, 2000, б. 68], – дип яза ул. Әсәрнең үзәгендә дошман әсирлегендә калган Донбасс җирләрендәге хәлләр, төрле милләт вәкилләренең илбасарларга каршы көрәше, фаҗигалы язмышлары урын ала. Биредә

татар халкы һәм башка милләт вәкилләре бердәм рәвештә Ватанны азат итү, бәйсезлек өчен гомерләрен кызганмыйча көрәшәләр. Вакыйгалар сугышның беренче елларына карый. Донбасс шахтерлары арасында күмер чыгару остасы булып танылган Гыйният Галимҗанов гаиләсе фашистлар тылында кала. Шахта мөдире булып эшләгән Фуат әтисе Гыйнияткә шахтаның планын сакларга тапшыра. Драмада Мастер Гыйният, шахта мөдире Фуат, стахановчы Остап, партизан Мартынов кебек фидакяр геройлар бу планны дошман күзеннән саклау (изге әманәт) өчен җитди көрәш алып баралар. Илбасарлар, стратегик әһәмияткә ия документны эләктерү нияте белән, Гыйниятне кулга алалар. Үлем алдында торуын белсә дә, драманың герое Ватан азатлыгы өчен үз-үзен аямый, батырларча үлемгә бара. Хәзинә әбинең әлеге планны яшереп кала алуы, Гыйниятнең аның өчен гомерен бирүе тирән фәлсәфи эчтәлеккә ия. Ул совет кешеләренең киләчәктәге якты көннәре символы дәрәҗәсенә күтәрелә. Финалда Фуатның бу планны югары тотуы, фашистлардан үч алырга ант итүе дә – шуның ачык мисалы. Әсәрнең исеме дә тирән мәгънәгә ия: оккупациядә калучылар Ватаннарына булган мәхәббәтләрен саклап калалар. Гыйният, Лида, Нәҗия, Әсфан кебекләр үлемгә баралар, дошманга бирелмиләр. Аларга илбасарларга гына түгел, ә дошманга хезмәт итүче Әбүзәр, Асия кебек хыянәтчеләргә каршы да көрәшергә туры килә. Шушы конфликтка бәйле рәвештә, әсәрдә гаилә драмасы, фаҗигалары калкып чыга. Сөйгәне Әсфанны үзе дә белмичә дошман кулына тоттырган Нәҗия драмасы, Әсфанның җизнәсе Әбүзәрнең, дошманга ярарга тырышып, кодасы Гыйниятнең фаҗигалы үлеменә сәбәпче булуы шундыйлардан. Әсәр сугыш вакыйгаларын психологик яктан нигезле һәм дәлилле итеп ачуы ягыннан да, сәнгатьчә эшләнешнең югарырак булуы белән дә, характерлар бөтенлеге, геройларның үз амплуаларында тулырак ачылу җәһәтеннән дә отышлы [Драматургиядә утлы еллар авазы, 2010, б. 5]. Гомумән, татар әдәбиятын тамырдан үзгәрткән сыйфатларның берсе – тирән психологизм һәм гомумкешелек фәлсәфәсе белән сугарылган булу. Бу яктан Н. Исәнбәтнең «Мәрьям», Ф. Кәримнең «Шакир Шигаев» сәхнә әсәрләре игътибарга лаек.

Дошман ягында хезмәт итүче образлар Н. Исәнбәтнең Бөек Ватан сугышы елларында, халыкның тылдагы батырлыкларына багышлап язылган «Мәрьям» трагедиясендә урын ала. Башка милләтләр белән бергә, татар халкының данлыклы уллары һәм кызлары да батырларча сугышалар, Ватанны немец вәхшиләреннән саклау өчен үзүзләрен аямыйлар. «Нәкый Исәнбәт иптәш “Мәрьям” пьесасын әнә шул көрәшнең бер героик эпизодын, батыр көрәшчеләрен һәм дошманның ерткычлыгын күрсәтүгә багышлаган», – дип яза Х. Хәйри, әсәрне бәяләп. Пьесада, нигездә, Кызыл Армиянең вакытлыча чигенү моментында туган хәлләр бирелә. Совет патриотлары – колхозчылар, партизан отряды оештырып, дошман тылында көрәш ачалар. Трагедия үзәгенә тыныч профессия кешеләре алына. Алар арасында гуманистик идеяләр белән яшәгән шәфкать туташлары Суфия белән Мәрь-

ям, гади авыл халкы бар. Әсәрнең төп геройларының берсе Мәрьям тыйнак, сабыр характерлы, мәхәббәт романтикасы белән чолганган кыз, укытучылык эшен калдырып, җиребезне басып алучылардан саклаучылар сафына баса. Әсәрдә чолганышта калган авыл халкының сугышның беренче көннәрендә югалып калуы, тәҗрибәсезлеге кебек вакыйгалар сурәтләнә. Алар бу сугышны чик буендагы бер бәрелеш буларак кына кабул итәләр. Биредә сугыш кырындагы тәҗрибәсезлек, төгәлрәк әйткәндә, дошманны танымаудагы тәҗрибәсезлек трагик хата булып тора. Мәрьям Иоһанның, совет сугышчысы киемен киеп, яшь сабый Илдүсне күтәреп килгәндә, «үзебезнекеләр» дигән сүзенә ышанып, төзәтеп булмаслык, ахырда фаҗига белән тәмамланачак трагик хата ясый (кызны дар агачына асып куялар). Илбасарлар кулына әсирлеккә төшкән кыз үлемне горур каршы ала. Мәрьямне аскан вакытта да, аның иң соңгы сүзләре Ватаны, туган җире, туганнары турында була. Ул, туган иле ягына карап: «Юк, минем илем бу якта. Хуш, әни! Газиз туган халкым! Күземнең соңгы нуры сиңа булсын!» – ди. Дошман солдаты, яшь кызның бу рухи көчен күреп, тетрәнеп китә. Пьесада хыянәтче Захар һәм немец ефрейторы Иоһан образлары чынбарлыктагыча гәүдәләндерелгәннәр. Алар кабатланмаган оригиналь образлар буларак тәкъдим ителгән. Дошманны тискәре амплуага куйган әдәбиятта бу яңалык була. Драматург үз геройларының «тормыш тарихын», теләк-омтылышларын ачып бирә. Мәрьям кебек фидакяр геройлар туган нигезе, иле өчен гомерләрен бирсәләр, элеккеге кенәз, эмигрант Лыков исә дошман ягында тәрҗемәче вазифасын башкара. «Әйе, мин – Лыков. Сез мине беткән иде дип уйлаган идегезме? Урманны кистегез, җиремне сөрдегез, менә хәзер мин кайтып, сезнекеләрне тагын җиремнән сөрәм, туташ» [Исәнбәт, 1968, б. 217], – дип аңлата ул үзенең эш-гамәлләрен. Әйтергә кирәк, язучының 1956 елда язылган «Муса Җәлил» трагедиясендә дә драматург сугыш фаҗигасында буыннар, милләтләр фаҗигасын чагылдырырлык геройларны әдәбият мәйданына чыгара. Н. Исәнбәт туган җирләреннән Алман иленә күчеп киткән, туганлык җепләрен югалткан Зәбир Альбиков нәселенең өч буын вәкилләрен сурәтли: Зәбиргә, Лыков кебек, туган җиренең малы гына кирәк; улы Фәрит туган телен оныткан, халкының милли йолаларын белмәгән һәм белергә теләмәгән каты күңелле кеше булып үсә, гореф-гадәтләреннән, теленнән аерылган, туган халкының җырын ишетүгә сусап яшәгән Газизә карчык туган туфрагына кайтып үлү теләгенә дә ирешә алмый.

Фронт тормышы уңышлы ачылган «Шакир Шигаев» (1944) пьесасында Ф. Кәримнең үзәк герое – разведка офицеры Шакир Шигаев. Пьесаны композицион яктан бер максат – күпер шартлату бурычы бәйләп тора. Әлеге әмерне үтәү җанны кызганмауны таләп итә. Үзәк герой җитди сынау кичерә. Драматик конфликт шәхеснең рухи дөньясына күчә: кешенең мораль бөеклеге романтик яссылыкта раслана [Ханзафаров, 2017, б. 345 ]. Н. Исәнбәтнең «Түләк» (1942) драматик поэмасының нигезен дә халыкта яшәгән өмет-хыяллар,

легенда-риваятьләр тәшкил итә. Н. Исәнбәт либреттосына Н. Җиһанов иҗат иткән «Түләк» операсы театр сәхнәләрендә зур уңыш белән бара. Текст болгарларның илбасарларга каршы көрәшенә багышланган, әлеге каршылыкны Алимбәк ханның кызы Аембикә белән Түләк арасындагы мәхәббәт тагы да кискенләштерә. Кыз тарафыннан кире кагылган Сартлан Болгар иленә монгол гаскәрләрен алып килә. Бу көрәштә хан да, аның кызы Аембикә дә үтерелә. Халык авыз иҗатындагы кебек үк, кол анадан туган, кыерсытылган, әмма Ватаны, мәхәббәте өчен җанын да кызганмаган Түләк, халкын яклап, дошманга каршы күтәрелә. Әсәрдә аның бабасы – чал чәчле ил карты образы бар, ул «Идегәй» дастанындагы халкыбызның үткән тарихын гәүдәләндергән Субра кебек ил агасы булып күзаллана [Ханзафаров, 1982, б. 111]. Язучының «Җирән Чичән белән Карачәч-Сылу» комедиясендә кораллы көрәшкә акыл, үткенлек, зирәклек каршы куела. Төп каһарманы Җирән хезмәт кешеләрен чит илләргә ялланган солдат, кәнизәк итеп озатуга, өстен сыйныфларның үз ватандашларын сатып табыш алуларына каршы чыга. Ул илләр арасындагы бәхәсләрне тыныч юл белән хәл итә: хан да аның шәхси хокукларын таный, егетне ирекле дип белдерә. Җирән Чичән – шулай ук халык үзе тудырган образ. Н. Исәнбәт Карачәч-Сылу һәм Җирән Чичән образларында халыктагы җорлык, тапкырлык, акыл көче кебек сыйфатларны туплап бирә. «Түләк», «Җирән Чичән белән Карачәч Сылу» (1942) кебек әсәрләрдә драматург хакыйкатьне, халык мәнфәгатьләрен яклап чыккан геройлар – халык арасында гасырдан гасырга күчеп яшәгән әкияти каһарманнарны тергезә. Тарихи трагедияләрдән булган «Идегәй» (1938–1941) илдә патриотик рух күтәренкелеге хөкем сөргән чорда заказ белән иҗат ителә. Н. Исәнбәт эпосның 17 вариантын файдаланып, җыйнама вариант әзерли һәм аны 1940 елда «Совет әдәбияты» журналында махсус язылган мәкалә белән бастырып чыгара. С. Липкин эпосны рус теленә тәрҗемә итә башлый. Трагедия Казанда күрсәтелә, 1941 елда Мәскәүдә буласы татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы программасына кертелә. Әмма сугыш башланып китә. 1944 елның 9 августында ВКП(б) Үзәк Комитеты тарафыннан кабул ителгән «Татарстан партия оешмасында масса-политик һәм идеологик эшләрнең торышы һәм аларны яхшырту чаралары турында» дигән карарда татар халкының «Идегәй» дастанына «ханнар-феодаллар эпосы» дигән нахак бәя бирелә. Аны халыкка каршы юнәлдерелгән әсәр дип атыйлар. Н. Исәнбәт иҗат иткән трагедия дә шундый ук язмышка дучар була. «Идегәй» дастаны 1980 еллар ахырында гына халыкка кайта. Н. Исәнбәт әсәрендә Идегәй образы, изелгәннәрне яклаучы буларак, тарихка һәм халык авыз иҗатына (дастанга) тугрылыклы рухта языла. Ул – кыю хәрби җитәкче, дәүләт эшлеклесе, драматик язмышлы ата, ил азатлыгы һәм иминлеге өчен көрәшүче фидакяр. Заман «тәнкыйтьчеләре» Идегәйне «хезмәт иясе вәкиле» буларак сурәтләргә тәкъдим итәләр. Алай тарихилык бозылачак дип, Н. Исәнбәт башка юл таба: эпоста булмаган «хезмәт ияләре»н әсәргә кертә (Янбулат, сукачы Кил-

мәт, Чулпан һ.б.) [Ханзафаров, 2017, б. 251]. Трагедиядә халык дастанын турыдан-туры кабатлау юк. Үзәк конфликт итеп Идегәй белән Туктамыш хан арасындагы көрәш алына, дәүләт язмышының аерым бер кешеләр холкына, теләк-омтылышларына мәгълүм дәрәҗәдә бәйле булуы тасвирлана.

1944 елның 28 мартында Татарстан Сәнгать эшләре идарәсе заман һәм тарих темасына караган пьесаларга конкурс оештыра. Батырлык, героика хакында язу, көрәшкә рухландыру драматургиядә тарихи теманың популярлашуына китерә. М. Гали, Х. Уразиковларның «Каюм Насыйри» (1944), Н. Исәнбәтнең «Нур Заһит» («Мулланур Вахитов»), «Гөлҗамал» (1944) кебек сәхнә әсәрләре әдәбият мәйданына чыга. Мәсәлән, Н. Исәнбәтнең «Мулланур Вахитов» (1943–1944) героик драмасында Октябрь инкыйлабы һәм Гражданнар сугышы елларында эшче-крестьяннарга бәйсезлек яулау юлында үзен корбан иткән каһарман М. Вахитов гәүдәләнә. Н. Исәнбәтнең «Гөлҗамал» драмасында татар халкының XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар тормышы, татар театрының беренче адымнары тасвирлана. Үзәктә – беренче татар актрисасы Гөлҗамал һәм алдынгы карашлы зыялылар, татар театрын үстерүче яшьләр. Вакыйгалар барышында бу фидакярләрнең авыр язмышы, труппа эчендәге каршылыклар, Гөлҗамалның «Сәйяр» төркеменнән китеп, Уфада «Нур» татар театры труппасы оештыруы барлык нечкәлекләре белән сурәтләнә. Үткән тарихка мөрәҗәгать итеп, драматург тигезлек, туганлык, ирек, бәхет кебек мөһим гомумкешелек кыйммәтләре өчен көрәшү мәҗбүрияте проблемасын күтәрә. Әмма ВКП(б) ҮКның 1944 ел 9 август карары белән татар әдәбиятында һәм сәнгатендә тарихи темаларны яктыртуга киртә куела.

Сугышның башлангыч чорында язылган сәхнә әсәрләрендә, нигездә, совет кешесенең героизмы, батырлыгы романтик рухта яктыртылса, чынбарлыктан ерак булган вакыйгалар бирелсә, соңрак Р. Ишморатның «Кайту» (1942), М. Әмирнең «Миңлекамал» (1944) К. Нәҗминең «Фәридә» (1944) кебек реалистик пьесалары иҗат ителә [Шәрипова, 2022, б. 96].

Ватан сугышы чоры драматургиясен өйрәнгәндә хезмәт ияләренең тылдагы батырлыкларын да читләтеп үтү мөмкин түгел. Мәсәлән, 1944 елда М. Әмир сугыш чоры авылы һәм авыл кешесенең героик хезмәтен, көнкүрешенең авырлыкларын күрсәткән «Миңлекамал» драмасын яза. Г. Кашшаф билгеләгәнчә, ««Миңлекамал» драмасы сугыш чорындагы колхозчылар массасын объектив гәүдәләндергән художество әсәре һәм ул татар совет әдәбиятының бүгенге юнәлешен характерлавы белән дә әһәмиятле» [Кашшаф, 1941, б. 67]. Бу әсәрдә Бөек Ватан сугышы чорында тылдагы халык язмышы, көнкүреше сурәтләнә. Әдипнең максаты — шул чордагы тыл каһарманнарының батырлыгын укучыга җиткерү. Сәхнә әсәрендә реаль тормыш тасвирлана, шул заман өчен характерлы булган типик вакыйгалар, ситуацияләр бирелә, шактый тулы эшләнгән җыйналма образлар урын ала.

Татар драматургиясендә үз вакыты өчен өр-яңа образ, көчле шәхес буларак тәкъдим ителгән Миңлекамал ярдәмендә, автор кешенең ныклыгын, тормышның бик авыр вакытларында кыю булып кала алуын тасвирлый. М. Әмир аерым колхозларның таркаулыгын кызыклы детальләр аша бирә. Символ рәвешендә районның сәгате бер сәгатькә ким сугу – шуның бер мисалы. Миңлекамал үзен таркалып барган «Яшел алан» колхозының рәисе итүләрен сорый һәм, бар көчен җыеп, авырлыкларга каршы бара, аның үзенә төшенкелеккә бирелергә рөхсәт итми яшәве, хезмәт итүе алгы планга чыгарыла. Авылда эшче куллар җитми, техника юк, маллар ачтан үлә, соңгы атлар да фронт өчен дип алына. Әмма аның ихтыяр көче шулкадәр зур, хатын-кызлар, картлар, яшүсмерләрне дә армый-талмый эшләргә этәрә, көч бирә, башкалар өчен үрнәккә әверелә. Биредә, М. Әмир сугыш чоры шартларында тылда хезмәт куйган хатын-кызны беренче планга куя. Миңлекамалның иң дөрес юлы – яшьләрне үз белдекләре белән эшләтмәвендә, аларны картларның ныклы күзәтүе астына куюында. Аерым кискен моментта Мәхмүтнең яңагына сугып җибәрүе дә психологик яктан аклана. Ул шул вакытта кырыслык һәм апа шәфкатьлелеге дә күрсәтә. Хезмәт патриоты, тормыш һәм көрәш эчендә кайнарга омтылучы актив шәхес буларак ачыла. Фронттан иренең үлүе турында хәбәр килү дә, ягъни геройның шәхси трагедиясе дә аның ихтыяр көчен сындырмый. Шунысын да әйтергә кирәк: тыл тормышын сурәтләгән әсәрләрдә дә психологик анализ, кешенең күңел дөньясына үтеп керү тирәнәя. Р. Ишморатның «Кайту» пьесасы да – шундый әсәрләрнең берсе. Әсәр авторы сугыш кырында яраланып, гарипләнеп кайткан фронтовик Хәмитнең, аның якыннарының рухи дөньясын бөтен тулылыгында ачып бирә. Психологик кичерешләрне ачу ягыннан колхоз председателе Мөршидә образы да игътибарга лаек. Чиста, саф күңелле, әхлаклы бу ханымны авырлыклар сынап кына тора: ире Хәмитнең үлүе турында хәбәр алуы; вакытлар үтү белән ялган гайбәт таралу (авыл советы председателе Ильяс белән чуалу). Бу хәлләр Мөршидәне олы максатларыннан аера алмый, ул авырлыкларны җиңеп, эшен дәвам итә, үзен гарип, артык дип санаган Хәмитне тормышка, хезмәткә кайтара, яшәүгә өмет уята.

Гомумән, сугыш чоры татар драматургиясендә тыл геройлары, Ватан сакчылары: партизаннар, разведчиклар, шәфкать туташлары һ.б. алгы планга чыга. Татар драматурглары кешеләр аңындагы үзгәрешләрне тасвирлау аша каһарман татар кешесе концепциясенең татар әдәбиятындагы үзгәрешен күрсәтәләр. Тематик яктан сугыш чоры драматургиясе разведчиклар тормышын, партизаннар кыюлыгын, фашистлар кылган җәбер-золымны, әсирлекне, тылдагы тормышны сурәтләү ярдәмендә киңәя, тармаклана.

Бу чор әдәбиятының үзенчәлеге – яшәү һәм үлем, ирек һәм коллык, батырлык һәм куркаклык, фидакярлек һәм хыянәт төшенчәләре арасына кеше җаны, рухы куелуда.

**Әдәбият**

*Агишев Я.* Изге аманет // Красная Татария. 1946. 23 июля.

*Ахмадуллин А.Г.* Татарская драматургия: истоки и проблемы. Казань: Татар. кн. изд-во, 2012. 511 с.

*Гыйззәтов К.* Таҗи Гыйззәт // Т. Гыйззәт Татарлар. Казан: Мастер Лайн, 2000. Б. 67–70.

Драматургиядә утлы еллар авазы: гомуми белем бирү мәктәпләре, урта һәм югары педагогик уку йортлары өчен уку әсбабы. 15 томда. 3 т. Казан: Татар. Республикасы «ХӘТЕР» нәшр., 2010. 5 б.

*Закирҗанов Ә.* Иҗат тылсымы: әдәби портретлар, күзәтү мәкаләләре, рецензияләр. Казан: Мәгариф – Вакыт, 2022. 416 б.

*Исәнбәт Н.* Сайланма әсәрләр: 3 томда. 3 т.: пьесалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1968. 217 б.

*Кашшаф Г.* Патриотизм көче // Совет әдәбияты. 1944. № 5. Б. 67.

*Кутуй Г.* Таймасовлар // Кызыл Татарстан. 1941. 31 июль.

*Ханзафаров Н.* Татар әдәбияты тарихы : 6 томда. 5 т.: Бөек Ватан сугышы һәм сугыштан соңгы еллар әдәбияты (1941–1960). Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. 447 б. 536 б.

*Ханзафаров Н.* Нәкый Исәнбәт драматургиясе. Казан: Татар. кит.нәшр., 1982. 181 б.

*Ханзафаров Н.* Татар әдәбияты тарихы: 8 томда. 5 т. : XX йөзнең 20–50 нче еллары. Казан : Татар. кит. нәшр., 2017. 2017. 623 б.

*Шарипова А.С.* Татарская драматургия XX – начала XXI века: проблема инварианта. Казань, 2022. 336 с.

***Миңнуллина Фатыйма Хәлиулла кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият белеме бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 82.512.1–131

*Л.Х. Мөхәммәтҗанова*

# ДАСТАНИ ОБРАЗГА АЧЫКЛЫК – ТАРИХИ ЧЫГАНАКЛАР АША:

## Чура Нарык улының Казан ханлыгы тарихындагы эшчәнлегенә экскурс

Статья посвящена проблемам исторического объяснения богатого эпического материала по народному творчеству. В научной литературе фигурирует мнение о том, что прототипом главного героя дастанов о Чуре батыре является общественно-политический деятель Казанского ханства Чура Нарыков. Попытка считать случайным явлением схожесть между событиями, образами, деталями эпоса и реальной действительностью себя не оправдывает. Придерживаясь подобного научного взгляда, в статье автор реконструирует исторический образ Чуры Нарыкова, политического деятеля, жившего в середине XVI в. в Казанском ханстве, выявляет связи между историко-героическим эпос-дастаном и реальными событиями Казанского ханства в 1-ой половине XVI в., проводит параллели между исторической действительностью и эпосом «Чура-батыр», выявляет общее между реальностью и эпическими произведениями. Рассмотрение исторической личности Чуры Нарыкова как прототип не только татарского, но и в целом тюркского историко-героического эпоса раскрывает историческую значимость татарской и других тюркских версий дастанов о Чура-батыре, способствует усилению внимания к народному герою.

**Ключевые слова:** эпические произведения о Чура-батыре, политический деятель и дипломат Чура Нарыков, период Казанского ханства, борьба за власть, Казанский хан, бек, оппозиция, военный переворот.

The article is devoted to the problems of historical explanation of the rich epic material on folk art. In the scientific literature there is an opinion that the prototype of the main character of the dastans about Chur batyr is the public and political figure of the Kazan Khanate Chura Narykov. An attempt to consider the similarity between events, images, details of the epos and reality as a random phenomenon does not justify itself. Adhering to such a scientific view in the article the author reconstructs the historical image of Chura Narykov, a political figure who lived in the middle of the 16th century in the Kazan Khanate, reveals the links between the historical and heroic epos and the real events of the Kazan Khanate in the first half of the 16th century, draws parallels between historical reality and the epos «Chura-batyr», reveals the commonality between reality and epic works. Consideration of the historical personality of Chura Narykov as a prototype not only of the Tatar but also of the Turkic historical and heroic epos as a whole reveals the historical significance of the Tatar and other Turkic versions of the dastans about Chura-batyr, contributes to increased attention to the folk hero.

**Keywords:** epic works about Chura-batyr, politician and diplomat Chura Narykov, period of the Kazan Khanate, struggle for power, Kazan Khan, bek, opposition, military coup.

Халыкның эпик мирасы аның тарихыннан, әдәби-мәдәни бәйләнешләреннән аерылгысыз. Халык иҗатының героик эпос яисә тарихи дастан дип аталган жанры реаль вакыйгалар җирлегендә барлыкка килә һәм тарихи шәхес образын гәүдәләндерә. Эпос-дастаннар чынбарлык вакыйгаларының күчермәсе түгел. Әмма әлеге жанрның фәнни, иҗтимагый, тәрбияви һәм мәдәни әһәмияте чиксез.

Тамыры белән уртак нигезгә барып тоташучы төрки халыклар, бигрәк тә татар, башкорт, казакъ, нугай, үзбәк, азәрбайҗан, төрекмән, кыргыз һ.б.лар иҗатында шактый гына охшашлык күзгә ташлана, биредә берсенә генә нисбәтләп булмый торган, бер үк вакытта берничә төрки халыкның әдәби-мәдәни мирасын тәшкил итүче ядкярләр бар. Чура батыр исеме белән бәйле дастаннар да – әнә шундый әсәрләрдән. «Чура батыр» исеме белән мәгълүм эпик истәлекләр XVI йөз уртасы татар ханлыкларына, аерым алганда, Казан ханлыгы тарихына турыдан-туры барып тоташалар һәм бу дәвернең бай хәзинәсен тәшкил итәләр.

Татар халык иҗатында Чура образы берничә эпик жанрда гәүдәләнгән. Чура батырга багышланган дастан, риваять, бәет, кобайырларның һәркайсы тарихта билгеле вакыйганы – Казан алынуны бәян итә. Ә Казанның рус дәүләте тарафыннан 1552 елда яулангын булуы билгеле, шуңа күрә бу әсәрләрнең барлыкка килү вакыты XVI йөз уртасыннан да иртәрәк була алмаган. Башка төрки халыклар эпосы белән аваздаш күләмле дастан һәм аның вариантлары [Баязит, 1915, б. 282–286; Юлдаш: 1916, б. 85–86; Кыйссаи Чура батыр, 1884], тарихи бәет [Казан тарихы, 1880; Казанская история, 1889, с. 5–22] һәм риваятьләр [Карауҗа, 1987, б. 51–53] – һәммәсе бу образны халык каһарманы буларак тасвирлау белән характерланалар. Иң беренче чиратта башка төрки халыклар эпосы белән аваздаш күләмле дастан игътибарны җәлеп итә.

Татарча дастан тексты беренче мәртәбә 1862 елда ук И.Н. Березинның «Турецкая хрестоматия»сендә «Нарык Чураның хикәяте будыр» исеме белән басылган [Нарык Чураның хикәяте будыр, 1862, б. 39–59]. 1984 елда исә «Татар халык иҗаты. Дастаннар» китабына фольклорчы галимә Ф. Әхмәтова тарафыннан шушы хрестоматиядән кыскартып алып кертелгән [Татар халык иҗаты. Дастаннар, 1984, б. 108–119]. Фольклор галиме Ф.И. Урманчеев дастанның И.Н. Березин хрестоматиясендә төрекмән диалекты үрнәге итеп бирелүен түбәндәгечә шәрехли: «Лингвистикада «төрекмән диалекты» дигән тел яисә диалект мәгълүм түгел. Бәлки биредә сүз Иделнең түбән агымындагы ярым-татар, ярым-нугай, ярым-төрекмән диалектында сөйләшүче трухменнар турында барадыр? Әсәрнең телендә, чыннан да, казакъ һәм нугай телләре йогынтысы сизелә» [Урманчеев, 1995. № 9, б. 100].

Әмма дастан татар телендә язылган. Әсәр үзенең идея-сюжеты ягыннан казан татарларының XVI йөзнең икенче яртысыннан соңгы мохитен үтә якыннан тасвирлавы белән аерылып тора. Шул ук вакытта теленең татар теленең урта диалектына хас билгеләре дә бу

әсәрне казан татарларына нисбәт итә. Моннан тыш, татар халкында сакланып калган бәет, риваятьләр, Чура батырга багышланган башка төрки версияләренә караганда, нәкъ менә шушы дастан рухына тәңгәл килә, шул ук әсәр вакыйгаларының урыны-вакыты белән чагыша, шулай ук казан татарыннан язып алынган сөйләмә вариантта да, шигъри формалы «автор»лы китаби вариантында да (Кыям Юлдаш варианты) шушы версиянең тәэсире зур. Татарларда телдән яки язма рәвештә яшәгән-таралган әлеге әсәрләрнең иң тулысы, иң зур күләмдәгесе – И.Н. Березин хрестоматиясендә басылып чыккан дастан тексты, шуңа күрә ул башка ваграк текстлар өчен беренчел чыганак ролен башкара. Әлеге сюжетка нәкъ менә кайсы текстның иң беренче барлыкка килгәнлеге үтә фәлсәфи һәм бәхәсле булып тоелса да, текстларда күзәтелгән эчтәлек-фикер җәһәтеннән чыгып караганда, югарыдагы фикер раслана. Текстларның тарихта теркәлү хронологиясе дә шушы ук фикерне куәтли. Димәк, И.Н. Березин варианты әлеге батыр хакында татар халкында мәгълүм барлык текстларны үз тирәсенә җыйнау функциясен үти. Икенче төрле әйткәндә, бу әсәр – татарларда таралыш алган «Чура батыр» сюжетының язма формада ныгыган, берләштерә торган үзәге. И.Н. Березин җыентыгындагы оригинальлектә дастан башка бер генә милли версиядә дә кабатланмый. Болар бар да башка төрки халыкларның Чура батырга багышланган дастаннары янәшәсендә И.Н. Березин хрестоматиясендә басылган «Чура батыр хикәяте»нең нәкъ менә татар җирлегендә иҗат ителгәнлеге файдасына сөйли һәм әсәрнең казан татарларына мөнәсәбәте шикле булмауны дәлилли.

Дастани Чура образы Казан ханлыгында яшәгән сәясәтче, дипломат Чура би шәхесе белән шактый охшаш. Дастандагы башка образлар һәм вакыйгалар да күп яклап XVI йөздәге реаль шәхесләргә һәм хәлләргә якыная. «Казанны алырга кат-кат килүче рус яуларына каршы батырларча көрәшеп йөргән һәм дастан каһарманына прототип Чура исемле реаль шәхес булгандырмы, юкмы – бу сорауга сакланып калган тарихи чыганаклар буенча кистереп кенә уңай җавап бирүе авыр», – дип яза күренекле галим Марсель Хәернас улы Бакиров һәм өстенлекне Чураның җыелма образ булу ихтималына бирә [Бакиров, б. 11]. Алай да Чура Нарык углының тарихи һәм дастани образы арасындагы, шул ук вакытта, дастан вакыйгаларының татар тарихының билгеле бер чорын яктыртуы җәһәтеннән килеп туган охшашлыклар очраклы гына булган дип карау үзен аклый алмый. Бу хакта тарихчы галим Д. Исхаков [Исхаков, 1994, б. 17–19; Исхаков, 2022, б. 110–153], Х. Паксой [Паксой, 1994, с. 9], филолог галим Ф. Урманчеев [Урманчеев, 1995, № 5, 7–8, 9, 10–11], Л. Ибраһимова (Л. Мөхәммәтҗанова) [Ибраһимова, 2002, б. 7–27; Мухаметзянова, 2022, с. 212–228], дастандагы персонажларның һәм вакыйгаларның реаль тарихка мөнәсәбәтен ачыклап, фәндә үз фикерләрен белдерделәр.

Әлбәттә, чорга кагылышлы архив документларының сакланмавы XVI йөзнең беренче яртысында Казан ханлыгында Чура Нарык углы

шәхесенең яшәп, сәяси һәм дипломатик эшчәнлек алып барганлыгын рәсми дәлилләүдә кыенлык тудыра. Әмма әлеге затның эшчәнлеге турында Казан ханлыгы тарихын яктырткан хезмәтләрдә шактый гына мәгълүмат бар. Моннан тыш борынгы татар шәҗәрәләрен барлаучы М.И. Әхмәтҗанов тарафыннан табылган шәҗәрә [Әхмәтҗанов, 2002, б. 323–324] үзе генә дә Чура батыр прототибын татардан эзләүнең хаклылыгын дәлилли. Галим «Чура батыр шәҗәрәсе» дип атаган бу документта Чура – Күкәс һәм Нарык буыннарыннан соң килүче зат. Шәҗәрәдә Чураның Нарык углы дип күрсәтелүе аның тарихи шәхескә тәгаенләнүе өчен җитәрлек нигез булса, дастандагы:

Мән Чурамын, Чурамын,
Түрә түгел, карамын,
Асылымны сорасаң –
Күкес углы Тамамән, –

дигән юллар һәм әсәрдә Чураның атасы Нарык турында җентекле тасвир исә дастан вакыйгалары белән татар шәҗәрәсенең тамырларын уртак итә. Хәлбуки дастани Чура батырны Казан ханлыгында яшәгән тарихи шәхес Чура Нарыковка бәйләүне хаксыз гамәл дип танып булмый, моны инкяр итә торган дәлилләр юк. Димәк, нигезендә Казан ханлыгы чорының татар халкына нисбәтле тарихи вакыйгалары яткан татар эпосына күзәтү ясау халык батырына игътибарны үстерә, тарихи һәм дастани Чура язмышын чагыштыру планында карау мөмкинлеген бирә.

Чура батыр турында әлеге дастан – татар халкының җитди эпик әсәре, шул ук вакытта татар халкының китаби дастаннары традициясенең гаҗәеп үрнәге. Билгеле булганча, Казан ханлыгы оешкан чорыннан алып бөтен яшәү дәвере буена Мәскәү Бөек кенәзлеге белән көч сынаша һәм, ниһаять, XVI йөз уртасында үзеннән көчлерәк дәүләт тарафыннан рәсми төстә яулана. Казан татарларына турыдан-туры кагылышлы бу вакыйгага реакция халык иҗатының эпик жанрларында, иң беренче чиратта, дастаннарда яңгыраган. Героик китаби дастаннардан «Чура батыр» халыкта милли фаҗига итеп кабул ителгән вакыйгаларның кайтавазы буларак кыйммәт. Безнең халыкның милли азатлык көрәше белән аваздаш әлеге дастан тарихи-традицион яктан да, әдәби формасы ягыннан да, стиле-таралышы белән дә гаять кызыклы. Бер үк халык фольклорында бер үк сюжетның, теманың һәм образның төрле жанр әсәрләрендә һәм төрле формаларда очравы фольклорда әллә ни еш күзәтелми. Чура батыр образы һәм аның белән бәйле вакыйгалар чагылыш тапкан эпик сюжетларның татар халкының үзендә генә дә берничә булуы шулай ук игътибарны җәлеп итә. «Чура батыр» дастанындагы эпик мотивларның, идея-сюжет һәм стиль үзенчәлекләренең гомумтөрки эпос масштабында, шиксез, үз урыны бар.

Тарихи шәхес буларак Чура Нарык углының яшәү һәм эшчәнлек дәвере чама белән XVI гасыр башы – XVI гасыр урталарына, ә тагын

да төгәлрәк итеп әйткәндә, 1500–1546 елларга туры килә. Чыганаклар күрсәткәнчә, XVI йөзнең 20 нче елларында ул Казанда хөкүмәт әгъзаларының берсе булган, шушы чордан башлап, үзенең сәяси эшчәнлегенә керешкән. Казан ханлыгында Сафагәрәй (1524–1532), Җангали (1532–1533), янә Сафагәрәй (1533–1546), Шаһгали (1546 елда 1 ай хакимлек итә) ханнар идарә иткән дәвердә Чура Нарыков – ил тормышында, дәүләт эшендә актив катнашучыларның берсе. Бу еллар Казан ханлыгы өчен гаять катлаулы һәм каршылыклы булган. Тәхетне әле Кырым, әле Мәскәү утырткан ханнар биләгән. Сафагәрәй – Кырымдагы Гәрәйләр нәселеннән, Җангали белән Шаһгали – Мәскәү тарафыннан утыртылган Касыйм ханы Шәехәүлиярның рус тәрбиясе алган уллары. Мондый шартлар Казан ханлыгында ныклы, бердәм эчке һәм тышкы сәясәт булдыруга тискәре йогынты ясаган. Мөстәкыйльлекне саклап калуның хәлиткеч вакытында читтән китерелгән ханнарның ханлык өчен ни дә булса эшләргә омтылулары яисә эшли алулары бик шикле. Шуңа күрә дәүләтнең хан идарәсе алып барган эшчәнлеге ханлыктагы сәяси һәм иҗтимагый төркем вәкилләренең ризасызлыгына сәбәп булган. Шундый ризасызлык Сафагәрәй ханга карата тугач, оппозициянең, ярдәм сорап, Мәскәүгә мөрәҗәгать иткәләгәнлеге мәгълүм. Мәсәлән, 1541 елның маенда Мәскәүгә Чабык исемле кеше җитәкчелегендә вәкилләр җибәрелә. Алар кенәзгә түбәндәге сүзләрне җиткерә: «Ныне казанским людям вельми тяжко, [Сафагирей] у многих князей ясаки поотымал да крымцам подавал, а земским людям великая продажа, копит казну да в Крым отсылает» [Худяков, 1990, с. 101]. Бу сүзләрдә азмы-күпме хаклык булуны танырга кирәк, әмма, икенче яктан караганда, әлегедәй фактлар дәүләтнең бөтенлеген саклап калу өчен иң җаваплы чорда татарларның үзләре арасында һәм бигрәк тә ил җитәкчелегендә бердәмлекнең булмавы хакында сөйли.

Җангали белән Шаһгали ханнарга да әллә ни өмет баглап булмаган. Берсе 15, икенчесе 13 яшендә тәхеткә утыртылган бу ханнар акыллы сәясәт алып баруга сәләтсез булганнар. Алай гына да түгел, теләсә-теләмәсәләр дә, сәясәттә Мәскәүгә йөз тотып, рус дәүләте файдасына эшләгәннәр.

Кырым өчен дә, Мәскәү өчен дә Казан ханлыгының элеккеге данын кире кайтару, мөстәкыйль сәясәтен саклау мөһим булмаган. Табигый, алар һәркайсы үз ихтыяҗларыннан чыгып, үз мәнфәгатьләрен кайгыртып эш иткәннәр. Мондый шартларда Казан ханлыгы белән бәйсез идарә итәргә тырышуның тәхет биләүче теләсә кем өчен җиңел булмавын да танымый мөмкин түгел. Әлбәттә, ханлыкның хәлен тагын да катлауландыручы җитди сәбәп – XVI йөзнең 40 нчы елларыннан Көнчыгышны басып алу өчен тыелгысыз һөҗүмнәр башлауга кучкән Россиянең агрессив сәясәте. Алтын Урда дәвамчысы, заманында чәчәк атып яшәгән Казан ханлыгының соңгы чоры кинәт күтәрелеп киткән Мәскәүнең колониаль сәясәтеннән котылу өчен көрәштән гыйбарәт булганлыгы сер түгел.

Менә шундый тарихи чорда сәяси һәм иҗтимагый көчләрне тәшкил иткән, ханлыкның үз кешеләре булган би, морзалар нинди эшчәнлек алып барганнар соң? Кызганыч, әмма кайбер күренекле дәүләт эшлеклеләре дә – Булат һәм Нурали Ширинnәр, Гәүһәршад, Сәед Боерган, Чура Нарыков, Кучак, Кадыш морза, Тагай морза һ.б. – хан идарәсе һәм хөкүмәтнең бердәмлеген булдырып, халыкны бер максатка туплый алмаганнар. Үзенең туган җире – Идел буенда үсеп тәрбия алган, хан дәрәҗәсенә күтәрелгән шәхесләр XVI йөзнең беренче яртысында гына түгел, Казан ханлыгында гомумән булмаган. Алтын Урда дәүләтендә яшәп килгән тәртип нигезендә, Казан ханлыгында да, башка татар ханлыкларындагы кебек үк, җучилы булмаган кеше хан тәхетенә утыра алмаган. Ә инде XV гасыр азагында һәм XVI гасырнаң I чирегендә ханлык Мәскәүгә бәйлелеккә төшкәч, ханнарны сайлап кую хокукы казанлылар кулыннан бөтенләй диярлек киткән.

Тарихи чыганакларда Чура Нарыков исеме нәкъ шушы тынгысыз елларда телгә алына башлый. «1526 елның март аенда Сафагәрәй ханнан Мәскәүгә Казый һәм Чура бәкләр, Давыл бахшы илче булып килделәр. Болар бу юлы Карл V тарафыннан җибәрелмеш Герберштейн белән Мәскәүдә очраштылар», – дип хәбәр итә күренекле тарихчы Һади Атласи [Атласи, 1993, б. 298]. Димәк, 1526 елда Чура дәүләт эшләрендә катнашырлык яшьтә булган. Аның әле 1546 елгача хөкүмәт составында торуы мәгълүм. Чама белән 40 яшьләрендә һәлак булган дип исәпләсәк тә, Мәскәүгә җибәрелгән Чура бәкнең без эзләгән Нарык углы Чура булуы бик ихтимал. 20 нче елларда ук, ягъни бик яшьли аның «бәк» дәрәҗәсен алуына килсәк, монда ике төрле караш булырга мөмкин. Беренчедән, татар халкында «бәк» сүзе ирләр исеменнән соң әйтелгәндә, «әфәнде» мәгънәсен дә аңлаткан. Икенче яктан караганда, бәк титуллы дипломат Чура Нарык углының дөньяга без уйлаганнан иртәрәк килеп, эшчәнлеген алдарак башлаган булуы да мөмкин. Әмма бу турыда чыганаклар берни дә сөйләми.

Аңлатмалы сүзлектә «чура» сүзенә түбәндәге билгеләмә бирелгән (бер мәгънәсе): чура – Алтын Урда чорындагы ханнарның политик вассалы, аерым гаскәр башлыгы [Татар теленен аңлатмалы сүзлеге, 1981, б. 447]. Чура Нарыковка карата бәк титулы тарихи әдәбиятта алга таба да кулланыла. Димәк, шуны әйтә алабыз: Чура XVI йөзнең беренче яртысында яшәгән Казан аксөяге булган. Казан ханлыгында бәк (би, әмир) дип эре җир биләмәләре булган аерым кешеләрне атап йөрткәннәр [Фәхретдинов, 1996, б. 190]. Эре феодаллар, нигездә, аксөяк нәселдән килгәннәр. Ханлыкның иҗтимагый төзелеше закончалыгыннан чыгып фикер йөрткәндә, Чура бәкнең дә атасыннан мирас булып күчкән эре җир биләмәсе булган, ә коралланган үз гаскәре хан фәрманы карамагында торган. «Казан тарихы»ның билгесез авторы искәрткәнчә, чыннан да, Чураның «500 йомышлы (хәрби хезмәт үтәүче. – *Л.М.*) коралланган колы, 1000 сугышчы-яугире, үзенә ияргән кенәзләре» [Казанская история, 1954, с. 82] булган.

Чура бәк тора-бара илнең эчке һәм тышкы сәясәтендә, аерым алганда, үз дәүләтенең Кырым ханлыгы һәм Мәскәү белән мөнәсәбәтләрен урнаштырганда әһәмиятле урын били башлый. Аның сәясәт мәйданына килгән дәвере ханлыкның үз эчендә сәяси көчләрнең ике төркемгә – «көнчыгыш» һәм «рус» партияләренә бүленгән елларга туры килә. Шартлы рәвештә көнчыгыш төркем дип Кырым ханлыгына йөз тоткан партия аталса, тышкы сәясәттә Россия белән союзны хуплаган партияне рус яисә көнбатыш төркеме диләр.

Чура Нарыков Мәскәү яклы морзалар тарафында җитди роль уйнаган шәхес буларак мәгълүм. Россия белән союз тарафдарлары Казан хөкүмәте составында 1531 елдан 1546 елга кадәр 15 ел дәвамында даими эшчәнлек алып баралар [Худяков, 1990, с. 112]. Казан ханлыгының үз эчендә барган иң киеренке көннәре дә нәкъ менә 1530–1546 елларга туры килә. Моны ханнарның еш алыштырылуы, ике төркем арасында барган ызгыш-талаш, рус дәүләте белән әледәнәле булып торган бәрелешләр раслый.

Татар телендә «чура»ның «кол» дигән мәгънәсе дә билгеле [Татар теленен аңлатмалы сүзлеге, 1981, б. 447]. Бу исә тарихи сәхифәләрдә телгә алынган дипломат Колчура исеменә тукталырга нигез бирә. Бу кеше 1531 елда, Сафагәрәй хан беренче мәртәбә тәхеттән куылгач, хан итеп кемне кую мәсьәләсе белән Мәскәүгә җибәрелгән була. «Временное правительство постановило не принимать на престол Шах-Али, кандидатуру которого навязывала Москва, но который был несимпатичен казанцам по своим личным качествам. Заявив отвод против русского кандидата, временное правительство все же осталось в сфере русской ориентации, и в ханы было избрано лицо, проживавшее в России – Касимовский удельный царевич Джан-Али, брат Шах-Али. Для переговоров с русским правительством в Москву были отправлены послы Кул-Чура и Форузат», – дип яза М. Худяков [Худяков, 1990, с. 95]. Колчура хакында мәгълүмат Һ. Атласида да бар. Тарихчы-галим күрсәтүенчә, Колчура белән Фәйрузат исемле әлеге кешеләр «Хөршидә бикә, Хаҗи Гали мирза, Булат бәк, Казанның угланнары, бәкләре, сәедләре, морзалары, шулай ук бөтен Казан йорты исеменнән ярлык белән килгәннәр иде» [Атласи, 1993, б. 298]. 1526 еллардан бирле хөкүмәт әгъзасы булса да, әлеге сәяси адымга бәйле рәвештә Чура бәк Нарыков исеме конкрет телгә алынмаган. Шуңа күрә, Колчура белән Чура икесе бер шәхес түгелме дигән фараз кала. Әмма шунысы бар: Нарык углы Чура турында сөйләгәндә тарихчы-авторлар һәрвакыт диярлек «бәк» титулын кулланалар, «эшлекле», «кыю», «талантлы», «мәшһүр» эпитетларын аның исеме белән янәшә китереп, Чураның Казан ханлыгында күренекле зат булуын күрсәтәләр. Ә Колчурага бәйле мондый үзенчәлекләр юк. Шулай ук әлеге исемнең 1549 елда да, ягъни Чура бәк үтерелгәннән соң да тарихи әдәбиятта очравы [Атласи, 1993, б. 148] әлеге фикердән кире кайтара.

«1534 елның 11 февралендә Василий Беречинскийның Казаннан Мәскәүгә кайтуы» хакында сөйләгәндә Һ. Атласи Чура исемле кеше-

не телгә ала. Әмма «Бу кеше (Василий Беречинский. – *Л.М.*) Василий үлгәнлекне, улы Иванның олуг кенәз булганлыгын Җангали ханга белдерер өчен Казанга барган иде. Василий белән бергә Чура исемле кеше Мәскәүгә килде. Бу кеше Казанның муллазадәләреннән булып, аны Җангали хан Мәскәүгә илче итеп җибәргән иде» [Атласи, 1993, б. 305], – дигән юлларны укыгач, әлеге Чураның да Нарыковка катнашы юклыгын гына әйтергә кала, чөнки, беренчедән, Һ. Атласи телгә алган кеше – муллазадә, икенчедән, тарихчы хезмәтендә ул әлегәчә таныш булмаган шәхес буларак тәкъдим ителгән. Ә Чура Нарыков тарихи әдәбиятта 1526 елдан бирле мәгълүм булып, тарихчы Һ. Атласи да аны гомумбилгеле сәяси эшлекле дип исәпли.

Без эзләгән Чура Нарыков исеме исә алга таба хөкүмәттә мәшһүр шәхесләрнең берсе булып калкып чыга, дәүләт эшләрендә әһәмиятле урын били. Тарихи чыганаклар һәм әдәбият шуны раслый.

1526–1531 елларны Чура бәк тормышында сәяси ныгу чоры, чагыштырмача тыныч эшчәнлек дәвере дип билгели алабыз. Бу елларда ул күренекле җәмәгать эшлеклесе, сәясәтче, дипломат булып танылырга өлгерә. Бу урында янә бер мәсьәләне ачыклап үтәргә кирәк. Казан ханлыгында Чуралар берәү генә булмаган. Тарихи әдәбиятта бу исем еш очрый. Мәсәлән, бу чорда Колчура һәм муллазадә Чура, Чура Кадышев, Бикчура, Чура Кадыев, Шаһчура, Качура исемле илчеләр, сәясәтчеләр һ.б. яшәгән. Гомумән, XVI йөзнең I яртысында Чура дигән исем популяр булган. Бүгенге Татарстан территориясе топонимикасында Чура исеме белән бәйле урыннарның күп булуы бәлки шуның белән аңлатыладыр. Әйтик, Татарстанның Нурлат районына кергән Чурабатыр авылы [Хәйри, 1996, с. 50], Чура би чокыры дип аталган урын (аның турында татар халык риваятендә әйтеп кителгән [Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар, 1987, б. 368.]), Яшел Үзән районында урнашкан Карагуҗа авылы тирәсеннән ага торган Чураби елгасы [Гарипова, 1994, б. 120.] һ.б. Әлеге атамаларның Чура Нарык углы белән дә бәйләнеше булырга бик мөмкин.

Чура бәк язмышы белән кызыксынуыбызны дәвам итеп, кабат тарихи әдәбиятка әйләнеп кайтсак, 1546 елда аның янә активлашып китүенә игътибар итәбез. Әмма бу чорга җиткәнче, зур булмаган тарихи чигенеш ясау шарт.

1521–1550 елларны М. Худяков Казан ханлыгында халыкның үзаңы үсеп, патриотлык хисләре көчәйгән дәвер дип билгели. Шул ук вакытта берсе Кырым, икенчесе Россиягә йөз тоткан төркемнәрнең, оешып, актив эшчәнлек итү һәм үзара көрәш алып барулары да нәкъ шушы елларга туры килә. Казан ханлыгына мөнәсәбәттә, Кырым һәм рус дәүләтләренең үз мәнфәгатьләреннән чыгып фикер йөртүләре аңлашыла. Шушы тарткалау-йолыккалау ханлыкның тыныч үсешенә, үзара бердәмлекнең булмавына зур йогынты ясаган да. Бер генә мисал: 1519 елның 1 мартында Казан тәхетенә рус хөкүмәте тарафыннан Шаһгали утыртыла. Аңа бу вакытта 13 кенә яшь була. Илне ныгыту өчен ул берни эшли алмаган, чөнки андый максат куелмаган

да. Ә бу вакытта Казанда русларның хәрби отрядлары тора, дәүләт белән асылда рус илчеләре идарә итә. Мондый шартлар булдыксыз ханга каршы оппозиция оешуны тизләтә, ә ул оппозиция исә Кырым хөкүмәте тарафыннан яклау таба. Күп тә үтми, дәүләт түнтәрелеше: 1521 елда тәхеткә кырымлы Сәхибгәрәй менә.

Шул рәвешчә, Казан ханлыгы тәхете, әле Кырым, әле Мәскәү кулына эләгә. Әйтергә кирәк, ханнарның еш алыштырылуы гадәти хәлгә әверелә, Казан аксөякләре өчен дә ханлыкның мондый язмышы табигый күренешкә әйләнә. Җәмгыятьнең ике лагерьга бүленүе көчәя бара: берәүләр коткаруны Кырымнан өмет итсә, икенчеләре исә Мәскәүгә сыенуны хуп күрә. Дәүләтнең сәяси һәм җәмәгать эшлеклеләре аңында Казанның бәйсезлеген бөтенләй үк югалтып бетермәү теләге яшәсә дә, Казан ханлыгы өчен хәлиткеч вазгыятьтә милли үзаңның тәэсире көчләрне бер максатка туплый алмый. Ханлыкны күрше дәүләткә буйсындыру өчен әкренләп алшартлар әзерләнә. 1530 елда русларның Казанга яу белән килүе уңышсыз тәмамлангач, рус хөкүмәте Казан илчеләрен Мәскәү белән союзның ханлык өчен отышлы булуына инандыру эшенә керешә. Мәскәү хөкүмәте файдасына булганда, Казандагы рус партиясе, әлбәттә, аннан яклау тапкан. Әмма шул ук вакытта Казанда 15 ел буе даими эшләп килгән әлеге партиянең дилбегәне мөмкин кадәр үз кулында тотарга тырышуын да инкяр итә алмыйбыз.

1521 елдан 1531 елгача Казан тәхетен кырымлы Гәрәйләр династиясе биләве мәгълүм (1521–1524 – Сәхибгәрәй, 1524–1531 – Сафагәрәй). Аларга каршы оешкан сәяси төркемнең башында күренекле эшлекле Булат Ширин торган. 1531 елда Сафагәрәй хан тәхеттән төшерелгәч, оппозиция аеруча активлашкан, үз сафларына 70–80 нән дә ким булмаган атаклы морзаларны, бәкләрне туплаган [Худяков, 1990, с. 112]. Партиянең иң сәяси вәкилләре дип Нурали Ширин, Гәүһәршад, Сәед Боерган, Кадыш, Отуч морзалар, Баубәк, Чура бәк (Чура Нарыков), Борнаш, Колыш морзалар һ.б. күрсәтергә булыр иде. Нәкъ менә шушы төркемгә мөнәсәбәттә 1531–1546 еллар Чура бәк тормышында яңа дәверне тәшкил итә. Шуңа күрә аның сәяси биографиясен әлеге төркем эшчәнлегенә нисбәтле күзәтү таләп ителә.

Билгеле булганча, 1531 елда Казан ханлыгы тәхетеннән Сафагәрәй куыла, хан идарәсе Җангали кулына тапшырыла. Переворотның мәгълүм партия басымы белән башкарылуы аңлашыла. Рус ориентациясендә торуларына карамастан, переворотны оештыручыларны, шул исәптән Чура бәкне дә, рус хөкүмәтенә иман саткан җаннар дип бәяләү объектив булмас иде. М. Худяков мәсьәләгә болай якын килә: «...переворотом 1531 года русская партия была обязана не искреннему желанию поставить Казанское ханство в зависимость от иностранцев, а стремлению спасти государство от дальнейшей войны и от продолжения агрессивной политики ханов Гиреев» [Худяков, 1990, с. 98]. 1531 елгы түнтәрелеш рус партиясенең Казан ханлыгын чит ил баскынчыларына бәйлелеккә төшерү түгел, ә бәлки дәүләт

иминлеген саклау, Гәрәй ханнарның агрессив сәясәтеннән коткарырга омтылуыннан килә, һәр уңайлы вазгыятьтә бу төркем вәкилләренең мөстәкыйльлекне саклап калуга юнәлдерелгән адымнар ясавы тарихчының югарыдагы фикере белән килешергә тулы хокук бирә. «В этот период Казанского ханства можно наблюдать следующую картину: при появлении первой же возможности освободиться от давления чужого государства, казанское правительство сразу принялось вставать на свои собственные ноги и вести самостоятельную политику, не считаясь с русским правительством». Мәсәлән, 1533 ел азагында Казан хөкүмәтенә мөстәкыйль сәясәткә борылыр өчен уңайлы шартлар туа. Мондый вазгыять Василий III үлеп, Мәскәү-Казан мөнәсәбәтләрендә шактый үзгәрешләр килеп чыгу белән бәйле. Илдә рус илчелегенең абруе төшә, көнчыгыш партиясенең йогынтысы үсә, нугайлар белән сәүдә активлаша. Гәүһәршад, Булат Шириннәр җитәкчелегендәге хөкүмәт үзгәрешләрдән файдаланып калырга омтыла. Казан сәясәтендәге кискен борылыш сарай түнтәрелеше белән тәмамлана. Серле генә шартларда Җангали хан үтерелә. Ханлык итү өчен яңадан Сафагәрәй чакырыла. Бу урында шуны әйтеп китү мөһим: переворottан риза булмаган Мәскәү яклы түрәләрнең кайберләре Россиягә кача, ватанны калдырып китүчеләр арасында Шәгъбән һәм Шаһ Булат Япанчылар, Карамыш һәм Яулыш (Евлуш) Хурсулилар һ.б.ның исемен атарга мөмкин [Худяков, 1990, с. 99]. Күпчелек исә, кискен чорда илгә тугрылык саклап, бирөдә кала һәм эшчәнлеген дәвам итә. Казан бәге Чура Нарыков та шулар сафында була.

Әмма тәхеткә Сафагәрәйнең килүе ханлыкны мөстәкыйльлеккә илтми. Казан янә кайнауда: кырымлы хан үз тирәсенә якыннарын туплый башлый, уртак максатлар билгеләнми. Хөкүмәт составындагы рус партиясе вәкилләре Кырым басымын Мәскәү йогынтысыннан берни белән дә аерылмый дип исәплиләр, чөнки 1531 елда Булат морза һәм Чура Нарыковлар тарафыннан тәхеттән куылган Сафагәрәй дәүләт эшләрендә күбрәк аларга түгел, ә үзенә тугрылыклы кырымлыларга таяна. Шулай итеп, ил өчен янә киеренке көннәр башлана. Ханга каршы Булат Ширин, Чура Нарыков һ.б.ны берләштергән оппозиция көчәя, ул янә Мәскәү тарафын ала һәм Россия хөкүмәте белән Сафагәрәйне төшерү турында яшерен сөйләшүләр алып бара башлый. Әйтик, 1541 елның маенда Мәскәүгә җибәрелгән вәкилләр Казандагы хәлләрне рус кенәзенә барып сөйлиләр [Худяков, 1990, с. 101]. Әледән-әле Мәскәү кенәзенә мөрәҗәгать итеп, аның Казандагы хәлләргә ачыклык кертүенә өметләнү ул елларда Казан бәк-морзаларының гадәтенә әйләнгән була, күрәсең.

1545 елның башында Казанда Сафагәрәйне икенче кат тәхеттән төшерү максатында переворот әзерләнә. Рус гаскәрләре дә Казанга өч юнәлештән хәрәкәт итә башлый. Әмма, гамәлдә фетнә әле өлгереп җитмәгән булганга, переворот барып чыкмый. Әлбәттә, бу вакыйга әлегә тәхеттә калган Сафагәрәйне чыгырыннан чыгара: репрессияләр башлана, хан җәзасыннан курыккан кайбер казанлылар Мәскәүгә

качу ягын карыйлар. Ханга оппозиция башында торган Булат морзага, Гәүһәршадка көн бетә. Алар инде сәясәттә кала алмыйлар, хөкүмәттән читләштереләләр. Сүз уңаеннан әйткәндә, М. Худяков әлеге шәхесләр җитәкчелегендәге партия эшчәнлегенә шактый югары бәя бирә, аны тиешенчә өйрәнү өчен чыганакларның җитәрлек булмавын искәртә.

Әмма оппозициягә карата Сафагәрәй кулланган чаралар тиешле нәтиҗәне бирми. Булат Ширин, Гәүһәршадлар урынын күп еллардан бирле алар белән янәшә эшләп ныгыган «сеид Беюрган, князь Кадыш (брат князя Отуча) и талантливый деятель Чура Нарыков» [Худяков, 1990, с. 102] ала. Шулай итеп, 1545 елгы вакыйгалар Чура бәкне сәясәт үренә китерәләр. Казанда милли үзаң үсеп, мөстәкыйльлекне сакларга омтылыш көчәйгән, әмма кискен конфликтлы бер чорда Чура Нарыков көрәш мәйданына чыга. Дипломатлык өлкәсендә шактый уңышларга ирешкән партиянең тәҗрибәсен үзләштергән Чура бәк оппозиция хәрәкәтен җитәкли башлый.

1545 елның июлендә Чура Нарыков фиркасе, хәрби ярдәм сорап, Мәскәүгә мөрәҗәгать итә. «1545 елның июлендә, – дип яза Һ. Атласи, – Казан бәкләреннән Кадыш белән Чура Иванга кеше җибәреп, аңардан Казан өстенә яу җибәрүен үтенделәр, Сафагәрәй ханны, шулай ук аның якыннарыннан булган утыз Кырым бәген тотып урысларга бирергә булдылар. Иван өчен моннан да куанычлы нәрсә булырга мөмкин түгел иде. Ул, Кадыш белән Чурага илче җибәреп, ханны тотарга боерды. Үзе тиздән гаскәр җибәрәчәк икәнлеген белдерде» [Атласи, 1993. б. 318]. 1545 елда рус хөкүмәтенең Казанга һөҗүме уңышсыз тәмамланганга күрәме, ярдәм сорап мөрәҗәгать итүгә Мәскәү сак килә: ул казанлыларга бик үк ышанып бетми. Ханга оппозициянең мөрәҗәгатенә каршы рус дәүләте гаскәрне Сафагәрәй тәхеттән төшерелгәч кенә бирәчәге турында белдерә. Шул рәвешчә, Чура Нарыковлар фиркасе сәясәттә бары үз көчләренә генә ышанырга тиеш булып кала. Илдәге хәлне җайга салу урынына, хан кулланган җәзалау чараларының җирле түрәләр, аерым алганда, Сәед Боерган, Чура бәкләр өчен рус хакимиятеннән дә яманрак булып күренүе гаҗәп түгел. 1545 елгы репрессияләр ханлыктагы болай да катлаулы хәлне тагын да кискенләштереп җибәргән.

Ниһаять, күптән әзерләнгән переворот 1546 елның гыйнварында тормышка ашырыла – Сафагәрәй тәхеттән төшерелә. Казанда Сәед Боерган, Кадыш морза, Нарык углы Чуралар составында вакытлы хөкүмәт оеша. Рус ориентациясендә булса да, бу хөкүмәтне аңлы рәвештә Мәскәү файдасына эшләгән дип бәяләү хаксызлык булыр иде. Түбәндәге тарихи фактлар шуны раслый.

1546 елгы переворот нәтиҗәсендә тәхеттән куылган Сафагәрәйнең шул ук елда кире Казанга юнәлүе мәгълүм. Әстерхан хөкүмәтеннән хәрби ярдәм алып, тәхетне кире кайтару максаты белән, ул шәһәрне камап ала. Һ. Атласи язганча, Сафагәрәй «Казанның яхшы кешеләре аны ханлыкка телиләр, дип уйлыйдыр иде. Шул өмет илә торса да, Казанның бәкләре илә олугларыннан һичбер кеше аның янына килмәде» [Атласи, 1993, б. 145]. Ягъни, рус партиясе генә түгел, көнчыгыш

тарафдарлары да кырымлы ханны кире кага, бу очракта ул Казанда беркемнән дә яклау таба алмаган. Моны ничек аңларга? Әлбәттә, Казан ханлыгының һәрвакыт мөстәкыйль сәясәт алып барырга омтылуы дип. Тәхетнең бушап калган чагы, чит ил баскынчылыгыннан арынып, ниһаять, бәйсезлеккә ирешү өчен кулай вакыт булган. 1535 елда (кайбер чыганаклар буенча, 1533 елда) касыймлы Җангали хан үтерелгәч тә ханлыкта нәкъ шундый омтылыш булган иде.

Шул рәвешчә, вакытлы хөкүмәт Сафагәрәй хан һөҗүмен кире кайтара. Килешүләрне яңартырга һәм хан тәхетенә кандидат мәсьәләсендә сөйләшүләр алып барырга дип, Казанга Мәскәү илчелеге килә. Ханлыкта фикерләр төрле булса да, рус йогынтысы көчле булу тәхеткә кабат Шаһгалине кайтара.

Мондый вазгыятьтә игътибарны Казан хөкүмәтен җитәкләгән Сәед Боерган, Кадыш морза, Чура бәкләр эшчәнлегендәге кайбер фактларга юнәлтик. 1546 елның мартында хан тәхетенә сайланган Шаһгали Казанга 4 меңлек гаскәр ияртеп килә. Аның 3 меңе касыймлылар, 1 меңе рус хәрби көчләре була. Рус хөкүмәте утырткан ханга казанлылар бик үк ышанып бетмиләр, аның идарәсен тулысынча контрольгә алырга омтылалар. Шаһгалинең шәһәргә бары 100 генә Касыйм татары белән кертелүен шулай аңларга кирәк. Ә аның белән килгән рус гаскәре каладан бөтенләй читтә тукталып калырга мәҗбүр ителә. Бу урында тарихчы М. Худяков фикере белән килешергә мөмкин: «Очевидно, правительство сеида Беюргана, князя Кадыша и Чуры Нарыкова, представлявшее русскую партию, не утратило своего национального самосознания и, держа русских в известных границах, смотрело на союз с Москвою лишь как на неизбежную необходимость, но не питало какой-либо сердечной привязанности к соседнему государству» [Худяков, 1990, с. 110]. Ул гына да түгел, бу төркемнең эшчәнлегенә бәя бирергә алынып, Булат Ширин, Гәүһәршад, Сәед Боерган, Кадыш морза, Чура бәкләр әйдәгән партиянең 15 ел дәвамында чит ил басымына каршы көрәшүен танырга кала. Казан ханлыгы өчен гаять катлаулы елларда алар күп тапкыр конфликтлы хәлләрдән чыгу җаен табалар, дипломатик осталык нәтиҗәсендә, эшчәнлекне Казанның төрле ханнары белән берлектә алып баралар. Шушы төркемнең күренекле вәкиле Чура Нарыков та – гомере буе ханлык мәнфәгате өчен көрәшкән сәләтле шәхес. Илдәге хәлләрдән һәрвакыт хәбәрдар Чура бәк халык белән еш аралашкан [Фәхретдин, 1995, б. 120], аның ышанычын яулаган оста сәясәтче булган.

Кабат тарихи эзлеклелеккә кайтсак, Чура Нарыковның фаҗигасына да ерак калмаган була бу вакытта. Икенче кат тәхеткә чакырылган Шаһгали бары бер ай гына «идарә итеп» кала. Аның Казанда абруе бөтенләй булмый. «Мәшһүр түрәләрдән Чура морза Шаһгалине никадәр мәдех итеп, ягъни мактап, «аңа ихласлы һәм итагатьле булырга тиешле», дип Казан халкына нәсыйхәтләр әйтеп йөрсә дә, сүзе тәэсир итмәде», – дип яза Р. Фәхретдин [Фәхретдин, 1995, б. 120]. Бер айдан Шаһгали хан тәхетен ташлап качкач, аның урынына бер

каршылыксыз гына яңадан Сафагәрәй килеп урнаша. Казанда кулга алулар башлана. Кырымлы хан оппозицион төркем вәкилләрен җәзалый. Барыннан да элек Чура бәк һәм аңа якын түрәләр кулга алына. Тарихи әдәбиятта әлегә кадәр Чура Нарыковның 1546 елда Сафагәрәй тарафыннан үтерелүе турында мәгълүмат таралган. Чура Нарык улының фаҗигалы үлеменә нисбәтән түбәндәге өч версияне китерергә мөмкин. Беренчедән, 1547 елда ул Сафагәрәй тарафыннан җәзага тартыла; икенче версия буенча, Ул Шаһгали хан хыянәте нәтиҗәсендә казанлыларның бер төркеме белән бәрелештә һәлак була; өченче чишелеш мондый булырга мөмкин: Чура батыр 1552 елда Явыз Иван белән сугыша, ә бәлки хәтта рус гаскәре Казанны алгач та, илбасарлар белән канлы көрәштә һәлак була.

Беренче версияне алсак, Сафагәрәй ханның Чураны җәзалап үтерүе аңлашыла. Ул күп еллар ханга оппозициядә торган төркемнән булган Чура бәкне үзенә каршы эшчәнлек алып баруда гаепли. М. Худяков та шул турыда хәбәр итә: «Казнены были князь Чура Нарыков, князь Кадыш, князь Баубек и другие сторонники союза с Россией» [Худяков, 1990, с. 111]. Шушы ук мәгълүматны Р. Фәхретдин дә җиткерә: «Чура морза кебек монафикъ, ягъни икейөзле түрәләрне үтертте»[ Фәхретдин, 1995, б. 105]. Бу турыда Һ.Атласи түбәндәгеләрне яза: «Чура Нарыков, Бау бәк, Кадыш бәкләрне, шулай ук болардан башка тагын ничәләп кешеләрне Сафагәрәй хан үтертте» [Атласи, 1993, б. 331]. Безнең карашыбызча да, Чура бәк 1547 елда, ә бәлки 1546 елда ук җәзага тарттырылган булырга тиеш, чөнки, Сафагәрәйнең тәхеткә килүе апрель-май айларында булган, ә инде 6–7 ай эчендә ул үзенең дошманнары язмышын хәл итәргә өлгергән.

Башка бер чыганак – «Казан тарихы» – Чура Нарыков үлеменә кагылышлы өр-яңа мәгълүматлар бирә төсле. Бирелә Чураның Казан кешеләре белән бәрелештә һәлак булуы турында сөйләнә. Ул Шаһгали ханны Казаннан Мәскәүгә качыруны оештыра, ә үзе исә 10 көннән хатыннарын, балаларын, 500 коралланган кол-хезмәтчесен, 1000 кешелек гаскәрен алып, Казанны ташлап китәргә уйлый. Сөйләшенгән урында аны Шаһгали көтеп торырга тиеш булса да, элекке хан, ни сәбәпледер, вәгъдәсен үтәми, Чура бәккә хыянәт итә. Чураны казанлылар куып җитәләр, «...и убили они храброго своего воеводу Чуру Нарыковича с сыном его и со всеми отроками его как изменника Казани и царского доброхота. И только жена его с рабынями живой возвратилась в Казан» [Казанская история, 1954, с. 80]. Мәскәүгә качу өчен Чура Нарыковның Шаһгалигә ярдәм итүен Р. Фәхретдин дә искәрткән иде: «Сафагәрәй ханны яңадан ханлык итәргә чакырдылар. Бу хәлләрдән хәбәрдар булган Чура морза, Шаһгали хозурына кереп, форсат кичмәстән мөкаддәм, ягъни җай бетмәстән элек ничек булса да качарга кирәк, юкса эшләрнең харап булачагын аңлатты» [Фәхретдин, 1995, б. 120].

Безнең карашыбызча, Чура Нарыков үлеменең беренче һәм икенче версияләрен үзара якынайтып, тулырак мәгълүмат табарга мөмкин. М. Худяков һәм «Казан тарихы» хәбәр итүенчә, «Шах-Али бежал

из Казани вниз по Волге на судах; на Волге ему удалось встретить касимовских татар и на их лошадях добраться до русской границы, он поселился в Касимове» [Худяков, 1990, с. 111], «Когда же царь и воевода его были готовы к побегу и настала ночь того дня, ... проводил Чура царя из Казани до Волги, выпустив его и уговорив бежать. ... Ибо разгневался князь Чура на казанцев из-за царя Шигалея за то, что обманули они царя, не послушавшись его совета, и, клятвенно пообещав ему безопасность, захотели убить его...». [Казанская история, 1954, с. 78]. Яисә Р.Фәхретдин язганча: «Шаһгали гаед кичендә (Соловьевның әйтүе буенча, бу вакыйга 1546 елда була) Казаннан качып чыкты вә, көймәгә утырып, Волга белән Мәскәү шәһәренә китте». [Фәхретдин, 1995, б. 122].

Һәр очракта ханны Чура озаткан булуы мөмкин, гәрчә кайбер чыганакларда әлеге фактка аерым игътибар бирелмәсә дә. Шулай итеп, безгә Чураның Сафагәрәй тарафыннан җәзага тарттырылуы һәм Шаһгалине Мәскәүгә озатканнан соң күпмедер вакыт узгач, ханның җәзалавыннан котылу максатында Мәскәүгә качып барганда тотылып, казанлылар тарафыннан үтерелүе турындагы хәбәрләр билгеле, һәр ике версияне мөмкин дип санаган хәлдә, бу ике карашны бер ноктага туплый алабыз. Бу исә хәлне түбәндәгечә күзаллау мөмкинлеген бирә. Сафагәрәй хан янә тәхеткә кайткач, үз тирәсенә көнчыгыш партия вәкилләрен, кырымлыларны туплый. Чура Нарыковлар төркеменнән исә ул рәхимсез үч алырга ниятли. Моны сизеп, Чура Шаһгалине качарга өнди. Казанда хәлләрнең гаять кискенләшкән чорында Чура бәк үзе өчен дә Сафагәрәй күзеннән югалып торуның мәслихәт булуын аңлый, әмма шәһәрдән китеп өлгерә алмый кала. Хан күрсәтмәсе буенча, Чура Нарыков качып барган җиреннән куып җитеп кулга алына һәм Сафагәрәй тарафдарлары аны җәзалап үтерә. Батырның хатыннары, хатын-кыз коллары гына исән калып, алар кире Казанга кайтарыла. Мондый нәтиҗә ясау чыганаклар арасында бернинди каршылык та тудырмый.

Шулай итеп, Чура бәкнең тормыш юлына 1546 елның көзендә нокта куела. Эзләнүләрне шушында туктатырга да мөмкин булыр иде. Әмма югардагы күзәтүләрдән чыгып билгеләнгән өченче версиянең дә урынлы булырга мөмкинлеге Чура бәк биографиясендә яңа табышмаклар китереп чыгара.

Тарихчы А.Х. Халиков Нарыковлар фамилиясенә мөнәсәбәттә түбәндәге мәгълүматларны китерә: «Известная княжеская фамилия в Казани около середины XVI века (ПСРЛ, 29, с. 28). В 1546 году Чура Нарыков и его брат встречали Шах Али в Васильсурске (ПСРЛ, 34, с. 27). В 1546–1552 гг. Нарыковы играли видную роль в Казани. В 1551 году Чура Нарыков был «побит» за непослушание Ивану IV, а его брат Алексей мурза Нарыков в 1552 году перешёл на службу к Ивану Грозному (ПСРЛ, 29, с. 12, 47–49, 146, 170). От него, очевидно, пошли Нарыковы» [Халиков, 1992, б. 135]. Мәгълүматларның рус елъязмаларыннан алынуы искәртелгән. Ягъни, Чура бәк 1546 елда

Сафагәрәй хан һәм казанлылар әзәрлекләвеннән качып котыла алган булып чыга. Алай гына да түгел, шушы ук елда ул инде Васильсурскида булып, Казаннан качып килүче Шаһгалине каршы ала. 1546–1552 елларда Нарыковларның «Казан тормышында күренекле роль уйнаулары» ихтимал. Әмма бу һич тә Чурага кагылмый, сүз аның Ислам һәм Галикәй исемле туганнары хакында бара булса кирәк. Алар тарихи әдәбиятта еш искә алыналар. Ислам да, Галикәй дә (кайбер чыганакларда – Аликәй) – Чура Нарыков фиркасе тарафдарлары. Чура бәкне 1551 елда Иван IV җәзага тарта, димәк, әлеге чыганак буенча, 1546 елда ул әле исән була. Әмма без бу текстка зур саклык белән карарга тиешбез. Чөнки биредә китерелгән күп кенә хәбәрләр каршылыклы фикерләр уята, фактлар ачыкланмаган. Яңадан башка чыганакларга мөрәҗәгать итеп, тарихи вакыйгаларны логик эзлеклелектә карау мәсьәләгә төгәллек кертер кебек. М. Худяков, Сафагәрәй ханның икенче кат тәхеткә килүенә бәйле рәвештә, түбәндәгеләрне яза: «...новое царствование открылось террором. Казнены были князь Чура Нарыков, князь Кадыш, князь Баубек и другие сторонники союза с Россией. В сентябре в Москву прибыла партия эмигрантов — князья Кулыш, Терегул, Бурнаш, братья Нарыковы и другие в числе 76 человек. Новое правительство составилось из крымских татар» [Худяков, 1990, б. 112 ]. Һ. Атласи да Чура бәкнең җәзалап үтерелүе хакында хәбәр итә: «Чура белән Кадыш Сафагәрәй ханны Казаннан каулау юлында зур урын тотучылардан иде. Болар белән бергә Боерган Сәед тә бар иде исә дә, ул Казаннан нугай йортына качып котылды» [Атласи, 1993, б. 331]. Тарихчы Чура бәкнең үтерелүе турында яза, ә Казаннан Мәскәүгә качып килүчеләр арасында түбәндәге исемнәрне атап китә: Колыш бәк, Тере-Угыл (Тәңре Кол), Борнаш, Чура Нарыковның туганнары [Атласи, 1993, б. 331]. Рус елъязмаларына таянып, галим С.Х. Алишев Чура Нарыков һәм аның туганнары хакында шундый ук мәгълүмат бирә [Алишев, 1995, б. 84].

Димәк, 1546 елда Чура Нарыковның исән калуы турында факт берничек тә расланмый. Ә менә шул ук елда Казаннан Мәскәүгә күчкән эмигрантлар арасында аның туганнары Ислам һәм Галикәй морзалар булган.

Тарихчы Д.М. Исхаков Чура Нарыков туганнарының 1549 елда Нугай Урдасында искә алынуы турында яза: «...алар Ислам морза һәм Аликәй морза (ул чапкын була) исемле булганнар. Нугай Урдасына караган эшләрдән күренгәнчә, алар нугайлар янына Сафагәрәйдән качканнар. Бу ике шәхес 1552 елгы вакыйгаларда да катнашалар» [Исхаков, 1994. № 9, б. 17]. Ягъни, 1546 елда Ислам белән Галикәй Нарыковлар Казаннан Мәскәүгә күчеп киткәннәр, әмма анда озак тормыйча, 1549 елда нугай ягына барганнар яисә тегендә дә, монда да йөргәннәр. Хәлбуки 1552 елда аларның кабат Казан ханлыгында булулары билгеле. Сафагәрәй вафатыннан соң, 1546 елда читкә китүчеләрнең кире әйләнеп кайтулары ихтимал.

1552 елның март аенда, казанлыларның таләбе буенча, Шаһгали Казаннан китә һәм Зөя каласына барып урнаша. Инде Казанга рус воеводалары керергә тиеш була. «Когда наместник приехал на Бежбалду (деревня, расположенная на месте Адмиралтейской слободы), – дип яза М. Худяков, – трое из сопровождавших его казанцев – кн. Ислам, кн. Кебек и мурза Алике Нарыков (брат покойного Чуры Нарыкова) попросили у него разрешение ехать вперед. Разрешение было дано, и они уехали в город» [Худяков, 1990, б. 142]. Казанга кергәч, болар шәһәр капкаларын ябып куялар, халыкны русларга каршы торырга өндиләр. Нәтиҗәдә, Казан ханлыгын Мәскәүгә тыныч юл белән иректе кушу барып чыкмый кала. Ислам морза 1552 елның 9 мартында ясалган дәүләт түнтәрелешеннән соң Тау ягыннан русларны куу сугышында һәлак була. Ә Галикәй исә Ядкяр хан чорында Казанда хөкүмәт составына керә. 1552 елдан соң тарихи чыганакларда Нарыковлар фамилиясе башкача телгә алынмый. Хәер, А.Х. Халиков күрсәтүенчә, Галикәй морза Нарыков 1552 елда Иван IV гә хезмәткә күчкән, исемен исә Алексей дип үзгәрткәннәр [Халиков, 1992, б. 135].

Чура Нарык углының тәрҗемәи хәле 1546 елда төгәлләнә дидек, әмма бу очракта 1551 елда да исән-сау булып, Иван IV тарафыннан эзәрлекләнгән, ягъни русларга каршы көрәшеп йөргән Чура кем була? Аның Чура Нарыковка бәйләнеше бар кебек тоелса да, бу шәхеснең югарыда биографиясе тикшерелгән Чура бәк булуы бик шикле. Биредә сүз икенче бер Чура турында бара булса кирәк, әйтик, Нарык углының улы хакында. Тарихта Чуралар бик күп булган, кайсының кем булуын конкрет ачыклау өчен чыганаклар бик аз, шуңа күрә чыганак буларак фольклорга да мөрәҗәгать итми мөмкин түгел. Сүз бара торган фактка, мәсәлән, татар халык риваятьләрендә ишарә юк түгел: «Чура бинең улы Чура батыр булган. Иван Грозный гаскәрләре Казанны алган вакытта Чура батыр шушы Карауҗа җирләре өчен сугышып үлгән» [Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар, 1987, б. 150]. «Казан тарихы»нда да Чура бәкнең хатыннары, балалары турында искәртелә [Казанская история, 1889, с. 77–79]. Боларга нигезләнсәк, Чура Нарык углының нәселе калган дип уйларга җирлек юк түгел. Татар халкының ярым легендар шәҗәрәләре дә моны раслый. Борынгы кульъязмалар, аеруча татар шәҗәрәләре белгече М.И. Әхмәтҗанов тарафыннан бастырылган шундый чыганакларның берсенә тукталыйк [Әхмәтҗанов, 1995, б. 34].

Казанда Каравай тирәсендә Кара би исемле кешенең Карауҗа дигән улы, Казаннан күченеп килеп, Карауҗа авылын кора. Тәһарәт алырга су бирмәгәннәре өчен, бер мосафир авылны каргый. Карауҗа, бик хәвефләнеп, өч улына өч ук бирә һәм әйтә: «Укларыгыз кая төшсә, шунда авыл корып утырырсыз», – ди. Бу урында иң әһәмиятлесе – Кара-Куҗаның өченче улы Чураби турындагы мәгълүмат. Чыганакта әйтелгәнчә, аның угы хәзерге Зур Карауҗа авылы уртасындагы Чураби чокырына төшә. Карауҗа улы Чураби белән шушында нигез кора. Чурабине Мәскәү патшасы, хыянәте өчен, җәзалап үтерә. Аның улы

Чура батыр, Явыз Иван гаскәрләре белән сугышып, Зур Карауҗада һәлак була. Чура батырның улы Ресмәт, Ресмәтнең улы Кадермәт, аның улы Гыйззәтулла исемле була. Алга таба янә 7 буынга кадәр исемнәр китерелә. Искәрмәдә китапның авторы Карауҗа нәселе шәҗәрәсенең Казан ханлыгы тарихы белән тыгыз бәйләнгән булуын әйтә.

Шунысын да искәртик: алдарак телгә алынган «Карауҗа» риваятендә сөйләнгән вакыйгалар әлеге шәҗәрәнең бер өлеше булып тора. Риваятьнең тагын бер версиясе галимә Ф.Г. Гарипова бастырып чыгарган китапта урын алган [Гарипова, 1994, б. 119].

Димәк, тарихта ике Чура хәрәкәт иткән булырга мөмкин. Берсе – атаклы Казан бәге Чура Нарыков, икенчесе – аның улы Чура батыр. Чура бәк мәгълүм сәбәпләр аркасында Сафагәрәй тарафыннан 1546 елда җәзага тарттырылган булса, Чура батырның бераз соңрак, Казан ханлыгын яклап сугышканда, батырларча һәлак булуы бик мөмкин.

Д.М. Исхаков Чурага кагылышлы, фәндә инде билгеле булган берничә шәҗәрә китерә. Беренчесе – Башкортстанда табылган, икенчесе – югарыда карап үтелгән «Карауҗа» шәҗәрәсе, өченчесе – Кырымдагы Аргыннар шәҗәрәсе [Исхаков, 1994, б. 18]. Тарихчы I шәҗәрә белән II һәм III шәҗәрәләр арасында бәйлелек Чура би һәм Кара Гуҗа (Кара Коджа) аркылы бара, дип күрсәтә, Чура бәкнең нәсел җепләрен «Казан ханлыгындагы дүрт аксөяк карачы бәкләр нәселенең берсенә – Аргыннар нәселенә (кланына)» китереп бәйли. Д. Исхаков биргән мәгълүматлар арасында төрки халык дастаннарын тарихи чынбарлык белән бәйли торганнары да бар.

Башкортстанда табылган шәҗәрәдә, мәсәлән, Чураның атасы Нәрек, Нәрекнең атасы Күкәс дип күрсәтелгән. Татар, кырымтатар, казакъ, нугай дастаннарында «Күкәс» исеме Күкеш, Күкешле Тама формасында очрый, Чура батыр үзе турында: «Күкәс (Күкеш) утлы Тамамын», ди. Шунда ук автор Чура батыр турында тамьян-катай ыруыннан чыккан башкортлар арасында язып алынган хәбәрләрне китерә: «...Күрек исемле морза Җагылбай нәселеннән, казакъ булган... Нарык байның Таңсылу исемле хатынынан Сура исемле малае туган. Икенче малае – Ширин исемлесе, берничә елдан соң туган» [Исхаков, 1994, б. 19]. Биредәге Ширин исеме казакъ халкының Чура батырга багышланган дастаннарында да очрый. Ширин эпоста Чура батырның кыз кардәше буларак сурәтләнә. Д.М. Исхаков әлеге исемне барлык төрки дөньясында Алтын Урда чорларыннан билгеле һәм Казан, Кырым, Касыйм ханлыкларында хакимлек иткән бәкләрнең бер кланы – Шириннәр белән бәйләп карый.

Дастани Чура батыр татар версиясендә дошманнары белән каты көрәшә, дошман гаскәрен рәхимсез кыра. Ахырда ул дошман ягыннан китерелгән хатыннан туган үз улы белән сугыша, җиңүгә ирешә алмый, ярсыган атына атланган килеш Иделгә егылып төшеп, суга батып үлә. Менә шуннан соң дастан тәмам булырга тиеш кебек, әмма эпик вакыйгалар дәвам итә: «Соңра урыс гаскәре галиб булып ( җиңү-

че булып), Казан шәһрене алды. Урыс падишаһына табигъ булдылар (буйсындылар). Бу Казан шәһрен алгандан бер ел соңра Хаҗитархан (Әстерхан) шәһрен янә алды. Чура батыр хикәяте тәмам булды» [Нарык Чураның хикәяте будыр, 1862, б. 59]. Дастан ахырында китерелгән әлеге юллар Чура батырга багышланган татар эпосына өр-яңа биеклектән карарга мәҗбүр итә. Дастан батыр гамәлләрен сурәтләү белән генә чикләнми, ә Алтын Урда варислары булган Казан ханлыгы, Кырым ханлыгы, Әстерхан ханлыгы, Нугай ханлыгы вакыйгаларына турыдан-туры кагыла! Әсәрнең XVI йөз уртасы тарихи вакыйгаларының эпик картинасын тудыруы шуның белән раслана. Бу дастанны Алтын Урда чоры эпик истәлеге «Идегәй»нең дәвамы дип атарга да мөмкиндер. «Идегәй» Алтын Урда таркалу вакыйгаларын сурәтләсә, Чура батырга багышланган әлеге ядкяр Алтын Урда таркалып, татар ханлыклары барлыкка килеп, билгеле бер чорда аларның үз көчен югалтуы тасвирлана. Каһарман батырлыгын сурәтләгән халык әсәре тарихи хроника төсен ала: тарихи чынбарлыкка туры килү тәртибендә рус дәүләте тарафыннан әүвәл Казан ханлыгының, аның артыннан Әстерхан ханлыгының яулануы хакында хәбәр итә. Татар дәүләтләрендә үзара мөнәсәбәтләрнең какшаган мәле «Чура батыр» дастанында шактый төгәллек белән торгызылган дию дөреслеккә туры килә. Бу – эпик фольклорда халыкның тарихи хәтере сакланган булуга дәлил.

Тамырлары затлы төрки нәселгә барып тоташкан Чура бәкнең дастаннар каһарманына әверелү сәбәпләре борынгы уртак нигездән килә дип нәтиҗә ясарга тулы мөмкинлек бар. Татар, нугай, казакъ, кырымтатар, башкорт, кыргыз халык эпик иҗатында аның популярлыгы чын мәгънәсендә тарихи чынбарлык белән бәйләнгән. Реаль шәхес Чура Нарыковның язмышын Казан ханлыгына мөнәсәбәттә карау аның шактый катлаулы тормыш юлы үткәнлеген күрсәтә. 1526–1531 елларда ул сәясәттә, дипломатиядә актив катнашкан, әмма әлегә чагыштырмача тыныч эшчәнлек алып барган, сәяси эшлекле буларак ныгыган, формалашкан. Нарык углы Чура бәк тормышында икенче дәвер 1531–1546 елларны үз эченә ала. Казан ханлыгы хөкүмәтендә рус ориентацияле төркемнең хәрәкәт итү дәвере дә шушы вакытка туры килә. Татарларның үзләре арасында һәм ил җитәкчелегендә бердәмлек булмауга карамастан, бу елларда ханлыкта мөстәкыйльлекне сакларга омтылыш юк дип әйтә алмыйбыз. Рус партиясенә мөнәсәбәттә Чура Нарыков эшчәнлегенә күзәтү ясау аны халык арасында популярлык казанган сәяси җитәкче, оста дипломат буларак таныта. Чура бәк – Казан ханлыгының азатлыгы өчен көрәшкән шәхес дисәк, хата булмас. Кем хаклы булган да, кем хаксыз – бу сорауга җаваплар, әлбәттә, төрлечә булырга мөмкин. Әмма шунысын игътибардан читтә калдырырга ярамый: Чура Нарыков гомере буе көрәшеп яшәгән, ханга оппозициядә торган төркемнең абруен тоеп эш иткән, үзен шактый көчле сәяси һәм җәмәгать эшлеклесе итеп танытуга ирешкән, халык ышанычын яулый белгән. Чураның

эпик биография югарылыгына күтәрелүендә аның нәкъ менә шушы сыйфатлары әһәмиятле роль уйнаган булса кирәк. Әлбәттә, каһарман образының дастани үрнәгеннән тарихи Чура нык кына аерыла. Аның эшчәнлегенә объектив бәя биргәндә, сәясәттә кайбер ялгышлар җибәрүен дә күрми мөмкин түгел. Бүгенге көн югарылыгыннан караганда, көнбатыштан басып керүгә каршы уртак көрәштә Казан-Нугай, Казан-Кырым, Казан-Себер, ниһаять, Татар-Төрек берләшмәләре төзү отышлырак булыр иде. Ә Казан дипломатиясе, шул исәптән Чура Нарыков та бу максатта ифрат йомшаклык күрсәтә. Шул ук вакытта Чура бәк яшәгән дәвер Көнчыгышның берләшүенә комачаулау өчен Мәскәүнең актив төстә нәтиҗәле эш алып бару чорына туры килә. Күренекле дәүләт эшлеклеләре Булат һәм Нурали Ширин, Гәүһәршад, Сәед Боерган, Чура Нарыков, Кучак һ.б. сәяси һәм иҗтимагый көчләрнең бердәмлеген булдыра алмыйлар, хан идарәсе белән хөкүмәт бердәм эшләми, халыкны бер максатка туплый алмый. Бу һәм башка сәбәпләр ханлыкның һәлакәтенә китерә. Бер караганда, Чура батырның дастаннардагы чагылышы образлы рәвештә Чура бәкнең каршылыклы сәясәтен күрсәтә кебек. Дастани Чура да, җиңү максаты белән дошманнарына каршы көрәшә, әмма язмышын фаҗигале төгәлли. Эпик Чура – идеаллаштырылган образ, ә чынбарлыктагы Чура Нарыков – дәүләтнең бөтенлеген саклап калу өчен иң җаваплы чорда яшәп эшчәнлек алып барган кеше, илдә бердәмлек булмаган болгавыр дәвернең бер вәкиле генә.

Шулай итеп, тарихи чыганакларга нигезләнеп һәм фольклордагы кайбер мәгълүматларга таянып, төрки халыклар эпосында популяр образ Чура Нарыкның прототибы дип уйланылган Чура бәк Нарыков язмышына күзәтү ясадык, аның тәрҗемәи хәлен ачыкларга тырыштык. Гомерен хөкүмәт эшчәнлегенә багышлаган Чура бәк татар, кырымтатар, казакъ, нугай халык дастаннарына да ил азатлыгы өчен көрәшкән шәхес буларак килеп кергән. Халык хыялы аның эпик биографиясен 1552 елгы мәгълүм көрәшкә үк китереп җиткергән, алай гына да түгел, Казан ханлыгының һ.б. татар ханлыкларының яулап алынуын шушы көрәшкә китереп бәйләгән, ул вакыйгаларны да шушы дастан эчендә күрсәтеп китүне кирәк санаган. Кайбер төрки халыкларда, шул исәптән татарларда да киң таралып, төрле вариантларда сакланган күләмле эпос-дастаннар Чура Нарык углының эпик биографиясен тагын да тулыландыралар.

**Әдәбият**

*Алишев С.* Казань и Москва: межгосударственные отношения в XV–XVI вв. Казань: Татар. кн. изд-во, 1995. 158 с.

*Атласи Һ.* Себер тарихы. Сөенбикә. Казан ханлыгы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. 446 б.

*Әхмәтҗанов М. И.* Нугай урдасы: татар халкының тарихи мирасы. Казан: Мәгариф, 2002. 344 б.

*Әхмәтҗанов М.* Татар шәҗәрәләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1995. 128 б.

Бакиров М. «Чура батыр» дастаны // Мәдәни җомга. 2023. 23 июнь (№ 24). Б. 11.

*Баязит Р.* Яңа кала. Чура батыр // Ак юл. 1915. № 16. Б. 282–286.

*Гарипова Ф.* Авылларны сөям җаным-тәнем белән. Казан: Татар. кит. нәшр., 1994. Б. 122.

*Ибраһимова Л.Х.* Төрки халыклар иҗатында «Чура батыр» дастаны. Казан: Фикер, 2002. 190 б.

*Исхаков Д.* Чура батыр кем ул? // Идел. 1994. № 9. Б. 17–19.

*Исхаков Д.М.* Халкыбызның эпик әсәрләрендә милли тарих. («Түләк һәм Сусылу», «Ак Күбәк», «Идегәй», «Чура батыр» дастаннары һәм тарихи риваятьләргә анализ): монография. Казан ООО «Грумант», 2022. 160 с.

Казан тарихы // Насыйри К. Календарь 1881 елга. Казан, 1880.

Казанская история // *Катанов Ф.* Исторические песни Казанских татар. Казань, 1899. Б. 5–22.

Казанская история. (Ист. повесть 16-го в.). М. – Л.: Изд-во АН СССР, 1954. 195 с.

Карауҗа // Татар халык иҗаты. Риваять һәм легендалар / томны төзүче, кереш мәкалә һәм искәрмәләрне язучы С.М. Гыйләҗетдинов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. С. 51–53.

Кыйссаи Чура батыр. Казан: Вечеслав тип., 1884. 16 б.

*Мухаметзянова Л.Х.* Чура Нарыков – политический деятель Казанского ханства // Золотоордынское обозрение. 2022. Т. 10, № 1. С. 212 – 228.

Нарык Чураның хикәяте будыр // *Березин И.Н.* Турецкая хрестоматия. Казань, 1862. С. 39 – 59.

*Паксой Х.Б.* Чура батыр кисәтүе // Идел. 1994. № 9. Б. 9.

Татар теленен аңлатмалы сүзлеге. Т. III. Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. 832 б.

Татар халык иҗаты. Дастаннар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. 384 б.

Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар / томны төзүче, кереш мәкалә һәм искәрмәләрне язучы С.М. Гыйләҗетдинов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. 368 б.

*Урманчеев Ф.И.* Чура батыр // Мирас. 1995. № 9. Б. 97–137.

*Урманчеев Ф.И.* Чура батыр // Мирас. 1995. № 7–8, 9, 10–11. Б. 97–137.

*Фәхретдин Р.* Казан ханнары. Казан: Татар. кит. нәшр., 1995. Б. 120.

*Фәхретдинов Р.Г.* Татар халкы һәм Татарстан тарихы. Борынгы заман һәм урта гасырлар: Гомуми урта белем мәктәпләре, гимназияләр һәм лицейлар өчен дәреслек. Казан: Мәгариф, 1996. 255 б.

*Халиков А.Х.* Болгар – татар чыгышлы 500 рус фамилиясе. Казан, 1992. 192 б.

*Хәйри Ә.* Шәһре-Бану – Шәрбән кыйссасы. Яр Чаллы, 1996. 60 б.

*Худяков М.* Очерки по истории Казанского ханства / Репринтное воспроизведение издания 1923 г. Казань: Фонд ТЯК, 1990. 310 с.

*Юлдаш К.* Чура батыр // Аң. 1916. № 5. Б. 85–86.

***Мөхәммәтҗанова Лилия Хатип кызы,***
*филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге баш фәнни хезмәткәре*

УДК 398.8

***Г. Хөсәенова,***
***И. Шарапова***

# БАШКОРТ ЧИЧӘНЛЕК СӘНГАТЕ ҺӘМ БОРЫНГЫ КОБАЙЫРЛАР

В башкирском фольклоре, сохранившем богатое эпическое наследие, естественно, имело место сказительское искусство. Ряд башкирских исследователей в своих статьях рассматривали вопросы названного уникального явления, характерного культуре многих народов. Цель исследования: на основе существующей литературы попытаться дать представление о башкирском сказительстве и древнем эпосе народа. Задачи: дать краткую информацию о личности сэсэна, об известных творцах и исполнителях башкирского эпоса, об их исполнительском своеобразии, школе сказительства, а также о мифологическом эпосе башкир. Материалом исследования послужили имеющиеся в башкирской фольклористике труды предшественников, обращавшихся к теме башкирского эпоса и сказительского искусства. При написании статьи были использованы сравнительно-исторический, аналитический методы. Результаты исследования показали, что на основе имеющегося материала вырисовывается достаточно хорошее представление о башкирском древнем эпосе и сказительстве.

**Ключевые слова:** сказительство, сэсэны, башкирский, эпическое наследие, исполнительство, творцы, хранители.

There was a storytelling art in the Bashkir folklore which has preserved a rich epic heritage. A number of Bashkir researchers in their articles considered the issues of this unique phenomenon, characteristic of the culture of many peoples. Purpose of the study: to try to give an idea of the Bashkir storytelling and the ancient epic of the people based on the existing literature. Tasks: to give brief information about the personality of the sesen, about the famous creators and performers of the Bashkir epic, about their performing originality, the school of storytelling, as well as about the mythological epic of the Bashkirs. The material of the study was the works of other scholars available in Bashkir folklore who wrote about the Bashkir epic and storytelling art. When writing the article comparative-historical, analytical methods were used. The results of the study showed that on the basis of the available material a fairly good concept of the Bashkir ancient epic and storytelling emerges.

**Keywords:** storytelling, sesens, Bashkir, epic heritage, performance, creators, keepers.

Башкорт халык иҗатының алтын фондын тәшкил иткән героик поэмаларның, кобайырларның үсеше иң элек чичәнлек сәнгате белән бәйләнгән. Чичән халыкның иҗтимагый тормышында актив катнашкан, илгә яу килгәндә, халыкны дошманга каршы дәррәү күтәрә алган, ил эчендә килеп туган бәхәсле мәсьәләләрне хәл иткән билгеле шәхес булган. Тел осталарының халык арасында абруе югарылары гына чичән исеменә лаек булган. Борын үткәрелгән җыеннарның, мәҗлесләрнең түрендә дә халык мәнфәгатьләрен яклаган, гаделсезлеккә каршы көрәшкән чичәннәр утырган.

Чичәннәрнең халык күзаллавындагы сыйфатлары һәм бурычлары түбәндәге кобайыр юлларында ачык әйтелгән:

*Яманлыкты якламаҫ,*
*Дошман хәтерен һакламаҫ,*
*Якшыны һөйәр, каныкмаҫ,*
*Илдең зарын һөйләр ул,*
*Яуға сакырып өндәр ул.*

Башкорт эпос белгече Мөхтәр Сәгыйтов билгеләвенчә, язма комарткыларда чичәннәр турында мәгълүматлар аз сакланган, әмма халык хәтере эпоста, легендаларда, риваятьләрдә Сабрау, Ерәнсә, Кобагош, Карас, Байык кебек байтак легендар чичәннәрнең исемен саклаган [Сәғитов, б. 32–33]. Язма комарткыларда чичәнлек сәнгатенә ирләр генә түгел, хатын-кызлар да ия булуы турында мәгълүматлар булган. М. Буранголов язуынча, XVI гасыр урталарында бөрьян ыруында Гилмияза исемле данлыклы чичән яшәгән. Ул аеруча кобайыр әйтүе, оста җырчы булуы белән тирә-якка танылган. Аның хакында төрле легендалар сөйләгәннәр, җырлар җырлаганнар. Гилмияза үзенең тел осталыгы, гаделлеге белән хәтта ике ыру – бөрьян белән үсәргән – арасында җир өчен барган озакка сузылган сугышны туктаткан, җир бәхәсен хәл итә алган [Буранғолов, б. 134–135].

XVIII гасырда чыгышы белән хәзерге Әбҗәлил районыннан булган, байтак чичәннәр иҗатына йогынты ясаган оста чичән Ишмөхәмәт Мырзакаевның, аның укучысы, репертуарын үзләштерүче, «Урал батыр» эпосын башкаручы Габит Аргынбаев чичәннең исемнәре тарихта сакланган, шулай ук Хәмит Әлмөхәмәтов (Баймак районы), Сәбирйән Мөхәмәтколов, Хәйрулла Ишмурзиннарның (Бөрьян районы) бер үк вакытта чичән дә, курайчы ла булуы билгеле. Башкорт чичәннәре гадәттә хезмәтчән халык вәкиле, аның мәнфәгатьләрен яклаучы буларак чыгыш ясаганнар. Әмма араларында феодаль аристократиягә хезмәт итүче чичәннәр дә булган, халык аларны үз итмәгән. Мәсәлән, «Акморза чичән белән Кобагош чичәндең әйтеше»ндә бигә хезмәт иткән Акморза чичән тәнкыйтьләнә. Андый чичәннәрнең иҗаты үзләре исән чакта ук онытылуга дучар булган. Халык мәнфәгатен яклаган чичәннәрнең иҗаты да, исеме дә халык күңелендә сакланган һәм байтагы безнең көннәргә килеп җиткән. Чичәннәр җыеннарда, туйларда, сүз ярышлары – әйтешләрдә чыгыш ясаганнар, осталыкларын күрсәткәннәр.

Чичәннәр репертуары буыннан-буынга, чичәннән чичәнгә тапшырыла килгән. Чичәннәр бер-берсеннән иҗади осталыкка өйрәнгәннәр, эпик әсәрләрне отып алганнар һәм, күңелләрендә йөртеп, үзләренә хас поэтик бизәкләр белән баетып сөйли торган булганнар. «Урал батыр» эпосын, мәсәлән, М. Буранголов Гәбит чичән белән Хәмит чичәннең сөйләве буенча кәгазьгә теркәгән һәм шуның аркасында ул безгә язма хәлендә килеп җиткән.

1917 елгы революциядән соң да чичәнлек сәнгате үсешен дәвам иткән, тик ул яңа форма һәм эчтәлек алган. 1944 елда Башкорт АССР

Югары Советы Президиумы указы белән «Башкорт халык чичәне» дигән мактаулы исем булдырыла һәм аңа Мөхәмәтша Буранголов, Фәррәх Дәүләтшин, Сәйет Исмәгыйлев лаек була.

XX гасырда хатын-кызлар арасыннан Бәдернисә Әфләтүнова (Курган өлкәсе), Рәхилә Теләкәева, Хәтирә Селәүсинова (Ырымбур өлкәсе), Өммехәят Колдәүләтова (Бөрьян районы), Хәзисә Күсәбаева (Мияс каласы) һ.б. – эпик әсәрләрне оста башкарулары белән танылган чичәннәр.

Хәзерге заманда кобайыр жанрына шулай ук шагыйрьләр Рәми Гарипов, Кадим Аралбай, Мәүлит Ямалетдин һ.б. мөрәҗәгать иткән.

Югарыда әйтелгәннәрдән күренүенчә, чичәннең функцияләре вакыт үтү белән тарая бара. Борынгы заманнарда ул ата-бабалардан буыннан-буынга тапшырыла килгән халык иҗаты әсәрләрен, беренче чиратта, эпик комарткыларны, саклаучы һәм сөйләүче, халыкның тормышындагы мөһим вакыйгаларны чагылдырган кобайырлар иҗат итүче, шул ук вакытта дошманга каршы көрәшкә өндәүче дә, тарихны бәян итүче дә булса, тора-бара – кобайыр үлчәмендә көнүзәк проблемаларны чагылдырган шигъри формадагы әсәрләр иҗат итүче, халык иҗаты әсәрләрен оста башкаручы, хәзер исә ул поэтик формадагы әсәрләр язган иҗатчы һәм язма эпик комарткыны яттан сөйләүче буларак күз алдына баса.

Эпос – халык иҗатының борынгы формаларының берсе. Ул кешеләрнең табигатькә, тормышка карашларын, аларның үзара мөнәсәбәтләрен, илдә булган мөһим тарихи вакыйгаларны чагылдыра. Башкортларда эпос борынгы ыру корылышы таркала башлаган дәвердә үк барлыкка килгән һәм ул «милли сүз сәнгатенең чишмә башын тәшкил иткән» [Рәҗәпов, б. 5]. Тора-бара ул халыкның тарихын, рухи дөньясын поэтик формада сынландырган, кешелек дөньясы өчен әһәмиятле темаларны күтәргән һәм аларны героик планда сурәтләгән эпик жанр буларак үскән. Халыкның мифологиясенә нигезләнгән борынгы эпоска мифологизм белән фантастика хас булса, соңгырак дәвердә туган эпик комарткыларда реалистик сурәтләү элементлары өстенлек ала башлай.

Күренекле галим, беренче башкорт эпос белгече Кирәй Мәргән башкорт халык эпосының күптөрле һәм күп сюжетлы булуы белән башка халыкларныкыннан аерылып торуын («Джангар», «Калевала», нардлар – бер генә сюжетка корылган, бер генә эре вакыйга тирәсендә оешкан эпик әсәрләр) билгели һәм моны халык иҗаты үсешендә үтелгән тарихи шартлар белән аңлата [Кирәй Мәргән, б. 6].

Башкорт фольклористикасында эпик комарткының зур һәм кечкенә күләмле булуы, тезмә һәм чәчмә формаларның аралашып килүе тикшеренүчеләр арасында төрле караш тудырган, хәтта жанр атамасы да төрле-төрле булган һәм галимнәрнең моңа үз карашы, нигезләве бар. Әйтик, күренекле мәгърифәтче Мөхәмәтсәлим Өметбаевның 1876 елда язган «Башкортлар» дигән хезмәте буенча, башкортларның борынгы җыры үләң дип атала. Үләң – ул хикәят (сказание), ягъни

эпос. Үләң җырларында батырларның каһарманлыгы һәм ханнарның улларына үгет-нәсыйхәтләре җырланган. Бөтен башкорт батырлары үләңнәрдә җырлана: мәсәлән, Морадым, Заятүләк, Сура батыр һ.б. Ләкин... башкортлар төрле халыклар белән аралашкан вакыттан алып үләң җырлары дүртәр юллы лирик рифмаларга әверелде. Аларда мәхәббәт, кунакларга мактау һәм рәхмәт җырлана. Үләң яки башкорт эпосы чоры исә, башка европалыларныкы кебек үк, батырлар дәвере белән тәмамлана [Өмөтбаев, б. 189–192]. Казакъ фольклорында «шигырь», «халык шигыре» мәгънәсендә йөргән бу термин башкорт фольклор гыйлемендә «эпос» жанрының атамасы буларак ныгый алмаган. Башкортлар арасында эпос мәгънәсендә киң таралганы һәм кулланылганы «кобайыр» булган. «Кобайыр» ике сүздән тора: «коба» һәм «йыр». Башкорт телендә ул мактау, данлау җыры дигәнне аңлата. «Коба» сүзе күп кенә төрки халыклар телендә яхшы, әйбәт, мактау гына түгел, хайван, кош-корт төсе мәгънәсендә дә кулланылган. Шуңа күрә аның «изге җыр» мәгънәсен йөртүе дә ихтимал [Сәғитов, б. 16].

«Кобайыр» терминын бигрәк тә М. Буранголов, М. Сәгыйтов, С. Галин, Г. Хөсәенов, Б. Байымов хуплаганнар һәм хезмәтләрендә аны борынгы эпик комарткыларыбызга карата кулланганнар. Зур күләмле, халык тарихында булган мөһим вакыйгаларны чагылдырган, шигырь белән проза аралашып килгән «Урал батыр», «Акбузат» һ.б. эпик әсәрләрне Кирәй Мәргән исә иртәк дип атый, С. Галин, үз чиратында, тәүгеләрен кобайыр, ә тормыш-көнкүреш вакыйгаларын чагылдыруга зур урын биргән «Заятүләк белән Сусылу», «Алпамша белән Барсынсылу» һәм хайваннар циклына караган әсәрләрне иртәк, башкорт ыруларының халык булып оешу темасын күтәргәннәрен, ягъни «Кузыкүрпәч белән Маянсылу», «Алдар белән Зөһрә» «Җик Мәргән» һ.б. хикәят, язма чыганаклар аша килеп кергән мәхәббәт турындагыларын кыйсса дип атау ягында. Танылган фольклорчы галимә Ф. Нәзершина 2010 елда өч телдә чыккан һәм борынгы башкорт кобайырлары «Акбузат», «Заятүләк белән Сусылу», «Кара юрга» әсәрләрен эченә алган китабының керешендә аларга карата «кобайыр-иртәк» терминын куллана һәм моны түбәндәге сүзләр белән нигезли: «Саф эпос» төшенчәсенә туры килгән әсәрләр белән беррәттән, эпос һәм әкият сыйфатларын берләштергән катнаш формалы жанр төре – кобайыр-иртәк үсеш алган» [Нәҙершина, б. 17]. Әйтелгәннәрдән күренүенчә, эпос жанрының атамасына карата төрле фикерләр бар. Аларны ачыклау – киләчәк эше. Без исә, әлегә эпос белән кобайыр терминнарын синоним буларак кулланырга, башка халыклардагы кебек милли терминыбызны саклап калырга кирәк, дигән фикердәбез.

Кобайыр жанрының борынгылыгын М. Буранголов болай дип билгеләп китә: «Иң әүвәл тән хәрәкәтенә ияреп көй туа. Көйгә лирик характердагы сүзләр кушыла. Лирик җырларга соңрак эпик эчтәлек салына башлый. Шулай кобайыр барлыкка килә. Кобайырларга ияреп тарихи җырлар формалаша» һәм «Кобайырлар бик борынгы заманда-гы вакыйгаларны сөйли...» [Буранғолов, б. 26–27]. Безнең көннәргәчә

килеп җиткән иң борынгы кобайыр XIV гасырга карый дип раслый галимнәр [Башҡорт энциклопедияһы, б. 461].

Төрки халыкларның эпик әсәрләрендә дә, билгеле булганча, шигъри һәм чәчмә формалар аралашып килгән һәм шушы форма, әллә ни үзгәрмичә, әлегә тикле сакланган. Шундый ук күренеш башкорт халкының эпик мирасында ла күзәтелә. «Урал батыр», «Акбузат», «Заятүләк белән Сусылу», «Кара юрга», «Куңыр буга», «Аксак кола» кебек борынгы сюжетларда шигъри өлешләр проза белән алмашып һәм эпик формада иҗат ителеп, башкорт халык авыз-тел иҗатының гомуми традиция кагыйдәләре чигендә кабатланмас үзенчәлекле төс алалар.

Башкорт кобайырларында гадәттә халык тарихы белән бәйле мөһим вакыйгаларда каһарманлык күрсәткән батырлар турында сүз бара. Шигъри өлештә эпик батырның көрәше тасвирланса, чәчмә өлеш батыр хәрәкәтен эпик вакыйгалар чылбыры белән бәйләүче элемент буларак кабул ителә. Тагы шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: шигъри өлеш тыңлаучы тарафыннан һичсүзсез якшырак кабул ителә һәм ул өлешнең күләмле булуы чичәннең әзерлегенә һәм осталыгына бәйле. Тыңлаучыларның мактау сүзләре чичәннәргә репертуарын баету җәһәтеннән дә, башкару манерасы өстендә ныграк эшләүгә дә этәргеч булган. Эпик формалар һәрвакыт бар халыкларда да үскән һәм камилләшкән. Кирәй Мәргән билгеләвенчә, үсешенең югары ноктасында эпос тулысынча шигъри формада була: эпик форма яңа сыйфат ала – героик поэма формасы – кобайыр, һәм бу милли эпосның өлгерүен күрсәтә, импровизаторлык сәнгатенең югары ноктасын билгели [Киреев, с. 50]. Формасының төзеклеге һәм камиллеге белән *кобайырлар* бүген дә тыңлаучыны сокландыра. Кызганычка каршы, башкорт илендәге тарихи сәбәпләр аркасында кобайырны тарихи җыр алмаштыра [Киреев, с. 52]. Феодаллар һәм патша яраннарының кобайырлары белән кешеләрнең йөрәгенә куз (утлы күмер) салучы чичәннәрне эзәрлекләве һәм кысрыклавы кобайыр иҗат ителү процессының да, чичәннәр иҗатының да сүлпәнләнүенә китерә. Көрәш рухы белән сугарылган батырлар турындагы кобайырларга бу иң беренче чиратта кагыла. XVI гасыр азагына кобайыр үзенең элекке әһәмиятен югалта [Киреев, с. 53].

Кобайырлар борынгы җырау һәм чичәннәр тарафыннан чыгарылып, думбра чиртеп, шуның тавышына кушылып көйләп башкару аша сүз осталары тарафыннан отып алынып, буыннан-буынга тапшырыла килеп, халык хәтерендә сакланган. Борынгы башкорт шәҗәрәләре хәтердә саклансын өчен, оста җыраулар аны кобайырга салып әйтә торган булганнар, ә тиз отып алучы, үткер чичәннәр аны ятлап алганнар. Безнең көннәргә Мөйтән бигә багышланган үсәргән ыруының поэтик шәҗәрәсе генә килеп җиткән [Хөсәйенов, б. 233]. XVII–XVIII гасырлардан башлап, аларны кәгазьгә күчереп, кулъязма хәлендә саклаганнар.

Башкорт халкының «эпик чоры», М. Сәгыйтов билгеләп үткәнчә, ыру корылышы җимерелеп, сыйныфлы җәмгыятькә күчә башлаганнан капиталистик мөнәсәбәттәр урнашканга кадәрге дәвер аралыгына

туры килә. Әле безгә буыннан-буынга җыраулар, чичәннәр сөйләве аша килеп җиткән билгеле эпик сюжетлар да шул чорда иҗат ителгән. Тик, үкенечкә каршы, аларны җыю, туплау һәм өйрәнү эшләре бик соң башланган, һәм, нигездә, XX гасыр башына гына тура килә. Шуңа күрә эпик комарткыларның күбесе онытылган һәм югалган [Сәғитов, б. 6].

Бөек Ватан сугышы чорында фронтта да, тылда да язма әдәбият белән беррәттән халык иҗаты әсәрләре дә яңа сулыш ала, нык тарала, үзгәрә, заманга яраклаша. Солдаттар арасында бәет, такмак чыгаручылар күбәя, ә алар телдән телгә күчә, хатлар аша язма формада да тарала. Тылда ла шул хәл күзәтелә. Халык иҗаты әсәрләрендәге патриотик мотивлар яңа тарихи җирлектә тагы да көчәя. С. Галин әйткәнчә, «Ил азатлыгы өчен көрәшкән халык һәрчак үзенең үткән тарихына күз салучан. Мондый чакларда ата-бабаларның героик образы, алардан калган поэтик мирас ярдәмгә килә. Шуңа күрә халкыбызның героик тарихына бәйле китапларның нәкъ менә шушы чорда дөньяга чыгуы да – табигый күренеш» [Галин, 1972, б. 50–51]. Мәсәлән, 1942 елда М. Буранголовтың «Ватан сугышы: Кобайыр», 1943 елда Р. Рәимовның «1812 елгы Ватан сугышында башкорт халкы» исемле күләмле монографиясе, 1944 елда Б. Бикбайның «Ватан сугышы җырлары: җыентык» һ.б. китаплар дөнья күрә. Совет халкы немец-фашист илбасарларына каршы алып барган каты сугыш көннәрендә нәшер ителгән бу басмалар республика халкының патриотик һәм хәрби рухын күтәрүгә зур өлеш кертә. «Бу чорда, һичшиксез, героик һәм патриотик характердагы фольклор әсәрләренә өстенлек бирелә. Яугирләргә дә, халыкка да рух көчен күтәрү, җиңүгә ышанычны ныгыту өчен күтәренке рухтагы әсәрләр кирәк була» [Хөсәйенова, б. 71]. Шушы елларда халык иҗатында халкыбызның тарихына, сугышчан традицияләренә бәйле мотивлар, образлар язма әдәбиятка зур йогынты ясый. Бөек Ватан сугышы елларында героик эпос, кобайыр традицияләре җанлана. Б. Бикбай, Р. Нигъмәти, К. Даян, М. Кәрим кебек әдипләрнең әсәрләре кобайырларга хас мәһабәтлек һәм эпиклык, философик тирәнлек һәм кыскалык белән аерылып тора, шул ук вакытта гаҗәп заманча яңгырый. Бу чорда халык чичәннәре М. Буранголов, С. Исмәгыйлов, Ф. Дәүләтшинның иҗади активлыгы көчәя.

Кобайыр строфикасына һәм үлчәвенә нигезләнеп язучылар совет заманында ла байтак булдылар һәм бүген дә бар.

«Башкорт халык иҗаты» томнарын эшләгәндә «Эпос» китапларының өченчесе кобайырлардан төзелде. Шигыре 7 иҗектән торган, строфалар саны 4 тән 30 га кадәр һәм аннан да күбрәк юлы булган кобайырлар югарыда әйтелгән китапта өч төркемгә бүлеп бирелә:

1) реаль шәхесләр – туган җирен саклаучылар, ыру башлыклары һ.б. каһарманлыклары данланган батырлар турында («Сүкем батыр», «Түлгән батыр», «Көбәк батыр» һ.б.);

2) композицион нигезен мәкальләр, әйтемнәр, йомаклар тәшкил иткән фәлсәфи-дидактик кобайырлар («Бур баекмас», «Тугры сүз», «Әйт, дисәгез, әйтәем» һ.б.);

3) туган җирнең бөеклегенә һәм матурлыгына дан җырлаган, Ватанны саклауга әзерлек чагылган лирик кобайырлар («Ай, Уралым, Уралым», «Уралып яткан Уралда», «Идел-ер» һ.б.). Башкорт фольклор гыйлемендә аларны сюжетсыз кобайырлар дип йөртәләр.

Без исә сюжетлы кобайырларга игътибарны юнәлтик. Югарыда әйтелгәнчә, алар исәбенә «Урал батыр», «Акбузат», «Заятүләк белән Сусылу», «Кара юрга», «Куңыр буга», «Аксак кола» кобайырлары керә. Араларында иң борынгысы – халкыбызның горурлыгы, ата-бабаларыбыздан гасырдан гасырга, буыннан-буынга тапшырылган изге әманат, мәшһүр эпик комарткыбыз – «Урал батыр» кобайыры. Беренче мәртәбә ул 1968 елда гына «Агыйдел» журналында дөнья күрсә, 1972 елда «Башкорт халык иҗаты» сериясендә тиешле аңлатмалар, кереш мәкалә белән аның академик басмасы нәшер ителә. «Урал батыр»ның 1975 елда Мәскәүдә «СССР халыкларының героик эпосы» сериясенең беренче китабында рус телендә, 1977 елда шунда ук «СССР халыклары эпосы» сериясендә башкорт һәм рус телләрендә «Акбузат», «Заятүләк белән Сусылу», «Кара юрга», «Куңыр буга», «Аксак кола» әсәрләре белән бергә кабаттан дөнья күрүе кобайырыбызның бөтен дөнья мәдәнияте күләмендә танылу алуын күрсәтсә, баш мәкаләдә илнең танылган эпос белгече А.А. Петросянның әсәрнең бөеклегенә һәм борынгы шумер эпосы «Гельгамеш» белән сюжет охшашлыгына, уртак мотивларына басым ясавы, эпик комарткыбызның рухи кыйммәтен бик югары күтәрде.

«Урал батыр»ның сюжеты нигезендә борынгы эпос өчен характерлы дөнья яралу, тәүге кешеләр, аларның табигать белән мөнәсәбәте, табигатьнең үлемсезлеге, кешелекне аның явыз дошманнарыннан аралау, изгелекнең явызлыктан өстенлеген раслау кебек идеялар ята. «Урал батыр» кобайырында сурәтләнгән вакыйгалар Урал тавы һәм Агыйдел, Нөгеш, Җаек, Сакмар елгалары буенда, Шүлгән күле тирәсендә бара һәм, күп төрки халыкларның эпосындагы кебек үк, өч буын батырларның язмышы тасвирлана: Йәнбирзе карт белән Йәнбикә карчык, аларның уллары Шүлгән белән Урал һәм оныклары – Җаек, Идел, Нөгеш, Сакмар.

Әсәрнең тәүге өлешендә Йәнбирзе карт белән Йәнбикә карчыкның тормышы аша кешелек тарихының иң борынгы чорын күзаллап була: тирә- ягын су ураткан, кеше аягы басмаган урын, башкорт ыруларын башлап җибәрүче тәүге кешеләр, аларның көнкүреше (сунар итү, арыслан менеп йөрү, чи ит ашау, ут булмау), малайлары туу, үсү, гореф-гадәт, тыюлар барлыкка килү.

Икенче бүлектә икенче буын вәкилләре Шүлгән белән Уралның үлемне эзләп чыгып китеп, төрле вакыйгаларга юлыгуы, Шүлгәннең гел җиңелрәк юл эзләве, тора-бара диюләр ягына күчүе, Уралның исә, бер көч, каршылык алдында да туктап калмыйча, гел алга, максатына таба баруы һәм юлында тик изгелекләр генә эшләве турында бәян ителә. Урал Йәншишмәне таба, аның аз гына калган суын үзе эчмичә, тирә-ягына бөркеп, табигатьне үлемсез ясый.

Кобайырның өченче өлешендә Урал батырның уллары туып, батыр булып үсеп җитүләре һәм аталарының изге эшләрен дәвам итүләре турында сүз бара. Аталары үлгәннән соң, сусызлыктан йончыган халыкка Урал батырның уллары елгалар ералар һәм башкорт иленең төп елгалары Җаек, Идел, Нөгеш, Сакмар дип, аларның исемнәре белән атала. Шулай итеп, «Урал батыр» эпосында борынгы һәм мәңгелек мотивларның иң мөһиме –табигатьнең һәм кешелекнең мәңгелеге өчен көрәш темасы күтәрелгән. Анда шулай ук янә бер зур тема – явызлыкка каршы көрәш урын алган. Гаделлек белән явызлык көрәше борынгы кешеләр җәмгыятендә хөкем сөргән дуалистик карашның эпик иҗатка үтеп керүен күрсәтә. Фольклор эстетикасы буенча, явызлык никадәр көчле күренсә дә, гаделлек җиңә дигән идея үткәрелә.

Башкорт эпос белгече М. Сәгыйтов эпосның борынгылыгына ишарәләүче төп мотивтар рәтенә дөнья яратылуны, таулар, тугайлар барлыкка китерелүне, елгалар еруны, хайваннарны кулга ияләштерүне, кошларны, җәнлекләрне изгеләштереп карауны һ.б. кертә [Сәғитов, б. 59]. «Урал батыр» кобайырында шулай ук борынгы никах формаларының берсе дә чагылыш таба. М. Сәгыйтов билгеләп үткәнчә, Урал батырның «өч хатын алуында борынгы кешелек җәмгыятендә яшәгән полигамия – берничә хатын алу йоласының поэтик чагылышы күренә» [Сәғитов, б. 64]. Төп максаты Йәншишмәне табып, табигатьне һәм кешеләрне үлемсез итү булган Урал батыр өчен хатын алу бер очракта да аңлы, уйланылган адым булып тормый, ул – көтелмәгән очрашулар сөземтәсе һәм никах формаларының ныгып җитмәгәнлеге, вакытлы булуының гәүдәләнеше генә, С. Галин әйткәнчә, «гаилә мәсьәләләре “Урал батыр” кобайырында төп урында тормый, без биредә архаик, әле тәмам формалашып бетмәгән гаилә-никах мөнәсәбәтләренең чаткыларын гына күрәбез» [Галин, 1996, б. 36].

Эпик репертуарда урын алган сюжетлар ниндидер очракта берберсен тулыландырып киләләр. Әйтик, «Акбузат» әсәре «Урал батыр»ның дәвамы кебек кабул ителә. Әсәрләрнең икесендә дә Акбүзат хәрәкәт итә, Урал батырның алмаз кылычы телгә алына. Аларның сюжеты нигезендә дә җәмгыятьнең борынгы дәвере өчен хас сунар табышы өчен көрәш, хатын эзләү, гаилә кору кебек мотивлар урын алган. «Акбузат» кобайырының сюжет фабуласы гади генә булып тоела: Сәүбән исемле егет Шүлгәнкүл буенда сунар иткәндә, алтын үрдәккә атып, аны яралый, кыз үзенең су асты патшасы кызы булуын әйтә, мал вәгъдә итеп, егеттән үзен җибәрүен сорый. Сәүбән «артыңа әйләнеп карама» дигән тыюны бозгач, күлдән чыгып килгән маллар кире чума. Озак вакыт каравыллаганнан соң, Сәүбән кызны тагын очрата, бу юлы аның белән су астына төшә. Күпмедер вакыт яшәгәннән соң, Сәүбән туган илен нык сагына, кызның ярдәме белән иленә кайта. Күрүебезчә, «Акбузат» сюжетының нигезендә кыз артыннан китү, гаилә корырга тырышу мотивы ята. Тик табыш егетнең кулыннан ычкына, гаилә оеша алмый, гаиләнең аерылмас өлөше булган мал образы да юкка чыга, чөнки батыр алдына мөһимрәк бурыч – «мал

коты» булган Акбүзатны кулга төшерү һәм аның ярдәмендә Җир йөзендә гомуми бәхет урнаштыру өчен көрәш тора.

«Заятүләк белән Сусылу», «Кара юрга», «Куңыр буга», «Акбузат» белән «Аксак кола» шулай ук идея-тематик яктан бер-берсенә нык кына охшыйлар. Башкортларда елкы малының су асты дөньясыннан чыгуы һәм кешеләр тарафыннан кулга ияләштерелүе хакында бик күп легендалар яши. Аларда һәм «Акбузат», «Заятүләк белән Сусылу», «Аксак кола» кобайырларында елкы малының Шүлгән, Асылы, Акзират, Мауызлы һ.б. күлләр төбеннән чыгуы хикәяләнә. Риваятьләр буенча, шушы күлләр төбеннән чыккан тычкан (соры) сыртлы кола елкыдан иң яхшы башкорт атлары токымы таралган. Тора-бара кулга ияләштерелгән ат язмышы кешелек тарихы белән аерылгысыз рәвештә бергә үрелеп китә. Ә хайваннарны кулга ияләштерү һәм үрчетү кешелек цивилизациясе тарихында бөек борылыш саналган, борынгы община корылышыннан сыйнфый җәмгыять корылышына күчү дәверен чагылдырган. М. Сәгыйтов билгеләвенчә, елкы, сыер һәм башка киек-хайваннарның кулга ияләшү дәверендә башкортлар арасында «Кара юрга», «Куңыр буга», «Аксак кола» кебек уникаль циклны тәшкил иткән эпик комарткылар туган. Изгелекле хайваннар турындагы мондый үз аллы эпик сюжетларның башка төрки халыклар иҗатында булуы билгеле түгел. Әмма охшаш мотивларны башка төрки-монгол халыклары эпосында табарга мөмкин. Башкорт фольклорында сакланган изге хайваннар хакында аерым сюжетлар бөтен төрки халыклар эпосын, рухи мәдәниятен, мифологиясен өйрәнүче галимнәр өчен әһәмиятле чыганак булып тора [Сәғитов, б. 14].

Фольклор гыйлемендә эпик комарткыларның кайсысы борынгырак икәнен аларда җәмгыять үсешенең кайсы дәвере чагылган булуына карап билгелиләр, ягъни халык тарихындагы мөһим вакыйгаларны чагылдырудагы эзлеклелек принцибына таяналар. Бу очракта иң борынгылар рәтенә табигать «хуҗаларына», һәртөрле мифик көчләргә каршы юнәлдерелгән сюжетлар куелырга тиеш; алга таба борынгы община корылышының җимерелә башлавын чагылдырган, гаилә кору өчен көрәш темасына багышланганнары килә. Урта гасырлар чоры, ягъни феодаль мөнәсәбәтләр урнашу нигезендә иҗтимагый тормышта килеп туган үзгәрешләрне күрсәткән, сыйнфый тигезсезлек, ырулар арасындагы барымта күренешләрен, илне саклау, уртак дошман алдында бердәмлекне, ыруларны эреләтү темаларын күтәргән, ахыр килеп, чит ил баскынчыларына каршы көрәшне чагылдырган эпик әсәрләр. Менә шундый хронологиядә күз алдына китереп буладыр башкорт халкының эпик репертуарын.

Кызганычка каршы, бүгенге көндә архаик эпос өлгеләрен халыкның сөйләм теленнән язып алу мөмкинлеге юк, алар онытылган. Аларның эчтәлеге белән китапларда гына танышып була. Эпик комарткылар яшәүдән туктагач, башкорт чичән мәктәбенең дә эчтәлеге, яшәү рәвеше, функциясе үзгәргән. Башкорт чичән мәктәбе дигәндә, китапта басылган эпосны ятлап сәхнәдән сөйләп ишеттергән балалар, я булмаса шигъри осталыгы булган ижатчылар күз алдына баса. Урал аръягындагы Си-

бай каласында эшләп килгән «Урал батыр» башкорт чичән мәктәбендә (җитәкчесе – «Традицион халык мәдәнияте» номинациясендә Россия Федерациясенең «Рәсәй күңеле» премиясе лауреаты (2017) А.Г. Гайнуллина) өлкәнрәк яшьтәге кешеләрнең эпос сөйләве билгеле булды, бәлки тора-бара башкорт чичән мәктәбен тергезү мөмкин булыр.

Әлегә бу тема аерым мәкаләләрдә күтәрелгән булса да, аны өйрәнүгә багышланган махсус монография юк, димәк, ул көн тәртибендә тора һәм өйрәнүчесен көтә.

**Әдәбият**


Башҡорт энциклопедияһы: 7 томда / баш мөхәррире М.Ә. Илһамов. 3 т. Й–Л. Өфө: Башҡ. Энцикл., 2015. 632 б.

*Буранғолов М.* Сәсән аманаты: Халыҡ ижады һәм ижадсылар тураһында, туй йолалары, боронғо йырҙар һәм легендалар, ҡобайырҙар. Өфө: Башҡортостан «Китап» нәшриәте, 1995. 352 б.

*Галин С.Ә.* Заман һәм фольклор (әҙәби тәнҡит мәҡәләләре). Өфө: Башҡортостан китап нәшриәте, 1972. 112 б.

*Галин С.Ә.* Тарих һәм халыҡ поэзияһы. Өфө: Китап, 1996. 288 б.

*Киреев А.Н.* Башкирский народный героический эпос. Уфа: Башкнигоиздат, 1970. 304 с.

*Кирәй Мәргән.* «Урал батыр» менән «Аҡбуҙат» // Башкирский фольклор: 85 лет записи башкирского эпоса «Урал батыр»: сб. статей. / под ред. А.М. Сулейманова и Г.Р. Хусаиновой. Уфа: Гилем, 2000. Вып. 4. Б. 6–24.

*Нәҙершина Ф.А.* Башҡорт халыҡ ҡобайыр-иртәктәре хаҡында // Башҡорт халыҡ ҡобайыр-иртәктәре – Башкирские народные эпические сказания – Bashkir Folk Epic Stories / авт.-төҙ. Фәнүзә Нәҙершина. Өфө: Китап, 2010. Б. 5–17.

*Рәжәпов Р.Ф.* Башҡорт эпик ҡомартҡыларының мифологик нигеҙҙәре. Өфө: Ғилем, 2006. 182 б.

*Сәгитов М.М.* Боронғо башҡорт ҡобайырҙары. Өфө: Башҡортостан китап нәшриәте, 1987. 224 б.

*Хөсәйенов Ғ.Б.* Мөйтән бей һәм ҡобайыр хаҡында // Башкироведение: Сборник статей 75-летию со дня рождения академика АН РБ Г.Б. Хусаинова. Уфа: Гилем, 2004. С. 232–234.

*Хөсәйенова Г.Р.* Бөйөк Ватан һуғышы темаһының башҡорт фольклорында сағылышы // Проблемы востоковедения, 2020. № 2. Б. 70–76.

*Өмөтбаев Мөхәмәтсәлим.* Йәдкәр. Шиғырҙар, публицистик яҙмалар, тәржемәләр, халыҡ ижады өлгөләре, тарихи-этнографик яҙмалар. Өфө: Башҡортостан китап нәшриәте, 1984. 288 б.



*Тикшеренү эше Россия фән фондының 22-28-00940 номерлы гранты ярдәмендә тормышка ашырылды, https://rscf.ru/project/22-28-00940/*

*Исследование выполнено за счет гранта Российского научного фонда № 22-28-00940, https://rscf.ru/project/22-28-00940/*



***Хөсәенова Гөлнур Равил кызы,***
*филология фәннәре докторы, Россия фәннәр академиясе Уфа тикшеренү үзәге Тарих, тел һәм әдәбият институтының фольклористика бүлеге мөдире*

***Шарапова Илсөяр Рамзис кызы,***
*фәлсәфә фәннәре кандидаты, Россия фәннәр академиясе Уфа тикшеренү үзәге Тарих, тел һәм әдәбият институтының Башкортстан тарихы һәм мәдәният тарихы бүлеге фәнни хезмәткәре*

УДК 398.4

***Л.Х. Дәүләтшина,***
***Л.М. Фәхриева***

# ҖЕН ТУРЫНДАГЫ ЫШАНУЛАРНЫҢ ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ БҮГЕНГЕ КӨН МИФОЛОГИК КҮЗАЛЛАУЛАРЫНДА ЧАГЫЛЫШЫ

В исследовательской работе представлен анализ современных мифологических представлений татар о персонаже нечистой силы *җен*. Источниками исследования являются полевые материалы авторов статьи и опубликованные тексты, охватывающие изучаемый пласт верований. В ходе работы выполнен анализ текстов, раскрывающих основные признаки исследуемого мифологического персонажа, который на современном этапе развития мифологической системы является персонажем-заместителем для всей нечистой силы в целом.

**Ключевые слова:** татарская мифология, мифологическая система, мифологический персонаж, функция, признак.

This work presents an analysis of the modern mythological ideas of the Tatars about the character of evil spirits җen. The sources of the study were the field materials of the authors of the article and published texts covering the studied amount of beliefs. In the course of the work an analysis was made of texts that reveals the main features of the mythological character under study, which at the present stage of development of the mythological system is a substitute character for all evil spirits in general.

**Keywords:** Tatar mythology, mythological system, mythological character, function, feature.

Фәнни әдәбиятта кабул ителгән классификацияләү принципларына нигезләнеп, татар халкының мифологик мирасын югары мифологиягә һәм түбән мифологиягә бүлеп карау кабул ителгән [Урманче, 2005; Бакиров, 2012]. Төрки-татар мифологиясе тәңречелек тәгълиматы белән бәйле югары дәрәҗәле аллалар (Тәңре, Җир-Су, Умай, Алас һ.б.) турындагы мифологик хикәятләрне һәм ышануларны бергә берләштерә. Андый хикәятләр һәм ышанулар өлешчә булса да борынгы язма ядкярләрдә теркәлеп калган, ә бер өлеше безнең заманга легенда-риваятьләр рәвешендә килеп җиткән. Мифологик мирасыбызның икенче төре – түбән мифология исә алла статусына ия булмаган ияләр, рухлар һәм зарарлы көчләргә бәйләнешле ышануларны һәм хикәятләрне үз эченә ала. Ияләр табигать объектларының, кеше яши торган торак урыннарының хуҗасы буларак кабул ителәләр һәм, күңелләрен күрә белсәң, кешегә файдалы затлар буларак күзалланалар. Җен, албасты, убыр, өрәк, шүрәле һ.б шундый түбән рухлар адәм баласының тормышында туган күңелсезлек, бәхетсезлек, акылдан язу кебек күренешләрнең сәбәпчесе буларак тасвир ителәләр. Түбән мифология персонажлары турындагы текстлар татар халкының төрле

этник традицияләрендә күптөрле локаль вариантларда бүген дә саклана, бу төр текстлар экспедицияләр барышында хәзерге көндә дә күпләп язып алына. Алар татар халкының мифологик системасын реконструкцияләү өчен кызыклы һәм файдалы чыганак ролен үтиләр.

Татар халкының бүгенге көн мифологик күзаллауларында түбән мифология персонажларын функциональ яктан үзендә берләштерүче иң актив затларның берсе – җен. Бу персонажның генезисы, бер яктан, мөселман мифологиясендәге җеннәргә, икенче яктан, ислам дине таралыш тапканчы барлыкка килгән явыз көчләр турындагы халык күзаллауларына барып тоташа. Тикшеренүчеләр фикеренчә, татар мифологиясенә ул мөселман динен кабул итү белән бергә үтеп керә һәм тулаем алганда явыз көчләрне гәүдәләндерә башлый, әмма шул ук вакытта функциональ яктан катлаулана, үзенә генә хас билгеләр белән байый [Урманче, 2009, б. 55; Әхмәтҗанов, 2011, б. 24; Давлетшина, 2020, с. 126].

Исламга кадәрге чорда ук Гарәбстанда яшәгән мәккәлеләр җеннәрне Аллаһка тугандаш илаһлар дип санаган (Коръән 37:158). VI–VII гасырларда Эчке Гарәбстанда яшәүчеләр өчен әйләнә-тирә дөнья – чүлләр, таулар, ташлар һәм агачлар җеннәр белән тулган булган; алар, нигездә, кешеләргә дошман дип саналган, ләкин аларга табынып һәм корбан китереп, ярдәм дә сорарга мөмкин булган («Әнгам» сүрәсе, 100 нче аять, 128 нче аять; «Саффат» сүрәсе, 158 нче аять; «Җинн» сүрәсе, 6 нчы аять)» [Мифы народов мира, 2003, с. 374]. Мөселман традициясе буенча, җеннәр Аллаһ тарафыннан төтенсез уттан барлыкка китерелгән акылга ия затлар дип исәпләнә. Җеннәрнең бер өлеше ислам динен кабул иткән һәм Аллаһыга иман китергән, шуңа күрә халык аңында аларны мөселман җеннәренә һәм кяфер җеннәренә бүлү барлыкка килгән.

Бүгенге көн татар халык ышануларында җен, бер яктан, кешегә зыян китерердәй персонажларны алыштырып килә, икенче яктан, аның үзенә генә хас функциональ кыры да оеша. Экспедиция барышында язып алынган текстларда информантлар әлеге персонажны *җен, чин, шайтан, зәхмәт*, *чин-сәхмәт, җен-зәхмәт, пәри, җен-шайтан, җен-пәри, гыйлем җеннәре*, *мөселман җеннәре, шәйтани җеннәр, начар җеннәр* һ.б. дип атыйлар. Әлеге исемнәрдән күренгәнчә, татарлар арасында җен атамасының синонимы буларак шайтан һәм пәри исемнәре дә кулланышта йөри. Шайтан Аллаһы Тәгаләгә буйсынудан баш тарткан өчен Күктән Җиргә төшерелгән фәрештә булса, пәри – Иран мифологиясенең борынгы катламнарына барып тоташкан һәм төрки телле әдәби һәйкәлләрдә XI гасырда ук искә алынган мифологик персонаж. Ул Урта Азия, Казакъстан, Төньяк Кавказ һәм Идел буенда яшәгән төрки телле халыклар мифологиясендә күпчелек очракта кешеләргә илтифат күрсәткән һәм аларның ярдәмчеләре булган ир-ат һәм хатын-кыз рухлары буларак кабул ителә [Мифы народов мира, 2003, с. 287]. Ислам дине таралу нәтиҗәсендә пәриләр хак динне тотучы һәм тотмаучыларга бүленә башлый, явыз затлар статусына

төшерелә һәм функциональ яктан җеннәр белән якыная. А.Е. Бертельс фикеренчә, фарсы сүзе «пәри» ислам таралыш тапкан беренче гасырларда ук гарәп сүзе «җен» белән бер сининомик рәт барлыкка китерә [Бертельс, 1979, с. 124]. Эпик фольклорда һәм Урта гасырлар татар шигъриятендә пәри катлаулы һәм күпкырлы мөстәкыйль образ буларак тасвир ителсә [Яхин, 2000, б. 173–175; Урманче, 2009, б. 275–276], татар халкының хәзерге мифологик карашларында җен, пәри, шайтан үзенчәлекле характеристикалар кушылмасына ия бердәм мифологик персонаж буларак кабул ителә.

Җен көндәлек тормышта күзгә күренеп йөрми, ул гаиләсе белән параллель дөньяда яши, әмма үзенә кирәк булганда кеше, берәр әйбер, табигать күренеше һ.б. кыяфәтләргә керергә мөмкин. Татарлар арасында таралыш тапкан ышанулар буенча, кеше тирәсендәге бөтен дөнья күзгә күренми торган җан ияләре белән тулы. Чит дөнья безнең күзгә күренмәсә дә, җен дөнья чикләре аша ирекле үтеп керә һәм кеше күзенә адәм заты үзе теләсә генә күренә. *«Җеннәр бар. Алар йөриләр. Алар төрле сыйфатка кереп киләләр. Эт сыйфатына да кереп киләләр, хайван сыйфатына да. Кеше кыяфетендә дә була»* [Ямалтдинов, 2018, б. 322]. *«Тагын бер хәл. Күршебез, мәрхүм Зиннур абый, Кырлай урманыннан төшкәндә, аңа ияреп, җеннәр төшкән. Аларны күреп, Зиннур абый бик курыккан һәм үзеннән-үзе куллары калтырый торган булып калган. Ишегалдына кадәр артыннан кергәннәр һәм юкка чыкканнар. Кич белән Зиннур абыйның әнисе Фахирә апай ишегалдына чыккан. Берзаман караса, ни күрсен, теге җеннәр лапасларында «Рамай» көенә рәхәтләнеп җырлап яталар икән. Фахирә апай, аты юлы белән сүгенеп: «Бар, йөрмәгез монда, өегезгә кайтыгыз!» – дигән һәм кереп киткән. Тынычлап кына йоклап киткән. Төнге икеләр тирәсендә тәрәзә шакыган тавышка уянып караса – теге җеннәр шакый икән. «Ярар, Фахирә, без киттек», – дип кайтып киткәннәр»* [Татар халык иҗаты, 2021, б. 276].

Дини традиция буенча җеннәр хак дин тотучы һәм тотмаучыларга бүленә. Мөселман җеннәре кешенең яхшы ниятләрендә юлдаш булалар, Коръәнне өйрәнергә ярдәм итәләр, догалар, намаз уку тәртибе һәм башка эшләргә өйрәтәләр. Кяферләре исә, киресенчә, кешене зыянлы гамәлләр кылырга мәҗбүр итәләр, аны хак юлдан яздыралар. Ел дәвамында һәр җирдә таралып яшәгән җен вәкилләренең явызлыкларын эшли алмаган бердәнбер вакыт аралыгы – Ураза ае, бу вакытта алар богауда була. *«Ул шайтани җеннәр бар, гыйлем җеннәре бар. Кайбер ишесе бик каты белгәчтен, моны гыйлем җеннәре өйрәткән, дип әйтәләр иде әбиләр безнең. Минә догаларны бик белә, бик каты дин буенча белә инде. «Аны төнлә гыйлем җеннәре өйрәтә», – дип әйтәләр иде әбиләр... Алары яхшыдыр, күрәсең, яхшыдыр»* [Давлетшина, 2015, с. 77]. *«Болай вакытта бар инде алар, менә уразаларда алар богауда булалар икән. Ну усалы, усалы гына кала икән. Усалын тота алмыйлар, ахры, аның.*

*Ә тегеләре богауда була. Ураза хәзер, курыкмагыз, җен җук дип әйтәләр иде»* [Татар халык иҗаты, 2021, б. 272].

Һәрвакыт кеше янәшәсендә булган явыз затның өйгә дә үтеп керү мөмкинлеге аңа карата тыюлар һәм кагыйдәләр җыелмасын барлыкка китерә. Йортны гаиләгә авырулар һәм низаглар китергән җен һөҗүменнән саклар өчен, шәмаилләр, миләш ботаклары, цикорий сабаклары, ат чабатасы, тоз, дары һ.б. кулланыла, билгеле бер гамәлләр комплексы башкарыла (кергәндә аякка ияреп кермәсен өчен, аякны селкеп керү, җен үтеп керергә мөмкин булган юлларны (тәрәзә, ишек, мич) «бисмилләһир-рахмәәнир-рахииим» дип ябу һ.б.). *«Тәрәзә төбенә ризык куймагыз, җен җөри тора урын (тәрәзә төбенә бернәрсә дә куймагыз, бу җен йөрү урыны)»* (Татарстан Республикасы Апас районы Урта Балтай авылында Л.Х. Җамалиевадан (1969 елгы) Л. Дәүләтшина тарафыннан язып алынган).

Йорт явыз көчләрдән барлык мөмкин булган ысуллар белән сакланса да, мунча әлеге персонажның даими яшәү урыны буларак кабул ителә. XXI гасыр башы мифологик традициясендә мунча иясе турындагы ышанулар тулысынча диярлек югала, әмма аңа нисбәтле булган урын җеннәргә бәйле актуальләшә. Мунча белән бәйле булган иң тотрыклы мотив, җеннең кешене үтерергә тырышуы яки башын мичкә тыгып үлемгә китерүе турындагы сюжетларда чагылыш таба. Шуңа бәйле рәвештә, кояш баегач, шулай ук көндезге һәм төнге сәгать уникедә мунчага керү тыела, бу кагыйдәне хәтта мифологик персонажлар булуын танымаган информантлар да мәҗбүри дип саный. *«Элек бөтен кешедә мунча юк иде. Сәхап абыйлар мунчасына кердек. Хәллерәк кешедә генә бар иде мунча. Мин кечкенә малай, әни белән кердек. Минә шунда түшәмнән әллә нинди туфраклар коела башлаган шикелле булды теге мунчада. Тәрәзәдән карыйбыз: мунчадан өйләренә таба менә шундый клубок ут китте. Шуннан хәл китте минем. Әни әйтә: – Улым, җен ул. Әйдә чыгабыз, – дип тиз генә өскә яртышар чиләк су сиптек тә, чыгып ычкындык без аннан»* [Ямалтдинов, 2016, б. 120]. *«Шайтан бар, – дир. Менә мунца кереп кайтканнар. Ә бер катын кайтми да кайтми да дир мунцадан. Барса, ишекне тартып аца алми, дир, ишекне йибәрми, дир. Аннары Аятел көрси укып ацып йибәргән икән. Мунца пиценә тыкканнар теге катынны, дир»* (Татарстан Республикасы Чүпрәле районында Ф. Баязитова тарафыннан язып алынган) [Баязитова, 2018, б. 303].

Татар фольклорында җен хатынының бала таба алмый азаплануы турындагы сюжетлар киң таралыш таба. Халык арасында, мондый хәл килеп чыкканда, мифологик затлар, ярдәм сорап, кендек әбисенә мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр булалар дигән ышану яшәп килә. Әлеге мотивка бәйле таралыш тапкан хикәятләр, гадәттә, бер сюжетка нигезләнә. Кендек әбисе мунчада бала таптырганнан соң, аны өенә кайтарып куялар, бүләккә биргән алтын тәңкәләр исә соңыннан ат тизәгенә әверелә. Бу сюжетның киң таралыш табуы өйдә һәм мунчада ризык һәм теләсә нинди сыеклыкларның өстен ябу турындагы

ышануны актуальләштерә, чөнки капланмаган килеш калдырылган сөттә яки суда җен баласын юа дигән сюжет бүгенге көндә дә еш очрый. *«Фатыйма әби булган, «карт әби» дип йөри идек без аны. «Туксан тугыз кешегә әбилек булдым, – дигән, – йөзенчесе – җенгә булдым», – дигән. Бу хәзер төн, сәгать унбер-уникеләр булган, карамаган да инде сәгатьне. «Фатыйма түти, тиз генә киенеп чык, балага авырта хатыным», – дип алып киткәннәр. Шуннан алып чыгып киткәннәр. Барган, бәбәйләткән, баланы юдырган сөт белән. Кая алып киткәннәрен дә, алып барганнарын да белми, кайтарып куйганнар. «Янымда кешеләр барын да белмим», – дип әйтә, ди. Кыштыр-кыштыр аяк эзеннән барган, шуннан кайткан, өйгә кайтып кергән. Иртә белән әйткән: «Менә шушындый-шушындый хәл булды, ышанасызмы-юкмы? Кайсыгызның сөтенең өсте ябылмаган бисмиллалап, карагыз – кан булыр», – ди. И күршедә, Әмәт әби дибез инде, шуның сөте белән юдырганнар баланы, бисмилласыз калдырырга ярамый, дип. Электән үк килгән бит инде ул: әйбернең өстен бисмиллалап ябарга, дип... «Туксан тугыз кешегә булдым, йөзенчесен җенгә булдым», – дигән минем әби. Кечкенә генә карчык иде ул, әз генә хәтерлим кендек әбисе дип»* [Татар халык иҗаты, 2021, б. 291].

Мифологик персонажның кеше белән үзара мөнәсәбәтләрен яктырткан сюжетлар арасында иң активларының берсе – баланы җен алыштыру. Экспедиция барышында язып алынган текстлардан күренгәнчә, баланы я ана карынында вакытта яки туганнан соң (гадәттә, беренче кырык көндә) җен алыштырырга мөмкин. Зур башлы, нәзек куллы һәм аяклы, түгәрәк корсаклы, ямьсез балаларны халыкта җен алыштырган бала дип атыйлар. Гадәттә мондый балалар үсми, сөйләшми, йөри алмый һәм тиздән үлә. Информантлар әйтүенчә, аларның кайберләре генә унсигез яшькә кадәр яшәгән. Мондый язмышка дучар булмас өчен, авырлы хатын-кызны һәм яңа туган баланы туганчы һәм аннан соң кырык көн дәвамында караучысыз калдырмаска тырышалар. Бу чорда җен теләсә нинди кыяфәттә, хәтта бала тудыручы әби образында да килеп, баланы үзенеке белән алыштыра ала. Әгәр дә ялгыз калдырырга туры килсә, баланы һәрьяклап якларга тырышалар: бишеккә тимер әйберләр (пычак, кайчы), сарымсак, миләш ботаклары, миләш, изге Коръән китабы салалар, кендеккә көл сөртәләр һ.б. *«Искечә, қадимчә йазылған китапны мендәр астына салып җоқлатыр ыйык, шулай бәбәй бишегенә салыр ыйық “җен килмәскә”. Бишек тирәсенә қайчы, пычақ қуйар ыйық»* [Баязитова, 2012, б. 243]. Мондый төр ышануларның киң таралыш алуы кеше баласын кире кайтаруга бәйле ритуаль практикалар барлыкка килүгә китергән, әмма бүгенге көндә алар бик сирәк теркәлә. Баланы алыштыруга бәйле фольклор текстларын анализлау шуны күрсәтә: бер яктан, җен бу гамәлне кешеләргә зыян китерергә теләгәннән башкара, икенче яктан, ул болай итеп адәм зәхмәтеннән котылырыга тели, чөнки бу төр зәхмәттән коткару көченә бары кеше баласы гына ия була.

Җен белән очрашу темасына бәйле текстларның бер өлеше тол калган хатын янына үлгән ире кыяфәтендә кайтып йөрүче җен персонажына бәйле. Мондый хәлдә калган хатын-кыз көннән-көн кибә һәм, чарасын күрмәсәң, үлә. Шуңа бәйле рәвештә халык мәдәниятендә бу хәлне булдырмау максатында төрле тыюлар барлыкка килгән. *«Ире сугышта үлеп киткәч, бик сагынган, бик елаган апай, бик елаган. Берзаман җизни булып җен килеп киткән. Пинжәкләрен киеп кайта торган булган. Җанында ятып, шулый ире кебек булган. Хәзер бу әнкәйгә сөйләгән кечкенә апай. Кайтып йөри бит, әнкәй, көн саен кайта, йоклыйбыз, аннан соң чыгып китә дип. "Бүгеннән үк балаларыңны җыеп кил. Бүгеннән калма, җенләнгәнсең икән. Нишләп кияү кайтсын сугыштан. Елап көтеп йөргәнгә күрә җен килгән", — дигән әнисе. Менә шулай. Монда килмәгән аннары. Ыштанын кисәң дә ярый инде, җен килмәсен өчен. Мин иремнең тапыен[1] салып куйган. Баш астымда тора»* (Татарстан Республикасы Яшел Үзән районы Кече Шырдан авылында М.Г. Гатауллинадан (1925 елгы) Л.Х. Дәүләтшина тарафыннан язып алынган).

Җеннең даими функцияләренең берсе – кешеләрне адаштыру, аларны юлдан яздыру. Башка төр сюжетлар очрамаса да, бу мотив сюжет формалаштыручы булып тора һәм теләсә нинди җирле традициядә адашулар һәм алар белән бәйле халәтләр турында сөйләк вариантларын язарга мөмкинлек бирә. Җеннең адаштыру ниятен тормышка ашыра торган урыннар булып гадәти юл түгел, ә җиде юл чаты, зират янындагы юллар, күперләр билгеләнә, бу урыннарның һәрберсендә кешене бутаган, аны юлдан яздырган, юлсыз калдырган бер яки берничә җенне очратырга мөмкин. *«Бу инде бик күптән булган эш. Бер мулла, ямщикка утырып, каяндыр Кыргапка таба юл тоткан. Көн кичкә якынлашып бара. Көз көне икән, аз гына яңгыр сибәли икән. Менә алар, Атачка авылын үтеп, «Кара тал»га ялкынлашканнар. Мулла юл буенда гына бер ялгыз, берничә катлы, яп-якты итеп яктыртылган йорт күргән. Тәрәздән күренә икән: өй эче тулы ирләр күңел ачып утыралар. Бу ни хәл, дип уйлаган мулла. Атны туктата да, төшеп, өйгә таба бара башлый, кинәт өй юкка чыга. Мулла, куркып, догасын укый да, атка менеп утыра. Бераз баргач, арба бөтенләй әкренәйгән кебек булып китә. Нәрсә бар икән дип, як-якларына карансалар, бер бозау боларның арба артына башын салып бара. Мулла куып карый, бозау селкенми дә. Шунда ямщик чыбыркысы белән сугып җибәрә, бозау югала, ә ямщик телсез кала. Арба җиңеләеп китә. Болар Кызыл кашын үтеп, Мурлы елгасына килеп җитәләр. Елганы чыгалар, карасалар, җирдә бер дүрт читле нәрсә ятканы күренә. «Нәрсә икән бу?» – дип, мулла, бисмилласын укып, җиргә төшә дә якын килә, карый: түшәк. «Кемнән төшеп калган икән бу?» – дип, мулла түшәкне арба артына сала. Баралар. Мулла*

[1] Тапый – чапкы.

*бервакыт күзен ачып җибәрсә, янында гына бер хатын-кыз муллага күзләрен чекерәйтеп карап утыра. Мулла, пәридер дип, догалар укый башлый. Ә теге шул догаларны кире ягыннан укый. Кыргапка якынлашалар, теге хатын-кыз юк була. Таныш муллаларның капка төбенә килеп җиткәч, ат туктый, мулла да, ямщик та аттан төшәләр, икесе дә телсез калганнар. Мулла (Кыргап мулласы) өйгә алып кереп өшкергәч кенә исләренә киләләр»* [Милли-мәдәни мирасыбыз: Омск өлкәсе..., б. 376]. Бу төр сюжетларның киң таралыш табуы саклану ысулларының актуальләшүенә китерә (сүгенү, догалар уку, киемнәрне кире ягы белән алмаштырып кию, тимер әйберләр куллану һ.б.).

Гомумән алганда, халык телендә җен дип аталып йөртелгән персонаж ислам дине өйрәтүләре нигезендә таралыш тапкан булса да, бүгенге көндә исемнәре, генезисы, тышкы кыяфәте ягыннан мөселман традициясенә якынлыгын саклаган хәлдә, функциональ яктан татар халкының мифологик күзаллауларына бәйле рәвештә шактый баеган һәм үзгә персонажга әверелгән. Явыз көчләргә хас булган гамәлләрне башкару белән бергә, җен үзенең чагыштырмача тотрыклы билгеләре белән дә характерлана. Иң типиклары арасында кешегә сырхау җибәрү, баланы алыштыру, тол хатын янына мәрхүм ире кыяфәтендә кайтып йөрү, кешене юлдан яздыру һ.б. Ислам таралу чорында мифологик системага үтеп кергән персонаж күп гасырлар дәвамында адаптация узганнан соң, мөселман мифологиясе белән бәйләнешен югалтмаган, әмма татар халкының мифологик күзаллауларын үз эченә алган мөстәкыйль образ формалаштырган.

**Әдәбият**

*Әхмәтҗанов М.И.* Татар археографиясе. Соңгы елларда археографик экспедицияләр вакытында тупланган кулъязмаларның тасвирламалары. Сигезенче кисәк. Казан: Институт истории АН РТ, 2011. 238 б.

*Бакиров М.Х.* Татарский фольклор. Казан, 2012. 399 с.

*Баязитова Ф.С.* Халык традицияләре лексикасы. Мифологик персонажлар, ышанулар (Җирле сөйләшләр һәм фольклор текстлары яссылыгында). Казан, 2018. 815 б.

*Бертельс А.Е.* Пери // Культура и искусство народов Средней Азии в древности и средневековье. М.: ГРВЛ, 1979. 191 с.

*Давлетшина Л.Х.* Лексема *җен* в говоре татар нагорной стороны // Пермистика 15: Диалекты и история пермских языков во взаимодействии с другими языками: Сборник статей / УИИЯЛ УрО РАН, Удм. гос. ун-т. Ижевск: Издательский центр «Удмурсткий университет», 2015. С. 74–80.

*Давлетшина Л.Х.* Персонаж *җен* в современных представлениях поволжских татар // Традиционная культура. 2020. Т. 21. № 1. С. 124–135.

*Ямалтдинов И.И.* Бабалар сүзе – акылның үзе // Милли-мәдәни мирасыбыз: Арча. Казан, 2016. Б. 113–186.

*Баязитова Ф.С.* Табын күрке – туганнар // Милли-мәдәни мирасыбыз: Мари Эл татарлары. Бәрәңге. Казан, 2012. Б. 229–254.

Милли-мәдәни мирасыбыз: Омск өлкәсе татарлары. Казан, 2015. 457 б.

*Ямалтдинов И.И.* Ульяновск өлкәсе татарлары // Милли-мәдәни мирасыбыз: Ульяновск өлкәсе татарлары. Казан, 2018. Б. 305–447.

Мифы народов мира: Энциклопедия: в 2 т. Т. 1 / под ред. С.А. Токарева. М., 2003. 672 с.

Татар халык иҗаты: 25 томда. 1 т.: Мифология / [төз., текст, иск. һәм аңл. әзерл., кереш сүз авт. Л.Х. Дәүләтшина]. Казан: Татар. кит. нәшр., 2021. 511 б.

*Урманче Ф.И.* Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек: 3 томда: 2 т. (Д–С). Казан: Мәгариф, 2009. 344 б.

*Урманче Ф.И.* Татар халык иҗаты. Казан, 2005. 383 б.

*Яхин Ф.З.* Татар шигъриятендә дини мистика һәм мифология. Казан: ТДГИ нәшрияты, 2000. 415 б.

***Дәүләтшина Ләйлә Хәсән кызы,***
*филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

***Фәхриева Ләйсән Марат кызы,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты беренче курс аспиранты*

УДК 94(575.4)

*А.Н. Расулов,*
*Д.М. Насретдинова*

# ТАТАР ХАТЫН-КЫЗЛАРЫНЫҢ ТӨРКЕСТАНДА АГИТАЦИЯ-ПРОПАГАНДА ЭШЕНДӘ КАТНАШУЫ (1917–1920 еллар башы)

Статья посвящена исследованию особенностей организации татарскими женщинами агитационно-пропагандистской работы среди мусульманок Туркестана после Октябрьской революции 1917 года. Автор освещает деятельность татарских активисток Зохиды Бурнашевой, Шамсузухы Хаировой, Марьям Бахтияровой, внесших существенный вклад в развитие женского просвещения в регионе, а именно – в организацию женских школ, педагогических курсов, клубов по ликвидации безграмотности и др.
**Ключевые слова:** татарские просветительницы, просвещение, Туркестан, Зохида Бурнашева, Шамсузуха Хаирова, Марьям Бахтиярова.

The article is devoted to the study of the peculiarities of the organization of agitation and propaganda work among the Muslim women of Turkestan by Tatar women after the October Revolution of 1917. The author highlights the activities of Tatar activists Zokhida Burnasheva, Shamsuzukha Khairova, Maryam Bakhtiyarova, who made a significant contribution to the development of women's education in the region, namely, to the organization of women's schools, pedagogical courses, illiteracy eradication clubs, etc.
**Keywords:** Tatar educators, education, Turkestan, Zokhida Burnasheva, Shamsuzuha Khairova, Maryam Bakhtiyarova.

Җәмгыятьтә социаль тигезсезлекне бетерү, шул исәптән хатын-кызларның тигез хокуклылыгын юридик яктан һәм чынбарлыкта тәэмин итү, аларның социализм төзүдә ирләр белән бертигез катнашуын тәэмин итү революциядән соң көнүзәк мәсьәләләрнең берсе була. Бу гасырлардан килгән дини-көнкүреш хорафатлар, хатын-кызларның коллык, хокуксыз хәле сакланган шартларда гаять авыр бурыч иде. Теге яки бу дәрәҗәдә хокукый тигезсезлек бөтен Россиягә хас иде. Совет хакимияте яклы кешеләрнең санын арттыру максатында, урыннардагы хатын-кызларны иҗтимагый тормышка җәлеп итү хисабына хатын-кызлар бүлекләре булдырылды. Алар халык арасында актив агитация-пропаганда эшләре алып барды. Төп чаралар хатын-кызларны иреккә чыгаруга, пәрәнҗә ябуга каршы көрәшне көчәйтүгә, аларның социаль-сәяси активлыгын күтәрүгә юнәлтелде. Шул ук вакытта яңа пролетариат культурасын барлыкка китерү сәясәте милли мәдәни мирасны һәм тормыш кыйммәтләрен исәпкә алмыйча гамәлгә ашырылды. Культура-агарту өлкәсендә лидерлар тәрбияләү максатында политкурслар оештырылды.

Төркестанда хатын-кызлар бүлеген һәм мәгарифен оештыручыларның берсе – З.Х. Бурнашева. Октябрь революциясеннән соң ул Россиядән Төркестанга килә. 1918 елда башта Сәмаркандта «Мехнаткашлар говуши» («Хезмәт ияләре тавышы») газетасы мөхәррире булып эшли һәм соңыннан аны Каттакурган өязенә җибәрәләр. Ул анда 1919 елга кадәр халык мәгарифе бүлеге мөдире урынбасары вазифасын башкара. 1919 елда Төркестан коммунистлар партиясе Үзәк Комитеты (ТКП ҮК) каршындагы хатын-кызлар бүлеге, оештыру сәләтен исәпкә алып, З.Х. Бурнашеваны Ташкентка күчерә. Биредә ул Иске Ташкент шәһәрендә беренче хатын-кызлар мәктәбен ача һәм хатын-кызлар өчен оештырылган төбәк педагогика курсларын җитәкли. Алга таба әлеге курслар Хатын-кызлар мәгариф институты дип үзгәртелә һәм аның эшчәнлеге белән З. Бурнашева җитәкчелек итә. Хатын-кызлар мәгариф институтын тәмамлаган Җахан Абидова, Таҗихан Шадиева һәм җирле халыкның күп кенә башка вәкилләре соңыннан Төркестанда хатын-кызларны азатлыкка чыгару өчен көрәшеп танылу ала. З.Х. Бурнашева үзенең туган теле – татар теленнән кала Төркестан халыкларының телләрен һәм бу төбәк хатын-кызларының авыр хәл-хәләтен яхшы белә, аларга булдыра алганча ярдәм итәргә тырыша. Аның актив катнашлыгында, халык мәгарифен үстерү максаты белән, берничә тапкыр «Мәктәпкә ярдәм атналыгы» оештырыла. 1920 елда Төркестан хатын-кызларының I корылтаенда Төркестан фронты командующие М.В. Фрунзеның чыгышын үзбәк теленә тәрҗемә итү дә нәкъ менә аңа йөкләнә. З.Х. Бурнашева шулай ук ТКП ҮКның хатын-кызлар бүлеге мөдире, РКП(б) ҮКның хатын-кызлар бүлеге инструкторы буларак һәм ТКП ҮК, партиянең Төрекмәнстан өлкә комитеты каршындагы хатын-кызлар бүлекләрендә төрле вазифаларда хезмәт куя. 1933 елдан 1951 елга кадәр Кыргызстанда җаваплы партия вазифаларында эшли [Расулов, 1990, с. 150; Татар хатын-кызлары..., б. 143–149; Гайнуллин, с. 286–289].

1918 елның 6 сентябрендә Төркестан Халык мәгарифе комиссариаты утырышында югарыда аталган курсларның проекты раслана [ҮР МА, 34 ф., 1 тасв., 103 сакл. бер., 3 кгз.]. Төркестан Халык мәгарифе комиссариатының 1919 елның 2 гыйнварында расланган «Эшчеләргә ярдәм йөзеннән мәдәни агарту курсларын ачу турында» нигезләмәсе буенча Комиссариат каршында өч айлык курслар оештырыла. Курсларда мәдәни-агарту учреждениеләре өчен квалификацияле инструкторлар әзерләнә. Укырга 18 яше тулган урта белемле затлар кабул ителә. Курсларның нигезләмәсе буенча, укуны тәмамлаучылар мәҗбүри рәвештә кимендә бер ел өлкәдә, районда яки шәһәрдә инструктор вазифасында эшләргә тиеш була. Төркестан Халык мәгариф комиссариаты тарафыннан бирелгән 850 сум күләмендәге акчалата компенсация яшьләрне җәлеп итүдә зур стимул булып тора [ҮР МА, 34 ф., 1 тасв., 103 сакл. бер., 21–21 кгз. арты].

Шуның белән бергә 1920 елдан башлап, яңа совет мәктәпләрендә эшне оештырырга ярдәм итү өчен, инструкторлык курслары

ачыла. Әлеге курсларны тыңлаучыларның күбесе татар кызлары була. Әйтик, 1920 елда мәктәп инструкторлык курсларын тәмамлаган 353 тыңлаучының 210 ы – татар кызы. Курсларны тәмамлаучылар Төркестан Халык мәгарифе комиссариаты юлламасы буенча төрле төбәкләргә эшкә җибәрелә. Аерым алганда, Гафифә Бурнашева мәктәп инструкторы сыйфатында Фирганә өлкәсенең Әндиҗан өязенә, Хәдичә Курманбаева Семиреченск өлкәсенең Верный өязенә барып эшлиләр [ҮР МА, 34 ф., 1 тасв., 523 сакл. бер., 43–43 кгз. арты].

Инструкторлар хатын-кызлар арасында зур пропаганда эше алып бара. Кадрларны Үзәккә укырга җибәреп әзерлиләр. Беренче елларда инструктор вазифасын, нигездә, руслар яки башка мөселман булмаган кешеләр үти. 1919 елның көзендә Төркестанда И. Финкельштейн җитәкчелегендә хатын-кыз инструкторлар бүлеге оештырыла. Беренче инспектор Л. Шумилова була. 1919 ел ахырында һәм 1920 еллар башында Каспий аръягы һәм Сәмәрканд өлкәләренә хатын-кызлар бүлекләре оештыру өчен инструкторлар җибәрелә. 1919 елның декабрендә Л. Шумилова әлеге төбәккә командировкага килә. Кыска гына вакыт эчендә ул биредәге хатын-кызларның хөрмәтен казана. Аңа төрле төбәкләрдән урыннардагы хатын-кызлар арасында агитация эшләрендә булышуын сорап язылган телеграммалар һәм хатлар килә [Шукурова, с. 73–74].

Хатын-кызлар бүлеге хезмәткәре Т. Бендецкая үзенең истәлекләрендә язганча, бүлекнең беренче коллективы составында үзбәк Содикова, татарлар Зөһрә Сәфәрова, Фатиха Редкина һәм Заһидә Бурнашева булган [Финкельштейн, Шукурова, с. 13]. 1920 елның апрелендә алар Төркестан хезмәт иясе хатын-кызларының беренче корылтаен оештыруда актив катнашканнар [Первый Туркестанский…].

1919 елның декабрендә хатын-кызлар бүлеге филиалы Ташкент шәһәрендә дә ачылган. Биредә татар кызлары М. Йосыпова, З. Бурнашева, Хөсәнбаева, Ш. Кәримова эшли. Хатын-кызларның эшчәнлеге «Иштирокиюн», «Кизил Байрок», «Туркистон», «Озод Бухоро», «Мориф», «Инкилоб куёши» газеталарында яктыртыла [Алимова, с. 14–15]. Татар кызлары үзләренең мәкаләләрендә җирле хатын-кызлар арасында большевистик идеяләрне таратуга бәйле мөһим мәсьәләләр күтәрәләр.

Төбәк хатын-кызларын совет дәүләте төзелешенә җәлеп итү, алар арасында агигация-пропаганда эшләре алып бару хатын-кызлар бүлегенең төп хезмәт бурычларыннан саналган. Бүлеккә аның мөдире, инструктор, профсоюз, комсомол оешмасы, партия комитеты һәм «Кошчи» берлеге вәкилләре кергән. Хатын-кызлар бүлеге составында шулай ук төрле иҗтимагый оешмалар вәкилләре дә эшли, алар җәмгыяви йөкләмәләр үтәү, «Күчмә кызыл юрт»та гомуми җыелышлар уздыру, сезонлы эшләр оештыру өчен махсус берләшмәләр төзиләр. Алар ирләр арасында күпхатынлыкка каршы көрәшне пропагандалауда катнашалар, «Кошчи» берлеге әгъзалары арасында наданлыкны бетерү өчен көрәшәләр [Абдуллаева, б. 109].

Вәкаләтле хатын-кызлар дәүләт структурасында хезмәт кую белән бергә җәмәгать эшләрендә дә актив катнашалар. Алар Идел һәм Урал буе төбәкләреннән ачлыктан коткару өчен күчерелгән кешеләргә үзара ярдәм итү, шимбә өмәләре үткәрү, балалар йортлары һәм интернатлар эшләрен оештыру инициаторлары булалар. Бу чорда Яңа Бохарада беренче вәкаләтле хатын-кызлар сыйфатында нәкъ менә татар һәм рус хатын-кызлары эшли. М. Васильева, Макрюкова, М. Бабушкина һәм М. Шәрәфетдинованы шулар исәбенә кертергә мөмкин [Аминова, с. 120]. Алар югарыда санап үтелгән бурычлар белән беррәттән, яңа хакимияткә тугрылык һәм патриотлык хисе тәрбияләү, шулай ук җирле хатын-кызларны грамотасызлыкны бетерү курсларына һәм мәктәпләргә җәлеп итү белән шөгыльләнәләр [Нишонбоева, б. 72].

Төркестандагы хатын-кыз инструкторларның эшчәнлеген бәяләгәндә, Л. Шумилованың хезмәтен аерым билгеләп үтәргә кирәк. Мәсәлән, ул үзенең истәлекләрендә болай дип яза: «1919 елда Ташкент шәһәре партия оешмасына Үзәктән хатын-кызлар арасында эшләр башкару өчен махсус җаваплы кеше билгеләү турында боерык җибәрелә. Башта әлеге бурыч Якоменкога йөкләнде, ярдәмче итеп мине билгеләделәр. 1919 елда И. Финкельштейн җирле хатын-кызлар арасында митинглар үткәрде. Аларның берсендә миңа да чыгыш ясарга куштылар. Митингта 200 дән артык хатын-кыз катнашты, митинг тәмамлангач, мин тарихта һәм хәзерге заманда мәгърифәтчеләрнең роле һәм урыны турында әңгәмә үткәрдем» [За пять лет, с. 109]. Шуңа да карамастан, ир-ат инструкторлар җитәкчелеге пропаганда эшләрен тиз үстерергә мөмкинлек бирми. Соңрак, әлеге вазифага татар хатын-кызлары билгеләнгәннән соң, эш урыннан кузгала. Тел үзенчәлекләре, менталитет һәм гадәтләрнең охшашлыгы җирле хатын-кызлар белән якынаерга һәм эшләрнең нәтиҗәлелеген күтәрергә ярдәм итә.

Төркестан хатын-кызлары арасында пропаганда эше алып барган беренче вәкилләр, нигездә, татар һәм рус милләтеннән булган. Җирле халык телен белмәү соңгылары өчен аралашуда билгеле бер кыенлыклар тудыра. Иң беренче инструкторлардан булган Г. Марченко билгеләп үткәнчә, җирле халык арасында агитация эшләре уздыруда татар хатын-кызлары мөһим роль уйнаганнар. Мисал өчен, агитация группасында беренчеләрдән булып эшләгән татар кызы М. Йосыпова җирле хатын-кызларның хәлләре турында сөйләгәндә, аларның милли кыйммәтләрен, гореф-гадәтләрен тәфсилләп аңлата. Соңрак бу төркемгә татарлар – Хөсәнбаева, Ф. Редкина, Ш. Кәримова һәм башкалар кушыла [За пять лет, с. 118].

Төркестан фронты реввоенсоветы тарафыннан җибәрелгән кешеләр арасында татар хатын-кызлары да күп була. Шуларның берсе – Хәирова Шәмсеруха Имран кызы. Ул Казан губернасының Тәтеш шәһәрендә туган. 1920 елның гыйнварында большевикларның Казан губерна комитеты Шәмсеруханы Төркестан фронтына мобилизацияли. Ул башта фронтның сәяси идарәсендә эшли. Аннан соң

Ш.И. Хәированы Төрекмән атлы бригадасына җибәрәләр, ул анда политбүлек начальнигы була. Беркадәр вакыттан соң Сәмәрканд өлкәсе политбүлеге башлыгы ярдәмчесе итеп билгелиләр. Политбүлектә эшләгәндә, кызылармиячеләрне һәм командирларны сәяси яктан тәрбияләү аның бурычына кергән, Ш.И. Хәирова моны бик яхшы үтәгән.

1920 ел ахырында ТКП ҮК үтенече белән Ш.И. Хәированы политбүлектән алып, хатын-кызлар арасында эшләү өчен, Сәмәрканд өлкәсенә җибәрәләр. Тиздән эшкә сәләтен исәпкә алып, ул партиянең Сәмәрканд өлкә комитеты мөдире итеп билгеләнә. Сәмәрканд өлкәсендә төрле милләт вәкилләре яшәгәнлеген искә алсак, мондагы кыенлыкларны күз алдына китерү авыр түгел. Шуңа да карамастан, татар һәм таҗик телләрен белүче Ш.И. Хәирова хатын-кызларны берләштерә алган. Сәмәркандта эшләгәндә, Ш.И. Хәирова җирле халык, шул исәптән хатын-кызлар арасында да, агитация һәм пропаганда өлкәсендәге кимчелекләрне күрә. Агитация алып бару өчен өлкәдә матбугатның ролен күтәрү сорала. Ләкин полиграфия сәнәгатенең хәле бик начар булып, кадрлар җитешмәү аркасында, ул белгечләр һәм гарәп шрифтыннан файдалану мәсьәләсен хәл итү өчен Казанга җибәрүне сорап, Сәмәрканд өлкә комитетына һәм ТКП ҮКна мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр була. 1920 елның ноябрендә Ш.И. Хәирова ТКП Үзәк Комитеты мандаты белән Казанга килә һәм партиянең Татарстан өлкә комитеты ярдәмендә үзенә тапшырылган бурычларны үти.

Хатын-кызлар арасында актив эшләүче буларак, 1921 елда Ш.И. Хәирова ТКП ҮК каршындагы хатын-кызлар бүлегенә күчерелә, анда ул инструктор вазифаларын башкара. Аннары берничә айдан ТКП Үзәк Комитетында партия эшен алып бара, партиянең Сәмәрканд өлкә комитетында исәп-статистика бүлеге мөдире була. Дүрт ел Төркестанда булу дәверендә Ш.И. Хәирова, кайда гына эшләсә дә, анда яшәгән халыкларга ярдәм күрсәтү өчен бөтен көчен куйган. 1923 елда, К. Маркс исемендәге Халык хуҗалыгы институтының икътисад факультетында белем алган вакытта, ул Төркестанда эшләвен укуын тәмамлаганнан соң да дәвам итәргә теләве турында яза [Расулов, 1990, с. 210].

Җирле халык арасында агитация һәм пропаганда эшенә башкорт хатын-кызларының да үзләреннән зур өлеш кертүен билгеләп үтәргә кирәк. Алар үзбәк хатын-кызлары үткәргән төрле чараларда катнашалар. Җирле гореф-гадәтләрне өйрәнеп, алар бер үк вакытта совет идеологиясен пропагандалыйлар [Финкельштейн, Шукурова, с. 77]. Шуның белән яңа хакимият тарафдарлары санын арттырырга тырышалар.

Җирле хатын-кызлар арасында актив агитаторларның берсе булган Л.А. Отмарштейн, Бохарадагы татар хатын-кызларының пропаганда эшчәнлеген бәяләп, аларның җирле халыкның телен һәм гореф-гадәтләрен яхшы белүе уңышлы эшчәнлекне гарантияләвен билгели [Расулов, 1990, с. 221].

Соңрак хөкүмәт, татар хатын-кызлары алып барган агитация эшенең нәтиҗәлелеген аңлап, җирле хатын-кызлар арасында пропаганданы

дәвам итү инициативасын да алар кулына бирә. Әңгәмәләр вакытында алар җирле хатын-кызларга большевиклар сәясәтенең асылын төшендерәләр. Бу Нәманганда беренче хатын-кызлар комитетлары төзелүгә китерә. 1919 елның 21 июлендә бүлек тарафыннан үткәрелгән киңәшмәдә 200 гә якын җирле хатын-кыз катнаша. Утырышта чыгыш ясаган хатын-кызлар бүлеге хезмәткәрләре мөселманнарның мәгариф һәм мәдәният өлкәсендә Европа хатын-кызларыннан артта калуын билгеләп үтәләр [Хотин-киз дунёсида]. Докладлардан соң тыңлаучылар да сораулар бирә һәм чыгыш ясый ала. Башта чыгыш ясарга теләүчеләр булмый диярлек, аннары аларның саны шактый арта. Җыелышта дүрт әгъзадан торган коллегия оештырыла. Хатын-кызлар бүлеге рәисе итеп татар кызы Н. Огунова сайлана.

Җыелышта Төркестанның башка төбәкләрендә дә хатын-кызлар бүлекләре төзү турында карар кабул ителә. Моннан тыш, мөселман хатын-кызларга үзләренең иҗтимагый активлыгын көчәйтү һәм җәмгыятьтә лаеклы урын алу зарурлыгы ассызыклана [Хотин-киз дунёсида]. Мондый пропаганда эшчәнлегендә татар хатын-кызларының лидерлык итүе идарә итүче партия өчен отышлы була. Аларның тырышлыгы нәтиҗәсендә хатын-кызлар арасында яңа сәяси системаны пропагандалауның темплары һәм нәтиҗәлелеге арта. Шул сәбәпле совет власте аларның составын киңәйтергә тырыша.

Билгеле бер вакыттан соң, алдан ук көтелгәнчә, хатын-кызлар бүлеге хезмәткәрләренең саны арта. Соңыннан яңа эшче-дихкан бүлеге төзелә, аның каршында мөселман секциясе эшли. Башта секциянең эшенә татар кызы Мәрьям Бәхтиярова җитәкчелек итә. 1920 елның августында Татарстанның Спас районыннан Төркестанга ирле-хатынлы укытучылар – Д. Бәхтияров һәм М. Бәхтиярова җибәрелә. М. Бәхтиярова урта белемгә генә ия булуына карамастан, 1922–1925 елларда Иске Ташкент шәһәренең Мәдәният хезмәткәрләре берләшмәсенең идарә бүлеге сәркатибе булып эшли [ҮР МА, Р. 792 ф., 1 тасв., 47 сакл. бер., 175 кгз.]. Аннан соң Бәхтияровлар гаиләсе Фирганә өлкәсенә җибәрелә. Анда ире укытучы-оештыручы булып, ә Мәрьям Бәхтиярова өлкә хатын-кызлар бүлегендә эшли [Расулов, 2005, б. 307].

1919 елның ноябреннән җирле партия комитетлары каршында хатын-кызлар белән эшләү секцияләре оештырыла. Секцияләр эшен оештыру һәм җирле хатын-кызлар арасында төрле пропаганда ысулларын һәм идеяләрен эшләү процессында татар кызлары Заһидә Бурнашева белән Зөһрә Баембәтова зур энтузиазм күрсәтәләр [Биктемирова., Хамитбаева, 2001]. Аларның пропаганда эшчәнлеген генә түгел, кызлар мәктәпләре өчен беренче укытучылар әзерләүдә дә зур роль уйнауларын билгеләп үтәргә кирәк. Аерым алганда, З. Бурнашева җитәкчелегендә үзәк һәм җирле газеталарда хатын-кызлар өчен махсус бүлектә мәкаләләр басылып чыга [За пять лет, с. 122]. Аларда хатын-кызлар мәгарифенең торышы һәм пропаганда эшләре нәтиҗәләре турында мәгълүмат бастырыла.

Үзбәкстанда хатын-кызлар проблемаларын өйрәнгән Х.С. Шукурова хатын-кызлар бүлегенең тәүге эшләрен бәяләп, болай дип яза: «Хатын-кызлар бүлеге хезмәткәрләре, пәрәнҗә ябынып, шәһәр һәм авылларда, кунак сыйфатында, җирле хатын-кызлар белән аралашалар. Алар әңгәмә вакытында эшче һәм крестьяннар өчен совет власте тарафыннан тудырылган шартлар турында сөйлиләр, аңарга карата ихтирамны арттыралар. Пропагандистлар, беренче чиратта, җирле хатын-кызлар арасыннан үзләренә ярдәмчеләр әзерләү белән шөгыльләнәләр, чөнки алга таба аңлату эшендә аларның ярдәменә таянып була» [Шукурова, с. 124].

Әмма татар хатын-кызларының эше һәрвакытта да уңышлы гына бармый. Гасырлар дәвамында формалашкан җирле традицияләрдән баш тарту һәм яңа европача яшәү рәвешенә күчү Төркестан хатын-кызларыннан «батырлык» таләп итә. Шуңа күрә бу процесс зур кыенлыклар белән бара һәм корбаннар сорый. Мәсәлән, хатын-кызлар арасында пропаганда эше активистларының берсе, татар укытучысы Әминә Вәлиева истәлекләрендә болай дип яза: «Яңа хакимият агитаторларына дин әһелләре таш ыргытканнар, этләргә чыгарып ташлаганнар, үтергәннәр... 15 яшендә Чистай педагогика техникумын тәмамлаган 16 яшьлек татар укытучысы Җәмилә Юмаева Төркестанның Лагмон авылы мәктәбенә эшкә җибәрелгән була. Анда ул явызларча үтерелә» [Биктемирова, Хамитбаева, с. 4].

Беренче елларда Үзәк хатын-кызлар бүлеге мөселман секцияләренең эшчәнлеге әллә ни абруй казанмый, чөнки остаз хатын-кызлар бик аз була. Татар хатыны М. Сәфәрова мөселман секциясенә эшкә килгәннән соң, анда шактый җанлану күзәтелә. Аның җитәкчелегендә – «Ана йорты» һәм анда аналарны, балаларны яклау буенча җирле хатын-кызлар өчен курслар оештырыла [За пять лет, с. 122]. «Ана йорты»нда бала табу яшендәге хатын-кызларга кирәкле киңәшләр бирелә һәм медицина хезмәте күрсәтелә. Ул вакытта заманча медицина хезмәте күрсәтү бик актуаль була, чөнки җирле хатын-кызлар арасында үлем-китем очраклары еш күзәтелә.

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, шуны билгеләп үтәргә кирәк: татар хатын-кызларының мәгърифәтчелек эшчәнлеге совет чорында да дәвам итә. Ул бигрәк тә грамотасызлыкны бетерү буенча хатын-кызлар өчен курслар, мәктәпләр һәм клублар эшчәнлеген оештыруда чагылыш таба. Татар хатын-кызларының сәяси активлыгында агитация-пропаганда эшләренә аерым игътибар бирелә. Хатын-кызлар клублар эшен җитәкләгәндә, «Кызыл чәйханә» һәм «Кызыл почмак»лар ачуда башлап йөриләр. Моннан тыш, хатын-кызларны азатлыкка чыгару һәм аларны руслар белән беррәттән җитештерүгә тарту сәясәтен уңышлы тормышка ашыруда татар хатын-кызларының да роле зур була. Тел, мәдәният һәм гореф-гадәтләрнең бердәйлеге аркасында, алар җирле хатын-кызларның көндәлек тормыш-көнкүрешенә җиңел кереп китә алганнар.

**Әдәбият**

*Абдуллаева Я.* XIX аср охири ва XX асрда Қаракалпоғистонда хотин-қизлар масаласи (ижтимоий-сиёсий аспект): тарих фан. д-ры ... дис. Тошкент, 2005.

*Алимова Д.А.* Решение женского вопроса в Узбекистане. Ташкент: Фан, 1987. 68 с.

*Аминова Р.* Октябрь и решение женского вопроса в Узбекистане. Ташкент: Фан, 1975. 355 с.

*Биктемирова Т., Хамитбаева Н.* Татарки просветительницы. Актуальное национально-культурное обозрение «Анко». 2001 // URL: http: // www. tataroved. ru

*Гайнуллин М.* Татарская литература и публицистика начала XX века. Казань: Татар. кн. изд-во, 1966. 435 с.

За пять лет. Сборник по вопросам работы коммунистической партии среди женщин Средней Азии. М., 1925. XII, 188 с.

*Нишонбоева К.* Узбекистонда хотин-кизлар масаласини хал этишнинг маданий жихатлари (20–30 йиллар тажриба ва окибатлар): тарих фан. номз. ... дис. Тошкент, 1998.

Первый Туркестанский съезд // Известия. 1920. 6 апрель.

*Расулов А.Н.* Интернациональная помощь партийных организаций, трудящихся Средневолжского региона народам Туркестана (1918–1924 гг.): дис. ... канд. ист. наук. Казань, 1990.

*Расулов А.Н.* Туркистон ва Волгабуйи, Уралолди халклари уртасидаги муносабатлар тарихи (1917–1924 йй.): тарих фан. докт. ... дис. Тошкент, 2005.

Татар хатын-кызлнары хәрәкәте тарихыннан. Казан: Татар. кит. нәшр., 1971. 152 б.

Үзбәкстан Республикасы милли архивы (ҮР МА), 34 фонд, 1 тасв., 103 сакл. бер.

ҮР МА, 34 фонд, 1 тасв., 523 сакл. бер., 43–43 кгз. арты.

ҮР МА, Р. 792 фонд, 1 тасв., 47 сакл. бер., 175 кгз.

*Финкельштейн И., Шукурова Х.* Пробуждённые Великим Октябрем. Сборник очерков и воспоминаний. Ташкент: Госиздат, 1961.

Хотин-киз дунёсида // Иштирокиюн, 1919. 21 июл.

*Шукурова Х.С.* Социализм и женщина Узбекистана. Ташкент: Узбекистан, 1970. 367 с.: ил.

***Расулов Абдулла Нуритдин улы,***
*тарих фәннәре докторы, Нәманган дәүләт университеты профессоры*

***Насретдинова Дилфуза Мухаммадин кызы,***
*тарих фәннәре кандидаты, Нәманган инженер-технология институты доценты*

УДК 81'373(091)

*Л.Ф. Байбулатова*

# УРТА ГАСЫРЛАР ТӨРКИ КУЛЪЯЗМАЛАРЫНДА «ТАТАР» АТАМАСЫ
## («Тәварих-е гөзидә Носрәт-намә» әсәре буенча)

В данной статье рассматривается употребление термина «татар» в тюркоязычном сочинении XVI века «Таварих-е гузида Нусрат-наме». Это произведение посвящено правителю Бухарского ханства Мухаммеду Шейбани-хану, где помимо его жизнедеятельности дается история его предков Чингизидов, в рамках которой освещается история завоеваний, представлены родословные некоторых потомков Чингиз-хана. В сочинении даны разнообразные сведения о тюркских родо-племенных образованиях, в том числе о татарах. Этот термин употребляется в основном первой части сочинения, которая представляет собой перевод «Джами ат-таварих» Рашид ад-Дина. Однако в одном из списков «Таварих-е гузида Нусрат-наме», изданном И.Н. Березиным под названием «Шейбаниада», данный термин употребляется без привязки к сочинению Рашид ад-Дина и несет иную смысловую нагрузку.

**Ключевые слова:** татары, Таварих-е гузида Нусрат-наме, Рашид ад-Дин, Шейбаниада, И.Н.Березин.

This article examines the use of the term «Tatars» in the Turkic-language work «Tavarih-e guzida Nusrat-name» which was written in the 16th century. This work is dedicated to the ruler of the Bukhara Khanate, Muhammad Sheibani Khan, where in addition to his life, the history of his Genghisid ancestors is given, within which the history of conquests is highlighted, the genealogies of some descendants of Genghis Khan are presented. The essay provides a variety of information about the Turkic tribal formations including the Tatars. This term is used mainly in the first part of the work which is a translation of «Jami at-tawarih» by Rashid al-Din. However, in one of the lists of «Tavarih-e guzida Nusrat-name» published by I.N. Berezin under the title «Sheibaniad», this term is used without reference to the work of Rashid al-Din and carries a different semantic load.

**Keywords:** Tatars, Tavarikh-e Guzida Nusrat-name, Rashid ad-Din, Sheybaniada, I.N. Berezin.

«Тәварих-е гөзидә Носрәт-намә» – XVI гасыр башында төрки телдә язылган хезмәт. Бу әсәр Мөхәммәд Шәйбани хан кушуы буенча язылган һәм аның төп максаты әлеге ханның нәсел тарихын һәм батырлыкларын яктыртудан гыйбарәт. Урта гасырлар мөселман язма мирасында мондый алым әсәрдә яктыртылган шәхеснең тормышын, казанышларын, данлыклы бабаларын халык хәтерендә калдыру өчен еш кулланылган [Турсунов, б. 40–41].

Хәзерге вакытта бу әсәрнең автографы табылмаган, әмма берничә күчермәсе сакланган. Шуларның икесе – Лондон һәм Ленинград күчермәләре – иң тулылардан санала. Беренчесе – Британия китапханәсендә, икенчесе Россия Фәннәр Академиясенең Санкт-

Петербургтагы филиалында саклана. Лондон күчермәсе иң борынгылардан булып, аның күчерелү вакыты 1563 ел дип күрсәтелә. Шулай ук И.Н. Березин бастырып чыгарган «Шейбаниада» исемле хезмәтне дә телгә алырга кирәк. Бу әсәр «Тәварих-е гөзидә...»нең күчермәсе дип санала, ләкин югарыда искә алынган ике күчермәдән бик нык аерыла. И.Н. Березин сүзләренчә, күчерүчесе бу әсәрне «Шәйбанинамә» дип атаган һәм аның язылу вакыты XVI гасырның икенче чирегенә туры килә. Бу әсәр өч өлештән тора, беренче өлешендә Нух пәйгамбәрдән алып Чыңгызханның император булу вакытына кадәр булган вакыйгалар тасвирлана; икенче өлешендә күбрәк коңрат ыруы, бераз башка ырулар, Чыңгызхан нәселе, Әбелхәер хан шәҗәрәсе турында сүз бара. Ике өлеше дә Рәшидеддиннең «Җамигъ әт-тәварих» исемле хезмәтеннән тәрҗемә ителгән кисәкләрдән тора. Әмма рус галиме аңлатканча, «Шәйбанинамә»не язучы кеше Рәшидеддиннең әсәрен үзенчәлекле рәвештә кулланган. Мәсәлән, ул «Җамигъ әт-тәварих»тан үзенә кирәкле, күбрәк әкияти, тарихчылар игътибар итмәстәй мәгълүматны тәрҗемә иткән [Библиотека..., с. VIII–X]. Өченче өлешендә исә Мөхәммәд Шәйбани-ханның яулары тасвирлана һәм әсәр аның үлеме белән тәмамлана [Библиотека..., с. VII].

«Тәварих-е гөзидә...» әсәре галимнәр тарафыннан күпмедер дәрәҗәдә өйрәнелгән. Аңа багышланган төп хезмәт 1967 елда басылып чыккан һәм биредә әсәрнең факсимилесе, тәнкыйди тексты, Лондон һәм Санкт-Петербург күчермәләрендәге аерымлыклар бирелгән [Тäварих-и]. Бу китапның төзүчесе А. Акрамов беренче мәртәбә әлеге әсәрнең барлык күчермәләрен барлап, алар турында мәгълүмат бирә, «Тәварих-е гөзидә...»нең тарихчылар, телчеләр өчен әһәмиятле чыганак булуын ассызыклый.

«Тәварих-е гөзидә...» әсәрен галимнәр Фирганә тарихын, күчмә үзбәкләр дәүләтен, чыңгызыйлар шәҗәрәсен һәм аларның җир биләмәләрен, шулай ук әсәрнең дини тәшкилятен өйрәнгәндә чыганак буларак кулланганнар [Азимджанова, Ахмедов, Сабитов, Мустакимов, Маликов, Байбулатова]. Ләкин бу хезмәттә өйрәнеләсе юнәлешләр шактый күп әле.

Бу мәкаләдә «Тәварих-е гөзидә...» һәм И.Н. Березин бастырган «Шейбаниада» күчермәләрендә *татар* атамасының ничек кулланылуы турында сүз барыр.

*Татар* атамасы «Тәварих-е гөзидә...»дә беренче мәртәбә Огуз ханга багышланган бүлектә очрый. Бу бүлек тулысынча Рәшидеддиннең «Җамигъ әт-тәварих» хезмәтеннән тәрҗемә ителгән. Биредә татарлар Огуз ханга кардәш булмаган кабиләләр (илләр) арасында искә алына һәм аларның атамасы могул булуы күрсәтелә һәм аның килеп чыгышының билгесез булуы ассызыклана: *«Тәкый мондин үзгә илләрне Могул дирляр, аларның асылы мәгълүм ирмас икәндер, әмма Могул ичинда бер кыйсесе бер мәгыйн*[1] *ат табыб туруурлар, бу тәртиб бер-*

[1] Мәгыйн – аерым.

*лә җәлаир, сунит, татар, туалас...*» [Тәварих-е..., б. 5v]. «Тәварих-е гөзидә...» авторы Рәшидеддин мәгълүматын ни өчендер кыскартып бирә, чөнки «Җамигъ әт-тәварих»та татарларның Огуз ханның агалары – Оз хан, Күр хан һәм Гуз ханнан барлыкка килүләрен әйтә. Әмма алга таба «Тәварих-е гөзидә...» авторы, Рәшидеддингә ияреп, татарларны төрки кавем дип атый һәм аларның килеп чыгышын Нух улы Әбүлҗә белән бәйли: «*...бу төркиляр кем атлары бетелде Әбулҗә хандин туруглар*» [Тәварих-е..., б. 6r].

Әсәрдә татарлар турындагы бу мәгълүмат берничә тапкыр кабатлана, һәрвакыт татарның *могул* буларак билгеле булуын, әмма бу атаманың соңрак барлыкка килүен, ә *татар* атамасының *могулдан* борынгырак булуын әйтә. Автор фикеренчә, татарлар *могул* атамасын алганчы ук бик көчле халык саналганнар, Кытайда һәм Һиндстанда да төрки кавемнәрне татарлар дип йөрткәннәр, татарлар һәм башка төрки кавемнәрнең могул дип йөртелү сәбәбен аларның төрки тамырларыннан эзләргә кирәк: «*...вә үзгәләргә могул димәк ул җәһәтдин туруржун аларга йакын булур ирде бу могул төрк каумедин бер кавем ирде җун гыйнайәт эзли аларның хакыда бар ирде бу төрт йүз йылда алардин күб шахҗәләр пәйда булды үзгәрдин булар купалды вә ул төрк кавемләрене тәкый могул ди башладылар мондин бурун татар иле куәтлык иде барҗаны татар дир ирделяр һәнүз Хитайда вә Һиндда татар дирляр*» [Тәварих-е..., б. 7r].

Аерым бер бүлек татарларга багышланган. Биредә дә автор Рәшидеддин хезмәтеннән файдалана, ләкин аның тексты белән үзе теләгәнчә эш итә. Күпчелек мәгълүматны тәрҗемә итеп бирсә дә, кайбер өлешләр төшеп калган. Татарлар турында түбәндәге мәгълүмат теркәлгән: бу халык борынгы заманнардан ук билгеле, алар бик күп тармакларга аерылган һәм татар кавеме барлыгы 70 мең өйдән торган; алар Кытай падишаһларына салым түләгәннәр, әмма туктаусыз сугышып торганнар; татар хатын-кызлары да тәвәккәллек күрсәтеп, ирләре белән беррәттән кулларына пычак тотып көрәшкәннәр. Татарларның даны шулкадәр таралган булган ки, хәтта башка төрки кавемнәр дә үзләрен татар дип атаганнар. Шулай ук татарларның алты кавемнән торуы искә алына: *тутукулйут, әлчи-татар, чаган-татар, кумин-татар, берат-татар, беркуй-татар.* Тутукулйут арада иң зурысы саналган. Татарлар Чыңгызханга каршы торырлык бик батыр кавем итеп сурәтләнә. Хан аларның барысын да үтерергә боерса да, бер өлеше исән кала. Шуларның балалары киләчәктә зур дәрәҗәләргә ирешкәннәр. Гомумән алганда, бу хезмәттә Чыңгызхан һәм татарлар арасындагы мөнәсәбәтләргә зур урын бирелгән. Бер яктан, алар һәрвакыт сугышып торганнар, икенче яктан, хатынлыкка кызлар бирешеп аралашканнар [Тәварих-е..., б. 12r–14r]. Шулай ук бу бүлектә татарлар белән бәйле төрле вакыйгалар тасвирлана, алар барысы да Рәшидеддиннән алынган. «Тәварих-е гөзидә...» авторы тәрҗемә иткәндә кайбер урыннарны кыскартып бирә, әмма үзе теләгәнчә өстәмә мәгълүмат яки төзәтүләр кертергә җөрьәт итми.

И.Н. Березин чыгарган «Шейбаниада»да *татар* атамасы башка мәгънәгә ия. Беренче чиратта, Татар – кеше исеме. А. Акрамов сүзләренә караганда, И.Н. Березин әсәрне башка күчермәгә нигезләнеп эшләгән [Таварих-и..., с. 69], шуңа күрә биредә аерымлыклар булуы сизелә. А. Акрамов бу аерымлыкларны Мөхәммәд Шәйбани хан белән бәйле вакыйгалар уңаеннан билгеләгән, әмма аларны әсәрнең беренче өлешендә дә очратырга мөмкин. Югарыда әйтелгәнчә, «Шәйбанинамә»нең төзүчесе Рәшидеддин хезмәтендәге мифологик характердагы мәгълүматны файдаланган. И.Н. Березин басмасында Татар исемле кешенең Алиҗа хан улы булуы аңлатыла. Татарның Могул исемле игезәк туганы да булган. Алиҗа хан үзе исән вакытта үз хакимлегендәге барлык вилаятьләрне ике улы арасында бүлгән һәм алар, әтиләре үлгәч, бергә идарә итә башлаганнар [Библиотека..., с. XX].

Татар хан идарә иткән кавемгә аның исеме дә күчкән һәм аннан соң падишаһ булган ханнарның исемнәре түбәндәге тәртиптә бирелгән: Бука хан, Биләнҗә хан, Исли хан, Алтәстә хан, Үзид хан, Байду хан, Суйунуҗ хан. Татар кавеменең бетүе соңгы хан заманына туры килә, чөнки бу хан белән могул кавеме арасында низаг чыгып, сугыш башланган [Библиотека..., с. XX].

Алга таба *татар* атамасы кавем мәгънәсендә кулланыла һәм бу кавем белән бәйле төрле вакыйгалар сурәтләнә (мәсәлән, татарларның Тур бине Фәридун ягында моголлар белән сугышуы; булачак Чыңгызхан туган вакытта аның әтисе Исугайның татар кавеменә каршы чыгуы һәм алар падашаһы Тимучин Үгәне үтереп, милкен алуы) [Библиотека..., б. XXVI, XXXV].

*Татар* атамасы дигәндә, аның белән янәшә кулланылган төшенчәләрне да игътибарсыз калдырырга ярамый. Ике хезмәттә *татар* атамасы я *кавем*, я *ил* сүзе белән бергә кулланыла. Алар бер үк мәгънәгә ияме, әллә икесе ике төшенчәме? Мәсәлән, «Тәварих-е гөзидә...»дә болай диелгән: «*...төрк кавемләрене тәкый могул ди башладылар, мондин бурун татар иле куәтлек иде, барҗаны татар дир ирделяр*» [Тәварих-е..., б. 7г.], «*Татар кавеме кадимдин бире бу кавемнең аты мәшһүр турур, булардин күб шәгъбәләр пәйда булды*» [Тәварих-е..., б. 12г.]. «Шәйбанинамә»дә татарлар кавем буларак искә алына: «*Үзид хан татарлар кавеменә падишаһ булды*», «*татар кавеменең ахырын падишаһ вә хакиме Суйунуҗ хан турур*» [Библиотека..., б. 6].

Беренче карашка, *ил* һәм *кавем* төшенчәләре бер үк халык мәгънәсендә кулланыла. Шул ук вакытта *кавем* туганлыкны да аңлатырга мөмкин, ә *ил* сүзен хәзерге дәүләт мәгънәсен бирә дип әйтә алабыз. Әмма әлеге атамаларга хәзерге төшенчәләр аша карап булмый, шуңа күрә бу әсәрләрдәге *ил* сүзе дәүләт мәгънәсенә туры килми. *Ил* сүзенә килгәндә, Л.Будагов сүзлегендә аның Бабурда очрый торган мәгънәсе китерелә: ил күчмә кабиләне аңлата [Будагов..., б. 203]. Безнеңчә, бу әсәрләргә карата әлеге аңлатманы кулланып булмый, чөнки, мәсәлән,

«Шәйбанинамә»дә Татар белән Могул турында сүз барганда, аларның ил олысын сөеп, бергәләшеп падишаһлык итүләре әйтелә [Библиотека..., с. XX]. Димәк, *ил* төшенчәсе биредә берничә өлештән торган берләшмәне аңлата. Шулай итеп, кавем ил эчендәге халык булырга тиеш. Шул ук вакытта кавем берничә тармакка бүленергә мөмкин һәм, «Таварих-е гөзидә...»дә әйтелгәнчә, һәрбер тармакның һәм кабиләнең үз торган җире булган.

Йомгаклап әйткәндә, «Тәварих-е гөзидә Носрәт-намә» әсәре, аның барлык күчермәләре әлегәчә бай чыганак булып тора. Андагы мәгълүмат тарихчылар, телчеләр, әдәбиятчылар, дин белгечләре өчен аеруча кызыклы. Әсәрнең күчермәләрен өйрәнү, Рәшидеддин хезмәтенең тәрҗемәсен төп нөсхә белән чагыштыру барышында яңа кызыклы фактлар ачылырга мөмкин.

**Әдәбият**

*Азимджанова С.А.* К истории Ферганы второй половины XV в. Ташкент: Издательство Академии наук Узбекской ССР, 1957. 94 с.

*Ахмедов Б.А.* Государство кочевых узбеков. М.: Наука, 1965. 194 с.

*Байбулатова Л.Ф.* Отражение роли ислама в «Таварих-и гу-зида – Нусрат-наме» // Золотоордынское обозрение. 2022. Т. 10, № 3. С. 601–611. DOI: 10.22378/2313-6197.2022-10-3.601-611 EDN: BUQHYH

Библиотека восточных историков, издаваемая И. Березиным. Т. 1. Шейбаниада. Казань: типография Университета, 1849.

*Будагов Л.* Сравнительный словарь турецко-татарских наречий. Т.1. Санкт-Петербург,1869. 829 с.

*Маликов А.М., Торланбаева К.У.* Некоторые особенности культурной идентичности Шейбани-хана и монументальное строительство в Самарканде в начале XVI века // Золотоордынское обозрение. 2022. Т. 10, № 2. С. 391–413. DOI: 10.22378/2313-6197.2022-10-2.391-413.

*Мустакимов И.А.* Сведения «Таварих-и гузида – Нусрат-наме» о владениях некоторых джучидов // Тюркологический сборник 2009–2010: Тюркские народы Евразии в древности и средневековье /редкол.: С.Г. Кляшторный (пред.), Т.И. Султанов, В.В. Трепавлов. М., 2011. С. 228–248.

*Сабитов Ж.М.* Таварих-и гузида-йи нусрат нама как источник по генеалогии джучидов // Золотоордынская цивилизация. 2009. № 2. С. 108–116.

Таварих-и гузида – Нусрат-наме. Исследование, критический текст, аннотированное оглавление и таблица сводных оглавлений кандидата филологических наук А.М.Акрамова. Ташкент, 1967. 128 с.

Тәварих-е гөзидә Носрәт-намә. British library. Or.3222.

*Турсунов С.И.* Зерцало минувших столетий. Историческая книга в культуре Средней Азии XV–XIX вв. СПб.: Филологический факультет СПбГУ, 2005. 304 с.

***Байбулатова Лилия Фәрит кызы,***
*тарих фәннәре кандидаты, ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге*
*Тарих институтының өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 785.1(470.56)

***Э.М. Галимова***

# ОРЕНБУРГ ТАТАРЛАРЫНЫҢ БҮГЕНГЕ ЗАМАН ХАЛЫКЧАН ИНСТРУМЕНТАЛЬ СӘНГАТЕ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Данное исследование посвящается традиционной музыкальной культуре оренбургских татар. Автору статьи во время полевых исследований удалось зафиксировать наигрыши в исполнении на следующих инструментах: *хромка, саратовская гармонь, тульская гармонь, баян, тальянка*, которые по существу определили характерные особенности сложившихся традиций, как исполнительского стиля, так и жанрового контекста. В народной музыкальной традиции оренбургских татар наряду с песенным фольклором представлена также инструментальная музыка, но уже довольно в скромном бытовании. Автор отмечает, что на сегодняшний день не удалось зафиксировать музыкальные образцы и исполнителей на *скрипке, мандолине, курае и кубызе*.

**Ключевые слова:** оренбургские татары, традиционная музыкальная культура, инструментальная культура, инструментальные традиции, музыкальные инструменты.

This study is dedicated to the traditional musical culture of the Orenburg Tatars. During field research the author of the article managed to record the tunes performed on the following instruments: *khromka, Saratov accordion, Tula accordion, button accordion, talyanka,* which essentially determined the characteristic features of the established traditions, both the performing style and the genre context. In the folk musical tradition of the Orenburg Tatars along with song folklore instrumental music is also represented but already in a rather modest existence. The author notes that today it has not been possible to fix musical samples and performers on the *violin, mandolin, kurai and kubyz*.

**Keywords:** Orenburg Tatars, traditional musical culture, instrumental culture, instrumental traditions, musical instruments.

Бүгенге көндә фәндә традицион музыка мәдәниятенең һәм халык авыз иҗатының үсешен барлау аеруча игътибарга лаек. Әлеге мәкалә Оренбург өлкәсе инструменталь сәнгатенең жанр, көй яңгырашында этник үзенчәлекләрне билгеләүгә багышлана. Мисал итеп китереләчәк инструменталь көйләр, нигездә, 2015 елда Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан оештырылган комплексылы фәнни экспедиция вакытында язып алынды. Әлеге экспедиция материаллары, беренчел эшкәртелеп, китап булып чыктты[Милли мәдәни мирасыбыз..., 2016]. Оренбург – күп милләтле өлкә. Биредә руслар, татарлар, казакълар, башкортлар, мордвалар, чувашлар һәм башка милләт вәкилләре яши. Экспедиция төркеме Оренбург өлкәсендәге дүрт районның унбиш авылында фәнни тикшеренүләр алып баруны максат итеп куйды. Без Шарлык районының

Яңа Муса, Сарманай, Зирекле, Мостафа; Александр районының Солтанай, Тукай; Сакмар районының Татар Каргалысы; Саракташ районының Колчым, Чишмә, Кабан, Биктимир, Рәдүт, Әбләз һ.б. авылларында булып кайттык. Бу авылларда татар, башкорт, казакъ халыкларының көнкүреш-яшәешен һәм традицион музыка мәдəниятен өйрәнүне күздә тотып эш иттек. Экспедиция кысаларында барлыгы 267 көй һәм җыр яздырып алынды. Җитмеш өч информант белән әңгәмә корылды (аларның иң өлкән яшьтәгесе – 1925, ә иң яше 1977 елгы иде). Әлеге мәкалә бары тик инструменталь көйләрне барлау һәм аларга аналитик яктан аңлатма бирү максаты белән язылды.

Әйтергә кирәк, халык арасында аеруча киң таралган музыка уен кораллары арасында гармун (гармонь, гармоника) аеруча игътибарга лаек. Пневматик һәм ике клавиатуралы әлеге уен коралы төзелеше ягыннан үзенчәлекле булуы белән аерылып тора [Гайсин, 2012, с. 219–222]. Этноорганолог И. В. Мациевский фикере буенча да, гармун «Европа мәдәниятендә булган интеграция процессларына үз йогынтысын ясаган символ» буларак билгеле [Мациевский, 2000, с. 14–17]. Экспедиция кысаларында Саратов, Тула гармуннарында һәм шулай ук хромкада, баянда башкарылган бик күп үзенчәлекле инструменталь көйләр, авыл, бию көйләре яздырып алынды.

Гармун төзелеше ягыннан ике төргә бүленә:

1) гармун күреге йөреше тарафыннан төймәгә баскач, бер югарылыктагы аваз чыга;

2) гармун күреге йөреше тарафыннан төймәгә баскач, аваз югарылыгы үзгәрә.

«Ливенка», «Русская венка», «Хромка» гармуннарын беренче төргә кертеп була. Икенче төргә – «Тальян гармун» «Черепанка» «Тульская» «Вятская» гармуннары керә [Благодатов, 1960, с. 17]. Димәк, гармуннарны уң як клавиатура һәм төймәләрнең ничә рәттән торуына карап һәм үзенчәлекләренә нигезләнеп, төркемнәргә бүлеп була. Хәзерге заманда гармунчылар арасында сыздырып уйнап җибәрү өчен кулай иң популяр төр – ике рәтле хромка. Әлбәттә, өч рәтле уен кораллары да була һәм шулай ук бер генә рәт төймәдән торган гармуннар да бар. Гармунга халыкта барлыкка килгән уен коралларын ясаучы осталар тарафыннан да һәрдаим үзгәрешләр кертелә. Бу шулай ук һәрбер төбәкнең этнографик үзенчәлекләрен барлау нигезендә һәм җирле халык арасында киң таралган музыкаль мәдәниятенең күп кенә жанрларын үзенчәлекле башкару форматын саклап калу йөзеннән эшләнә [Ломако, 2005, с. 3].

Саратов гармунын башка төр бер генә гармун белән дә бутап булмый. Чөнки ул үтә яңгыравыклы һәм кабатланмас кыңгырау тавышына хас тембрга ия. Әлбәттә, әлеге үзенчәлек аның техник яктан төзелеше белән бәйле. Саратов гармунының өч металик телчегенә берьюлы басканда, нәкъ менә шундый бай яңгырашлы аваз чыга. Шулай ук төзелеше ягыннан караганда, аның свистковая планкасы бар, төймәләрнең яңгырашы бер октавага югары авазлар чыгару белән характерлана. Иң

мөһим үзенчәлек – кечкенә кыңгырауның сул якка беркетелүе – Саратов гармунын бай тембрлы уен кораллары рәтенә кертергә мөмкинлек бирә. [Благодатов, 1960, с.68]. Алда әйтеп үтелгән уен коралларын инструменталь көйләрне, биюләрне башкарганда да, җырлаганда кушылып җырлау, аккомпанемент ясау өчен дә файдаланалар. Җырчы җырлаганда да гармунчы көйне аның белән беррәттән уйнап бармый, ә вариацияләр белән баетырга тырыша. Ә менә гармунчының башкаручы буларак осталыгы бию көйләрен уйнаганда сынала: виртуозларча уйныймы, әллә сүлпәнрәк ритм калыпларыннан чыга алмыймы? Җырлар мәсьәләсенә килгәндә, гармун ярдәмендә башкарылган аккомпанемент «бас-аккорд» алымына корыла. Нигездә, гармунда башкарганда авыл көйләре, такмаклар, кыска көйләр һәм бию көйләре аеруча отышлы яңгыраш ала. М. Нигъмәтҗанов фикеренчә, гармунда бер генә тавыш рәтен кулланып уйнау (З. Сәйдәшеваның әлеге тавыш рәтен «керәшен тавыш рәте» дип билгеләвенә таянып [Сайдашева, 2003, с. 92]), шуңа өстәп, сул як аккордикасының тар күләмле булуы алдагы җанрларны башкаруга уңай йогынты ясый [Нигмедзянов, 2003, с. 94].

Экспедиция вакытында Оренбург өлкәсенең төрле авылларында яздырып алган уен көйләренең бүген дә популяр булуы һәм аларның, җыр җанры белән беррәттән, инструменталь вариантта да киң таралуы билгеле булды. Уен көйләре яшьләр җыела торган кичке уеннарның, төрле бәйрәмнәрнең музыкаль бизәге булып торган. Яз килүгә, яшьләр су буена төшеп, басмага басып, «Боз озату» бәйрәмен үткәргәннәр. Менә шул басмада, гармунчыга ияреп, такмаклар, кыска көйләр, авыл көйләрен башкарганнар һәм бию көенә рәхәтләнеп биегәннәр. Сабантуй бәйрәме алдыннан, *«Маевка»* һәм «Җыен» уздырганнар [Галимова, 2016, с. 246]. Әлеге бәйрәмнәрдә кыска көйләр, авыл көйләре, такмаклар һәм бию көйләренең аеруча киң таралган жанрлар булуын билгели алабыз. Ачык һавада, бик күп кешеләр катнашында яңгыраган уен көйләре аеруча популярлык казанган. Шулай ук әлеге уен көйләрен яшьләр, бергә җыелып, «кич утырганда» да башкарганнар. Җәен «кич утырулар»ны яшьләр су буена күчергәннәр, ә көз һәм кыш айларында, кемнең әти-әнисе өйдә юк, шуларда «аулак өй»гә җыелганнар. Кызлар кич утырганда кул эше белән шөгыльләнгәннәр, чигү чиккәннәр, бәйләгәннәр. Оренбург өлкәсе авылларында уен көйләре һәм җырларның күплеге безне гаҗәпкә калдырды, алар хәтта «озын көй», «авыл көйләре»н дә уздырып җибәрә. Шунысы бар: уен җырларын Оренбург татарлары бер-берсенә кунакка йөрешкәндә җырларга яратканнар. Мисалга Яңа Муса авылында гомер итүче Әбдершина Рушан Бари кызыннан (1940 елгы) яздырып алган төрле кызыклы уеннар исемлеген тәкъдим итә алабыз: «Зилем уены», «Йөзек салышлы», «Исем кушышлы», «Саңгырау телефон», «Дуадак уены», «Ярма яралы», «Үрдәккәем чумасың» һ. б. Шулай ук Зирекле авылында яшәүче Кәбирова Зара Заһретдин кызы (1932 елгы) безгә «Күмер салышлы», «Наза уены», «Тук-тук уены», «Чирта уены» хакында бик кызыклы мәгълүматлар бирде. Мостафа авылында яшәүче Саягфарова Сәбилә Гайсаян кызы

(1943 елгы) «Кристанце», «Чүрәкәй» уеннарының тәртибе белән таныштырды. Шулай ук Александр районының Султакай авылында безгә Агишева Галия Мөхәммәтҗан кызы (1945 елгы) «Күгәрчен ашату», «Кагыш-кагыш уены», «Ак тирәк уены» хакында сөйләде. Әлбәттә, әлеге уеннарда җыр һәм уен көйләре бергә үрелеп барган. Төзелеше буенча уен көйләре ике өлештән тора: башында салмак кына хор белән белән «запев» башкарыла, ә аннары бию көе тизлегендә такмак кебек өлеше дәвам итә. Уен көйләре гармунга кушылып башкарылса, тагы да отышлы килеп чыга. Гармунсыз башкарылган уен көйләре дә бихисап [Нигмедзянов, 1984, с. 20]. Шуны да әйтеп үтәргә кирәк: авыл җирендә яшәүче халык теләсә нинди көйне «авыл көе» дип атарга гадәтләнгән. Ә без бу өлкәдә авыл исеме белән бәйле «авыл көе»н яздырып алуга ирештек. Әлбәттә, авыл көйләре күмәк эш башкарганда, кунакка йөрешкәндә, туй мәҗлесләрендә һ.б. халык тарафыннан башкарылган. Менә шуларның кызыклы вариантларын – җыр һәм инструменталь җанр буларак сакланган авыл көйләрен – без Яңа Муса, Мостафа, Тукай, Чишмә авылларында яздырып алдык.

Шунысы әһәмиятле: җыр сәнгатендә сүз әйтелеше бик зур мәгънәгә ия. Чөнки көй төзелеше, ритм калыбы һәм җырның жанр буларак формалашуы нәкъ менә поэтик үзенчәлекләрдән тора. Ә менә инструменталь көйләргә килгәндә, алар башкаручының вариация ясарлык дәрәҗәдә уйнау сәләте һәм фантазия кулланып фикерләү мөмкинчелеге белән бәйле.

Кызганычка каршы, Оренбург өлкәсендә без скрипка һәм мандолинада уйнаучы этнофорлар очратмадык. Әлбәттә, алар һәрбер авылда булган һәм бик оста башкаручы булып танылган. Бүгенге көндә инде авылдашлары аларны бакыйлыкка күчкән талантлы музыкантлар буларак искә ала. Шулай ук без скрипка, мандолина, кубыз, курай кебек уен коралларында уйнаганны яздырып ала алмадык. Аларны берничә авыл музее экспозициясендә генә күрүгә ирештек.

Гомумән, бүгенге көндә авылда яшәүче урта яшьтәгеләрнең күбесе шул баян, гармун һәм хромка кебек уен коралларында гына уйный. Ә менә өлкән буын вәкилләре тальян гармунда, Саратов һәм Тула гармуннарында виртуозларча уйный белүләре белән Оренбург өлкәсенең горурлыгы булып торалар. Яшьләрнең тальян гармунда уйнарга өйрәнү теләге дә юк. Бу проблеманың нигезендә эстраданың йогынтысы зур булу ята. Һәм моны массакүләм чараларның яшь буынга милли йолаларыбызны, татар халкына хас музыка уен коралларының әһәмиятен аңлатмавы нәтиҗәсе дип тә карарга кирәк.

Һәрбер төбәкнең үз милли йолалары, гармунда көйне башкару ысуллары, җырларның тематик яктан төрлелеге – болар барысы да Оренбург өлкәсенең дә һәм анда гомер итүче татар халкының да традицион музыка мәдәнияте үзенчәлеген билгеләп торучы факторлар [Земцовский, 1987, с. 125]. Инструменталь сәнгатькә килгәндә, аның формалашуын һәм гасырлар дәвамында үзгәреш кичерүен җыр сәнгате белән бәйләдек. Чөнки экспедиция материаллары инструменталь һәм

җыр сәнгатьләренең аерылгысыз һәм бер-берсенә бәйле булуын тагын бер тапкыр исбатлады.

**Әдәбият**

*Благодатов Г.И.* Русская гармоника. Очерк истории инструмента и его роли в русской народной музыкальной культуре / ред. Ф.А. Рубцов. Л.: Музгиз, 1960. 182 с.

*Гайсин Г.А.* Гармоника в русской народной музыкальной культуре XIX века // Ярославский педагогический вестник, 2012. № 3. Т. I (Гуманитарные науки). С. 219–222.

*Галимова Э.М.* Традиционная музыкальная культура татар Оренбургской области // Милли-мәдәни мирасыбыз: Оренбург өлкәсе татарлары. Казан, 2016. Б. 241–263.

*Земцовский И.И.* Музыкальный инструмент и музыкальное мышление (к постановке вопроса) // Народные музыкальные инструменты и инструментальная музыка. Ч 1. М., 1987. С. 125–131.

*Мациевский И.В.* Основные проблемы и аспекты изучения народных музыкальных инструментов и инструментальной музыки // Народные музыкальные инструменты и инструментальная музыка: Сб. статей и материалов в двух частях. Часть первая / общ. ред. Е. Гиппиуса. М.: Сов. композитор, 1987. Ч. 1. С. 6–38.

*Мациевский И.В.* Гармоника в системе традиционной музыкальной культуры // Гармоника: история, теория, практика. Майков, 2000. С. 14–17.

Милли-мәдәни мирасыбыз: Оренбург өлкәсе татарлары. Казан, 2016. 360 б. (Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән, унөченче китап).

*Нигмедзянов М.Н.* Татарские народные песни. Казань: Татар. кн. изд-во, 1984. 240 с.

*Нигмедзянов М.Н.* Татарская народная музыка. Казань: Магариф, 2003. 255 с.

*Сайдашева З. Н.* Песенная культура татар Волго-Камья: Эволюция жанрово-стилевых норм в контексте национальной истории. Казань: Дом печати, 2002. 166 с.

*Ломако В.П.* Саратовские переборы // Репертуарный сборник пьес для ансамблей саратовксих гармоник: ноты, партитуры / Вступительное слово. Саратов: Саратовский областной центр народного творчества, 2005. 74 с.

*Страйнар Ю.* Несколько слов об изучении народных инструментов и инструментальной музыки // Народные музыкальные инструменты и инструментальная музыка. Ч. 1. М., 1987. С. 132–136.

***Галимова Эльмира Мөнир кызы,***
*сәнгать фәннәре кандидаты, Казан дәүләт мәдәният институтының театр, кино һәм телевидение факультеты деканы*

УДК 37.013

***Л.Г. Гыйләҗева,***
***Г.В. Һадиева***

## ЯҢАРТЫЛГАН ДӘҮЛӘТ БЕЛЕМ БИРҮ СТАНДАРТЫ ТАЛӘБЕ БУЛАРАК ЭМОЦИОНАЛЬ ИНТЕЛЛЕКТ

В статье рассматривается эмоциональный интеллект современного учителя как требование обновленного ФГОС ООО в условиях конкретизации формируемых метапредметных результатов учащихся. Указываются причины востребованности эмоционального интеллекта в современном образовании. Подчеркивается, как уровень эмоционального интеллекта влияет на процесс обучения и в повседневной жизни.

**Ключевые слова:** обновленный федеральный государственный стандарт, эмоциональный интеллект, гибкий навык, уровни эмоционального интеллекта.

The article considers the emotional intelligence of a modern teacher as a requirement of the updated Federal State Educational Standards in the context of specifying the formed meta-subject results of students. The reasons for the demand for emotional intelligence in modern education are indicated. It is emphasized how the level of emotional intelligence affects the learning process in everyday life.

**Keywords:** updated federal state standard, emotional intelligence, flexible skill, levels of emotional intelligence.

Россия Федерациясендә 2021 елның 31 маеннан № 287 боерык белән төп гомуми белем бирүнең Федераль дәүләт белем бирү стандарты гамәлгә кертелде [Приказ]. Шуның нәтиҗәсендә белем бирү системасына үзгәрешләр кертелә. Яңартылган стандарттагы үзгәрешләр шәхескә кагылышлы, метапредмет һәм предмет нәтиҗәләрен төгәлләштерү белән характерлана. Гамәлгә кергән яңалык мәктәптә барлык фәннәрне укытуга да кагыла. Шулай итеп, туган тел (татар теле) һәм татар әдәбияты предметларын укыту да яңартылган Федераль дәүләт белем бирү стандарты буенча оештырылырга тиеш.

Стандартта метапредмет нәтиҗәләре төгәлләштерелгән һәм бу өлештә яңалык буларак тәкъдим ителгән үзгәрешләр дә бар. Метапредмет нәтиҗәләренең регулятив уку гамәлләре өлкәсендәге яңалыгы эмоциональ интеллект төшенчәсе белән бәйле. Эмоциональ интеллект (инглиз теленнән *emotional intelligence*, *EI*) – башкаларның һәм үзеңнең эмоция, хис, мотивация һәм теләкләреңне тану, шулай ук, төрле мәсьәләләрне хәл итү максатыннан, хис-кичерешләр белән идарә итүгә бәйле күнекмәләр һәм осталыклар җыелмасы. Ул бүгенге заман педагогының профкомпетенцияләренә кергән креатив фикерләү белән беррәттән сыгылмалы күнекмәләр җыелмасын тәшкил итә.

Димәк, туган тел (татар теле) һәм татар әдәбияты дәресләрендә дә укытучыларның укучыларда эмоциональ интеллект формалашты-

руы – яңартылган стандарт таләбе. Ә укучыларда эмоциональ интеллект формалаштыру өчен укытучы үзе бу осталыкка, күнекмәгә ия булырга тиеш.

Педагогка эмоциональ интеллект ни өчен кирәк? Ул тормышта һәм эш процессында ничек ярдәм итә ала?

**Беренче сәбәп.** Эмоциональ интеллект ярдәмендә укытучы укучыларны танып белергә һәм үз хис-кичерешләрен контрольдә тотарга өйрәнәчәк.

Эмоциональ интеллект түбәндәгеләрне үз эченә ала:

– **үз-үзеңне танып белү** – үзеңне аңлый белү, хис-кичерешләреңне һәм тойгыларыңны аера белү;

– **үзконтроль** – максатларга ирешү өчен үз эмоцияләреең белән идарә итә белү;

– **эмпатия** – башкаларның хисләрен аңлау, аларны үзара хезмәттәшлектә исәпкә алу сәләте;

– **мөнәсәбәтләр белән идарә итү** – үз-үзеңне контрольдә тоту һәм эмпатия нигезендә үзара хезмәттәшлек максатларына ирешү сәләте [Кузнецова, б. 87].

Бу компонентлар билгеле бер тәртиптә урнашкан, үзара бәйләнгән һәм бер-берсеннән башка үсә алмыйлар. Хис-кичерешләреңне аңламый торып, аларны контрольдә тотып булмый. Шуңа күрә үзконтроль үз-үзеңне танып белүдән башка мөмкин түгел, чөнки, хис-кичерешләреңне белми торып, башкаларның хисләрен аңлап булмый. Үз-үзеңне контрольдә тотмыйча, эмпатия дә була алмый. Шунлыктан эмоциональ интеллект формалашу һәм аның үсеше һәрвакыт кешенең үз хис-кичерешләрен, эмоцияләрен танып белүдән башлана һәм мөнәсәбәтләр белән идарә итә белүгә таба юнәлә.

Мисал өчен үзконтроль компонентын дәрестә формалаштыру процессын карап узыйк. Бу компонент эмоцияләреең белән идарә итү һәм ышаныч, тугрылык һәм намус кебек сыйфатларны күз алдында тота. Әлеге эшчәнлектә беренче адым – үз хис-кичерешләреңне тану, чөнки белмәгән әйберне контрольдә тотып та, аның белән идарә итеп тә булмый. Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә, үзконтроль формалаштыру максатында, эмоцияләр көндәлеген алып баруны тәкъдим итәргә мөмкин. Бу эшчәнлекне татар әдәбияты дәресләрендә уку көндәлеге белән параллель дә гамәлгә ашырырга була. Теге яки бу әсәрне укыганда укучыларга үзләре кичергән хисләрне язып барырга тәкъдим итү отышлы. Мәсәлән, «Татар әдәбияты» дәреслегендә (авторы Ф. Хәсәнова, 5 нче сыйныф) [Татар әдәбияты, б. 31–38] урын алган «Үги кыз» әкияте укучыларда төрле хисләр уята: үги кызның гаиләсенә нәфрәт, кызны кызгану, аңа карап соклану һ.б. Укытучы дәрестә бу хис-кичерешләрнең барлыкка килү сәбәпләрен дә билгеләтә ала. Әлеге эш төре югары сыйныф укучыларында тагын да кызыграк хисләр тудырырга мөмкин.

5 нче сыйныфта татар әдәбияты дәресендә Г. Тукайның «Су анасы» [Татар әдәбияты, б. 61–65] әкиятен үткәндә дә, укучыларга

эмоцияләр көндәлеге белән эшләргә тәкъдим итәргә мөмкин. Эмоцияләрнең каршылыклы булуына игътибар итеп, аларда әлеге каршылыклы хисләрне уртага салып сөйләшү ихтыяҗы туачак. Алар, бер яктан, төп герой яклы, Су анасы аның артыннан йөгергәндә дә аларның эмпатиясе малай ягында, аның исән-сау өенә кайтып керүе укучыларда шатлык хисләре уятачак. Ә алга таба исә әни кешенең әлеге вазгыятькә мөнәсәбәте аша эмоцияләр үзгәрешен күзәтергә мөмкин.

6 нчы сыйныфта татар әдәбияты дәресендә Г. Исхакыйның «Кәҗүл читек» әсәрен [Татар әдәбияты, б. 35–39] өйрәнгәндә дә, төп геройның эмоцияләрен аңлау өчен, укучыларның үзләренең тормышларына күчереп параллель үткәрү уңышлы: «Үзегездә булдырырга теләгән бер кием, предметны көткәндә, аның турында хыяллангандагы халәтегезне искә төшерергез».

**Икенче сәбәп.** Эмоциональ интеллекты үсеш алган педагог укучыларны, ата-аналарны һәм хезмәттәшләрен яхшырак аңлаячак. Үсеш алган эмпатия әйләнә-тирәдәгеләрнең хис-кичерешләрен аңларга һәм анализларга ярдәм итә. Мәсәлән, эмоциональ интеллект ярдәмендә укытучы психологик дискомфорт туу сәбәпле түбән нәтиҗәләр күрсәткән укучыны аерып чыгара һәм сәбәпләрен ачыклый белә. Эмпатиясе булмаган педагог исә бу вазгыятьтә үзен яки укучыны уңышсызлыкта гаепләп, берьяклы гына эш итәчәк, бу исә укытучыга да, балага да файдага булмаячак.

Үсеш алган эмпатия һәм аның нәтиҗәсе – мөнәсәбәтләр белән идарә итү күнекмәсе – стресс халәтен йомшартырга һәм конфликтлар санын киметергә ярдәм итә. Дөрес мөнәсәбәтләр урнаштыра белгән укытучы ата-аналар басымы, укучылар агрессиясе һәм хезмәттәшләрен аңламау белән очрашмаячак. Димәк, үзенең психологик һәм физик ресурсларын бәхәсләргә түгел, ә эшкә юнәлтәчәк.

Башкаларның хис-кичерешләрен таныргa өйрәтү иҗади биремнәр нигезендә дә булырга мөмкин. Мәсәлән, татар теле дәресенең мотивлаштыру этабында укучыларга «эмоцияләрне фотога төшер» (сагыш, шатлык, бәхет, курку, гаҗәпләнү) дигән бирем тәкъдим ителә ала. Балаларга кеше фотоларыннан гына түгел, пейзаж, портрет һәм хәтта натюрморттан да хисне эзләргә өйрәтергә була.

**Өченче сәбәп.** Эмоциональ интеллект шәхси нәтиҗәләргә дә бәйле. Мәктәп укучылары ирешергә тиешле барлык шәхси нәтиҗәләр дә формалашкан эмоциональ интеллекттан башка мөмкин түгел.

Эмоциональ интеллект дәрәҗәсе тормышка җайлашырга да мөмкинлек бирә. Кешедә бу интеллект никадәр югары үсештә булса, тормыштагы ситуацияләрдә ориентлашу шулкадәр җиңелрәк булачак. Мәсәлән, пандемия вакытында дистанцион белем бирү тормыш чынбарлыгына әйләнде. Яңа практика кешеләрдә ситуациягә җайлашырга мәҗбүр итә торган эмоция һәм хисләр тудырды. Нәтиҗәдә, кешеләрдә ике билгеләнеш барлыкка килде: иррациональ – «бар да начар» һәм рациональ – «бар да башкача». Беренче билгеләнеш стресс халәте белән бәйле. Ул кешедә каршы тору позициясе уята, кешедән эмоция,

көч таләп итә. Болар барысы да – түбән эмоциональ интеллект билгесе. Әгәр дә кеше үзенең эмоцияләрен аңлап, алар белән эш итә белсә, бу хәлләргә җайлашу күпкә җиңелрәк булыр иде.

Сәламәтлек саклауга юнәлтелгән икенче билгеләнеш эмоциональ интеллект үсеш алган кешеләрдә чагылыш таба. Эмоцияләр һәм хисләрне контрольдә тоту, бөтен көчне проблеманы танып, аны хәл итү юлларын эзләүгә юнәлтелә. Яңа һәм авыр бурычларны чишүдәге уңышлар кешене илһамландыра, уңай эмоцияләр тудыра. Кеше яңа үзгәрешләргә тизрәк җайлаша һәм аларга йогынты ясау сәләтенә ия була.

Укучыларда эмоциональ интеллект формалаштыру эшчәнлеген нәрсәдән башлап җибәрергә соң? Эмоциональ интеллект формалаштыру өчен аның үсеш дәрәҗәсен билгеләү мөһим. Моны төрле онлайн тестлар яки маркерлы карточкалар ярдәмендә ачыкларга мөмкин. Мәсәлән, түбән дәрәҗәдәге эмоциональ интеллект маркеры эмоция һәм хисләреңне яшерү һәм басу нәтиҗәсендә барлыкка килгән агрессиядә чагыла: «Ул минем фикеремне кабул итмәде, алга таба сөйләшүне дәвам итүдә мәгънә юк». Урта дәрәҗәдәге эмоциональ интеллект маркеры конфликтлы булмау, җиңел аралашу һәм проблемаларны читләтеп узу белән характерлана: «Синең фикереңбелән тулысынча килешеп бетмим. Ярар, синеңчә булсын». Югары дәрәҗәдәге эмоциональ интеллект маркеры үзгәрешләргә бик тиз җайлашу, проблемаларда тукталып калмау, җаваплылыкны үз өстенә алу белән аерылып тора: «Мин мәсьәләнең бу ягын уйлап бетермәгәнмен икән. Әйе, болай да карап була икән».

Алга таба эмоциональ интеллект үсеше өчен нәрсә эшләргә кирәк, шул турыда аңлату эшләрен оештырырга, педагог-психолог белән тренинглар үткәрүне планлаштырырга кирәк. Федераль исемлеккә кертелгән яңа буын УМКлары да бу яңалыкны гамәлгә ашыруга юнәлтелгән. Дәреслекләрдә эмоциональ интеллект белән бәйле материаллар, алар нигезендә эшләнгән коммуникатив биремнәр укучыларда метапредмет нәтиҗәләрен формаштыруга җирлек булып тора. Мәсәлән, «Дәүләт теле буларак татар теле» предметын өйрәнүгә юнәлтелгән «Сәлам!» УМКсында (авторы Р.Ф. Бәхтиев, 9 нчы сыйныф) [Татар теле, б. 81–83] конфликтларны чишү, үзеңнең һәм башкаларның эмоцияләрен атау һәм аның сәбәпләрен ачыклауга караган биремнәр урын алган. Бер-ике биремгә тукталып китик:

1) Рәсемнәргә кара. Бу кем? Ул бу хәлдә нинди?

*Маша йодрык ясаган, ул ...*

*Тимур аякларын идәнгә бәрә, ул ...*

*Алсу иреннәрен тешли, ул ...*

*Руслан кул кушырып тора, аңа ...*

*Терәк сүзләр: борчулы, ачулы, күңелсез, түземсез.*

2) Укы. Син конфликт вакытында нишлисең?

*Конфликт – безнең тормышның бер өлеше. Ачулы булу – гадәти, табигый хәл. Сез үзегезне «кулга алырга» өйрәнергә тиешсез, чөн-*

*ки дуссыз калырга мөмкинсез. Конфликт вакытыныда, кайбер кешеләр кычкыралар, сугышалар, ә икенчеләре читтә калырга тырышалар.*

Эмоциональ интеллект күнекмәләрен формалаштыра торган биремнәрне туган тел (татар теле) һәм әдәбияты укытучысы үзе дә текстларга, әдәби әсәрләргә, тормыш ситуацияләренә нигезләнеп төзи һәм дәрестә куллана ала. Шул рәвешле ул укучыларда регулятив уку гамәлләре формалаштыра.

Эмоциональ интеллект автор әйтергә теләгән фикерне, әдәби әсәрне аңларга ярдәм итә. Укучыларның әдәби герой урынына үзләрен куеп карау, ягъни хис-кичерешләрне әдәби геройга вакытлыча күчү алымы ярдәмендә үткәрү яхшы нәтиҗә бирә. Бу вакытта теге яки бу персонажның «битлеген киеп караган» укучы, әдәби әсәр контексты кысаларыннан чыкмыйча, үзенең герое исеменнән хис-кичерешләренә таянып уйлый һәм җавап бирергә тырыша. Башта ул сурәтләгән персонаж балага битараф кебек тоелса да, ниндидер мизгелдә ул ирексездән аның хәленә керә, аның гамәлләрен аклый, сәбәпләрен ачыклый һәм ахырда аларны башка күзлектән чыгып аңлата башлый. Г. Ибраһимовның «Нәҗип» әсәрен анализлаганда, укучыларның «Нәҗип битлеген» киеп карау Нәҗипнең эш-гамәлләренең сәбәбен аңларга ярдәм итәчәк.

Укучыларга тормыш хис-кичерешләрсез була алмый һәм шуның белән ул кызыклы, дигән фикерне җиткерергә кирәк. Г. Ибраһимовның «Алмачуар» әсәрен генә мисалга алыйк. Әсәрне вакыйгалар эзлеклелегендә генә бирсәк тә, һәрбер вакыйга билгеле бер эмоция белән барганлыгын күрербез:

1. Колын туу – шатлык хисе.
2. Алмачуарның яралануы – борчылу хисе.
3. Закирның колынны сабанга җиктерүгә каршы төшүе – ярсу хисе.
4. Алмачуарны чабышка әзерләү – шатлык хисе.
5. Ярыш – өметләнү, курку хисе.
6. Староста белән бәрелешү – ачу килү, үпкә, ярсу хисе.
7. Алмачуарның үлеме – олы кайгы хисе.

Бүгенге заман белем бирү системасында укытучының эмоциональ интеллектка ия булуы, беренче чиратта, үзенең хис-кичерешләрен аңларга һәм аның белән идарә итәргә, укучыларның эмоцияләрен танып белергә, конфликтларны чишәргә һәм аралаша белергә ярдәм итә. Димәк, эмоциональ интеллект укытучының педагогик эшчәнлек нәтиҗәлелеген арттыруда әйдәп баручы рольне үти.

**Әдәбият**

*Кузнецова А.* Как объяснить педагогам, для чего нужен эмоциональный интеллект и мотивировать его развивать // Справочник заместителя директора школы. 2021. № 2. С. 82–88.

Приказ Министерства просвещения Российской Федерации от 31.05.2021 № 287 «Об утверждении федерального образовательного стандарта основного общего образования».

Татар әдәбияты: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек. 5 нче сыйныф. 1 нче кисәк / Ф.Ф. Хәсәнова, Г.М. Сафиуллина, М.Я. Гарифуллина. Казан: Мәгариф – Вакыт, 2017. 143 б.

Татар әдәбияты: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек. 6 нчы сыйныф. 1 нче кисәк / Ф.Ф. Хәсәнова, Г.М. Сафиуллина, М.Я. Гарифуллина. Казан: Мәгариф – Вакыт, 2017. 151 б.

Татар теле: 9 нчы сыйныф: рус телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен өйрәнүче укучылар өчен) 9 нчы сыйныф / Р.Ф. Бәхтиев һ.б. Казан: Мәгарифне үстерү институты, 2022. 112 б.

***Гыйләҗева Лилия Гыйльметдин кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Татарстан Республикасы*
*Мәгарифне үстерү институты доценты*

***Һадиева Гөлнара Васил кызы,***
*Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты*
*өлкән укытучысы*

УДК 82-95

# ФАТИХ ӘМИРХАННЫҢ «ӘЛИСЛАХ» ГАЗЕТАСЫНДА БАСЫЛГАН БАШ МӘКАЛӘЛӘРЕННӘН

Наследие и творчество Фатиха Амирхана (1886–1926) занимает особое место в истории татарской литературы. Его литературные и критические произведения печатались в газетах, журналах и отдельными книгами. Ф. Амирхан работал в различных редакциях газет и журналов, где активно печатался, таких как «Тарбият эл-атфаль», «Альислах», «Кояш», «Аң». В газете «Альислах» (1907–1909 гг.) писатель был фактическим редактором, перу которого принадлежат вводные статьи каждого номера выпусков газет. Вводные статьи представлены без подписи автора. В письме, адресованному Ризвану Алуши (от 25 ноября 1907 г.) он пишет о том, что вводные статьи и статьи под псевдонимом «Дамелла» принадлежат ему. В изданный в 1984–1986 годах четырехтомник «Сочинений» Фатиха Амирхана вошли не все вводные статьи. В данных статьях поднимаются вопросы реформирования обучения в медресе, составления единой программы образования, обучения женщин, расширение предметов обучения и т.д. Предлагаемые читателям вводные статьи печатаются на кириллице впервые.
**Ключевые слова:** татарская литература, Фатих Амирхан, критические статьи, образование.

The legacy and work of Fatih Amirkhan (1886–1926) has a special place in the history of Tatar literature. His literary and critical works were published in newspapers, magazines and books. F. Amirkhan worked in various editorial offices of newspapers and magazines, where he was actively published, such as «Tarbiyat el-atfal», «Alislah», «Koyash», «An». In the newspaper «Alislah» (1907–1909) the writer was the actual editor, who wrote the introductory articles of each issue of the newspapers. Introductory articles are presented without the signature of the author. In a letter addressed to Rizvan Alushi (November 25, 1907), he writes that introductory articles and articles under the pseudonym «Damella» belong to him. The four-volume «Works» of Fatih Amirkhan, published in 1984–1986, did not include all the introductory articles. These articles raise issues of reforming education in the madrasah, drawing up a unified education program, teaching women, expanding subjects of study, etc. The introductory articles offered to readers are printed in Cyrillic for the first time.
**Keywords:** Tatar literature, Fatih Amirkhan, critical articles, education.

*Татар әдәбияты классигы, танылган публицист Фатих Әмирхан (1886–1926) – татар халкының милли-мәдәни тормышында тирән эз калдырган шәхес. Язучының әдәби, тәнкыйди эшчәнлеге XX йөз башы газета-журнал редакцияләре белән тыгыз бәйле була. Ул «Әлислах», «Кояш», «Кызыл Армия» газеталарында, «Тәрбияи этфаль», «Ялт-йолт» журналларында языша. «Әлислах» газетасының оештыручысы һәм фактик редакторы буларак, һәр санда диярлек үз язмаларын*

*урнаштырып бара. Иң актив язышкан чоры 1907–1909 елларга туры килә. Аның шул чор татар җәмгыяте өчен актуаль темаларга язган мәкаләләрен төрле тәхәллүсләр белән дә, имзасыз да бастыруы инде мәгълүм. Мәсәлән, «Әлислах»та кереш мәкаләләрнең күбесе имзасыз басылган. Әлеге мәкаләләрнең анықы булуы шик уятмый. 1907 елның 25 ноябрендә дусты Р. Алушига язган хатында ул: ««Әлислах» сезгә барып ирешкән булса, баш мәкаләләр вә «Дамелла» имзалы мәкаләләрне аяксыз дустым Фатих кулы белән язылган дип укырсың!» – дип яза. Ф. Әмирханның 1984–1986 елларда нәшер ителгән дүрт томлы «Әсәрләр»енә кереш мәкаләләрнең барысы да кертелмәгән. Әлеге мәкаләләр үзләренең тематикасы, XX йөз башы милли хәяты өчен җитди мәсьәләләрне күтәрүе белән кыйммәтле. Язучы иҗатының башлангыч чорында (1906–1912) гарәп-фарсы алынмаларының күп кулланылуы күзәтелә. Түбәндәге мәкаләләр текстологик яктан эшкәртелеп һәм астөшермәләр белән тулыландырылып, укучыга беренче тапкыр тәкъдим ителә.*

## Казан, 25 октябрь

Ысулы җәдидәнең көннән-көн интишары[1] күптән татар милләте каршысына ысулы тәгълимнән хәбәрдар мөгаллимнәр кирәклеге мәсьәләсен чыгарган һәм ул мөгаллимнәрнең җитешмәве мәсьәләсендә бик гүзәл сурәттә аңлаткан иде. Бик фәкыйрь генә авыл халкының үзләренең актык кисәкләреннән сындырып мөгаллимгә өлеш чыгарганлыгыны, үз кесәсеннән мәктәп тәрбия итә торган, кешеләрнең хөкүмәт мәктәпләреннән мөкәммәлрәк тәрбия күреп чыккан һәм хөкүмәттән вазифа ала торган мөгаллимнәргә караганда күбрәк вазифа тәгъйин итеп[2], мөгаллимнәр җәлеп итәргә мәҗбүр булуларыны уйласак, хәзер дә халкымызның мөгаллимнәргә ихтыяҗыны ни дәрәҗә хис итә башлаганлыкларыны вә мөгаллимнәр җитештерү мәсьәләсенең ни дәрәҗәдә бер дәкыйкадә кичектерүне тәҗвиз итми торган[3] мәсьәлә икәнлегене ачык сурәттә күрергә мәҗбүрмез. Әгәр моның өстенә күз алдымыздагы 3 нче Думага хөкүмәт тарафыннан гарыз ителәчәк[4] гомуми мәҗбүри тәгълиме ибтидаи ляихәсене дә игътибарга алсак, мөгаллимнәр җитештерү мәсьәләсе хәятымызның иң әһәмиятле вә бәлки сәяси ноктадан да бер дә акрынлап торуны күтәрәчәк түгел икәненә тәмамән канәгать хасил итми хәлемез юктыр.

Хәзер әле алты-җиде авылга бер тәртипле мәктәп булып торганда мөгаллимнәремез җитешми. Әгәр дә тәгълиме ибтидаи тәгъмим[5] вә мәҗбүри ителсә, хәзерге ихтыяҗ 6–7 мәртәбә куәтләнәчәктер.

---

[1] Интишары – таралуы.

[2] Тәгъйин итеп – билгеләп.

[3] Тәҗвиз итми торган – хупланмый торган.

[4] Гарыз ителәчәк – тәкъдим ителәчәк.

[5] Тәгъмим – барлык җиргә кертү.

Гәзитә укыганнарга мәгълүм: рус милләтенең шулкадәр күп дарел-мөгаллиминнәре булу өстенә дә, хөкүмәтнең хисабы буенча тәгълиме ибтидаи мәҗбүри ителсә, ул мөгаллимнәрнең гадәдләре[1] җитәрлек түгел, шуңар күрә дә кечерәк дәрәҗәле мөгаллимнәрнең хак вә праваларыны арттырырга мәҗбүрият хис ителәчәктер.

Әгәр дә 3 нче Дума тәгълиме ибтидаине мәҗбүри ясап, тиз көннән гамәлгә дә куелуын таләп итсә, татар милләте мөгаллимнәр кайдан алачактыр?

Мөгаллимнәр җитешмәве сәбәпле, күп җирләрдә татар мәктәпләре ачыла алмагач, алар урынына билмәҗбүрият[2] рус мәктәпләре ачылырга тиеш булып килмәс микән?

Җитешкән мөгаллимнәрдән дә бер дәрәҗә мәгълүмат таләп ителенә башласа (табигый, нинди тугры килсә, шундый мөгаллим насыйп иткән мәктәпләр, тәгълим мәҗбүри кагыйдәсен җиренә китерә алачак түгел), ничек итеп шул көнне генә ул мөгаллимнәргә кирәк дәрәҗә тәрбия вә мәгълүмат бирерлек икән?

Вә билахирәдә[3], боларның һәммәсеннән катгы назар[4] кылганда да, күпмегә кадәр бу хәзерлексез мөгаллимнәр белән генә иктифа ителеп[5], бөтен татар балалары яхшырак тәрбия күргән мөгаллимнәргә шәкерт булудан мәхрүм булып көн итәргә мәхкүмнәр икән?

Менә бу сөальләргә җаваплар бу көннән бирелергә тиештер. Бу мәсьәлә милләтемезнең мәгарифе мәсьәләсе белән иштигаль итә[6] торган һәр зат тарафыннан күз алдында тотылырга тиештер. Безнең акрын гына барасымыз килер-килмәс кенә баруымызны заман көтмәячәк, вә шул көе дәвам итсәк, безнең киләчәгемез өчен авыр гакыйбәтле[7] нәрсәләрне безнең өстемезгә ыргытачак икәнендә шөбһә итәргә урын юктыр. Чөнки моңар кадәр безнең белән заман шулай мөгамәлә иткән, тәкъдир безнең белән шулай уйнаган, безнең гафләтемезне, хәзерләнә дә башламаган икәнчелекемезне, хәзрәтләремезнең әле бәлештән бушый алмаганлыкларыны, Бохараи Шәриф безгә андый тәгълимат бирмәгәнлекене заман гозер санамаган һәм, бер дә кызганмыйча, кылган гөнаһларымызның җәзасын өстемезгә җаудыра килгән.

Үткән җәйдә Казан муллаларының бер сыйныфы җәйлек кенә булса да, бер дарелмөгаллимин ачып караганнар иде һәм ачылган көне белән Русиянең һәр тарафыннан шәкертләр дә килеп тулганнар иде. Ләкин ... милләтемезнең тәрәккый вә тәгалисенә[8] дошман «чын татар»ларымыз («чын руслар» дигән кеби моннан соң ул мөбарәклә-

[1] Гадәдләре – саннары.
[2] Билмәҗбүрият – көчләнеп, ихтыярсызлык белән.
[3] Билахирәдә – ахырда.
[4] Катгы назар – карамастан.
[5] Иктифа ителеп – канәгатьләнеп.
[6] Иштигаль итә – шөгыльләнә.
[7] Гакыйбәтле – нәтиҗәле, ахыры.
[8] Тәгалисенә – күтәрелешенә.

не без «чын татарлар» дип йөртәчәкмез) үзләренең күптән бирле мөлкә итеп килә торган эшләре донос белән яптырдылар. Чын татарлар яшьләремезгә аз булса да файда итәрлек бер нәрсәнең арамызда торуына эчләре пошты, губернатор химаясенә чаптылар, төрле ялганнар белән максудларына да җиттеләр: шәкертләрне таратып, бинасын бикләтеп куелды. Әлбәттә, бу дарелмөгаллимин бик накыйс[1] булачак иде, ләкин ничек булса да бар иде.

Бервакыт өчен ул да файда китерә алачак иде. Дарелмөгаллимин мөдирләреннән мулла Салихҗан әл-Баруди программага «Сөбател-гаҗизин» дә кертергә кирәк дигән шикелле көлке гарызлары, үз мәдрәсәсендә ятып эшкә яраклары беткән шәхесләрне мөгаллим насыйп итәргә тырышуы, вә бәгъзеләрендә билфигыль[2] насыйп итүе һәм шул ук үз мәдрәсәсе җимеше булган тәгълим, тәрбия вә әхлактан хәбәрсез бер шәхесне тәрк[3] полиция вә хәфийясе[4] хезмәтене итәргә тәгъйин итүе белән, әгәр дарелмөгаллимин дәвам итсә, тәрәккыенә шактый манигъ[5] булачак икәнене күрсәтергә өлгерсә дә, башка мөтәрәккыйрәк әгъзаларның мөдахәләсе[6] белән бу сүи истигъмальләр[7] бетәр дип өмид итәргә мөмкин иде. Ләкин ни чара, әүвәлдә әйткәнемезчә, безгә тәкъдир көлеп карамый.

Үткән эшкә салават, диләр. Ул ябылды, бетте, безгә хәзергесен кайгыртырга кирәк. Үсә торган яшь балаларымызның истикъбальләрен аз гына кайгыртсак та, иң әүвәл күз алдымызга мөгаллимнәр җитештерү, аларга балаларымызны хәятка мөстәгыйдрәк[8] итеп чыгарырлык тәрбия бирүнең әһәмияте күз алдымызга килергә тиештер. Күрше милләтләремездән русларның дарелмөгаллиминнәренә генә карасак та, мөгаллимнәр тәрбиясенә никадәр әһәмият биргәнлекләрене вә шул ибтидаи мәктәп мөгаллиме булачак кешеләргә, никадәр мәгълүматны лязим күреп, шуннан башка мөгаллимлек хакыны бирмәгәнлекләрене күрәмез, нәмунә итеп[9] Татарская учительская школаны алсак: рус теле, әдәбияты, җәгърафия, тарих, хисап кәсер[10] белән һәндәсә, гыйльме әшья, педагогиядән бер дәрәҗә яхшы мәгълүмат биргәнлегене һәм дүрт ел вакыт эчендә бер дә русча белми торган татар баласын ибтидаи рус теле мөгаллиме ясап чыгарганлыгыны күрәмез. Безгә дә әгәр башка мөтәрәккый милләтләргә балалары кадерле булган шикелле, үз балаларымыз кадерле булсалар, әгәр дә без дә аларның балаларына теләгән тәрбиясене вә мәгълүматлы

[1] Накыйс – ким.
[2] Билфигыль – чынлыкта.
[3] Тәрк – ташлау.
[4] Хәфийясе – яшерен полиция кешесе.
[5] Манигъ – киртә.
[6] Мөдахәләсе – кушылуы.
[7] Сүәи истигъмальләр – урынсыз кулланулар.
[8] Мөстәгыйдрәк – әзер булып торучы.
[9] Нәмунә итеп – үрнәк итеп.
[10] Кәсер – вакланма.

булуларыны теләсәк, шул халыкларның ничә еллар тәҗрибә белән ирешкән нәрсәләреннән файдаланырга вә никадәр мәшәкать вә хезмәт белән ирешкән нәрсәләреннән гыйбрәт алырга тиешле буладыр.

Моңар кадәр бушка уздырган вакытларымызда, нәтиҗәсезгә күргән мәшкъләремез[1] дә җитәр инде. Хәзер тәгълим юлларымызда булган ноксанатны[2] аңлагач та, ислахның ярым юлында туктап, катып калмак гафу кылынырлык гөнаһ булмас. Шуңар күрә бу көннән башлап, мөгаллимнәр тәрбиясе кайгысына төшү, бер дәкыйка фәүт иттермичә[3], бөтен Волга буена бер-ике генә булса да дарелмөгаллимин ачу милләтемезнең мәгарифтә тәрәккый нәзарыннан фарыздыр.

Бу дарелмөгаллиминнең, әлбәттә, берсе вә әүвәлгесе Казанда ачылырга тиештер, чөнки Казанның кувәи маддия вә мәгънәвиясе дә хәзер бер тәртипле дарелмөгаллимин тәрбиясенә генә җитәрлек вә шуңар истигъдад[4] хасил итеп җиткәндер: эшкә яраксыз, дарелфөнун исеме золмәт[5] сачеп тора торган мәдрәсәләрдән берсенең бинасы бу елга ике әүвәлге сыйныф өчен җитәчәктер.

Шәһәремездә ике әүвәлге сыйныфка голүме хәятия тәдрис итеп торырлык яшьләрне дә табуы мөшкил булачак түгел, бәлки аларның һәркайсысы бу эшкә күңелләре белән шад булганга, һәрвакыт ихлас белән хезмәт итәчәкләрдер. Әлхасыйль, аз гына бер һиммәт вә иҗтиһад белән бер-ике мең сум матди иганә белән дарелмөгаллиминне башлап җибәрергә бик мөмкиндер. Фәкать эш башында иҗтиһадлы вә әһеле улган кешеләрнең торуы гына шарттыр. Хөкүмәттән рөхсәт алу тугрысында да ул кадәр мәшәкатьләнергә тиеш булмас. Зыялыларымыздан бәгъзесенең мәктәпләр ачу правасына малик булуыннан истифадә итәргә[6] мөмкин булыр.

Әлхасыйль, чынлап теләргә вә касдына[7] төшәргә кирәк. Бик тиз вакытта милләтемезнең шулкадәр мохтаҗ булган дарелмөгаллиминенә әсас (фонд) салынган булыр. Ноксаннарын[8] заман вә тәҗрибә төзәтер, шулай итеп, бер адым булса да алга киткән булырмыз.

Татар милләте үзенең мәгариф эшен үзе илтә алудан гаҗизлек күрсәтерлек бер гайрәтсез милләт түгел!

*(«Әлислах», 1907, № 4, 25 октябрь)*

---

[1] Мәшкъләремез – укуларымыз.
[2] Ноксанатны – җитешсезлекләрне.
[3] Фәүт иттермичә – уздырмыйча.
[4] Истигъдад – сәләтлелек.
[5] Золмәт – караңгылык.
[6] Истифадә итәргә – файдаланырга.
[7] Касдына – максатына.
[8] Ноксаннарын – җитешсезлекләрен.

## Казан, 12 ноябрь

Коруне уля вә вөста[1] тарихларына мөтталигъ улан[2] һәркемгә мәгълүм: бәни адәмнең[3] мәгыйшәте, гакылы һәм тәҗрибәсе баланың анадан туып үсүе вә кәмаләткә[4] ирешүе шикелле үк туган, үскән вә акрынлап кәмаләткә таба сәер итәдер[5]. Бәни адәм гыйлемсез вә тәҗрибәсез көе җир йөзенә чыгып та, мәгыйшәтнең кысуы вә өйрәтүе сәбәпле, үзенә кирәкле нәрсәләрне белә башлаган, алар хакында тәҗрибәләр кылган вә аларны, үзе дә белмичә, кәмаләткә таба сәвекъ кыла[6] башлаган һәм хәзер дә сәвекъ кылып барадыр. Хәзердә тәкмил ителеп,[7] кагыйдәләре бәдаһәт[8] дәрәҗәсенә китерелгән фәннәрне карасак, аларның моннан өч-дүрт, хәтта ике-өч мең ел элек тә вакты сабавәттә[9] булган икәнлекләрене вә фәкать бик күп гакыллар вә бик күп тәҗрибәләрнең хезмәтләре соңында гына бу кәмаләткә ирешкән икәнлекләрене күрәмез. Бу тәрәккыйләр белән бергә бәни бәшәрнең[10] гакылы да вә мәгыйшәткә булган нәзары да бик зур адымнар белән тәрәккый итеп, күптән түгел генә колларга малик булуга бераү дә гаҗәпләнми горфи[11] бер эш дип кенә карасалар да, хәзерге гакыллар вә хәзерге фикерләр бәни адәмне мәмлүк булыр өчен түгел, бәлки хөррият вә мәсгудият өчен дөньяга чыккан нәрсәләр дип карап, коллар милекләүгә бер вәхшәт дип карый башладылар. Күптән түгел генә хатыннарга накыйсәт[12] дип карау бик мәкъбүл булса да, хәзерге гакыл вә фикерләр аларның ирләр шикелле үк икәнене тасдыйк итteләр. Күптән түгел генә бәни адәм дөньяда фәкать мәшәкать чигәргә кирәк дип уйлап, үзенә дә, кешегә дә файдасы тими торган көлфәтләрне[13] өстенә йөкләүчеләрне мөкаддәс вә заһид дип атасалар да, хәзерге гакыл вә фикерләр аларны мөтәкәллиф[14] вә яңлышкан кешеләр дип атый башладылар. Боларны фәкать бер мисал итеп китерәмез. Әлхасыйль, әүвәлдә могтәбәр саналган эшләрнең күбесе ул игътибарларын җуялтып, алар урынына яңа фикер вә яңа уйлар чыгып, бәни адәмнең гакылы вә мәгыйшәте тигезлек, кардәшлек вә сәгадәте гомумия дигән нәрсәләргә таба сәер итәдер. Моннан йөз ел элек фәннәр

---

[1] Коруне уля вә вөста – борынгы заман һәм Урта гасырлар.
[2] Мөтталигъ улан – белгән.
[3] Бәни адәмнең – адәм балаларының.
[4] Кәмаләткә – өлгергәнлеккә.
[5] Сәер итәдер – барадыр.
[6] Сәвекъ кыла – алга этәрә, юнәлтә.
[7] Тәкмил ителеп – җитешеп.
[8] Бәдаһәт – ачыклык, билгеле булу.
[9] Вакты сабавәттә – балалык вакытында.
[10] Бәни бәшәрнең – адәм балаларының.
[11] Горфи – гадәттәгечә.
[12] Накыйсәт – ким.
[13] Көлфәтләрне – хезмәтләрне.
[14] Мөтәкәллиф – кирәксезгә үз өстенә авыр йөк алучы.

вә әфкяре гомумия бер дәрәҗәдә булса да, аларның тәкмиле[1] юлында йөз төрле күп гакыл вә тәҗрибәләр хезмәт иттекеннән бу көндә алар әллә никадәр алга киткәннәр вә әллә никадәр тәкмил иткәннәр. Моннан берничә гасырлар әүвәл бер кагыйдәләрне бер нәрсә исбатына истигъмаль итсәләр[2], бу көн шул ук кагыйдәләрне тәкмил итеп, бөтенләй аңар мохалиф нәрсә исбатына истигъмаль ителәдер. (Мисал уларак бу номер вә газетамызда «Җәүһәр Фәрд» мәкаләсене дәрҗ иттек[3].) Менә бу үзгәрүләр, бу тәрәккыйләр, шөбһәсез, татар мәгыйшәте өчен дә тәэсирсез калырга мөмкин түгелдер, бөтен галәм-җирне сәйярә[4] дип исбат иткәндә, аның үгез мөгезендә торганлыгыны дәгъва итү ничек бер сәфаһәттән[5] гыйбарәт булса, яңа фикерләргә вә яңа мәгыйшәткә каршы тору вә аны белергә теләмәү дә шулай ук сәфаһәт вә гакылсызлыктан башка нәрсә түгелдер. Шуңар күрә дә алты гасыр моннан әүвәлдә булган әфкяр вә фөнүнне хәзергә кадәр кыл хәтле дә үзгәртми саклап килгән мәдрәсәләремезне дә мәңге ул көйгә калдыру мөмкин түгел, аларга тәкмил ителгән вә яңартылган фәннәр вә фикерләр кертергә вакыт вә аларның шәкертләрен дә моннан алты йөз ел әүвәлге вакытта түгел – менә шушы көндә – XX гасырда торырлык кешеләр иттереп чыгарырга вакыттыр.

Бөтен галәмне тимер юллар чолгап алганда тәвә белән сәфәр хөкемнәрен[6] өйрәнүне бөтен сәясәт галәмен дер селкеткән җир мәсьәләсендә (Аграр. воп.) зәмиләрдән[7] күпме хәраҗәт[8] алыначагыны, сәүдә вә һөнәрләр бөтенләй икенче тарыз[9] алганда – тәвә хисабыннан зәкят бирүне, сәйярәләрне вә аларның хәрәкәтләрен күз белән тамаша итеп була торган гасырда – алты йолдыз 4 нче кат күккә беркетелеп куелганны сөйләгән һәйәт китапларыны өйрәнүне ташлап, заман мәгыйшәт вә хәлемезгә тиеш нәрсәләрне өйрәнергә вакыттыр. Бөтен зыялы милләтләр мәгыйшәт хазирәгә мөстәгыйд[10] руханилар житештергәндә, ул руханилар заманнан бөтенләй хәбәрдар булып, диннән теләгәннәре мәсләктә вә мәгыйшәт файдасына истифадәгә моктәдир[11] булганда, безнең руханиларымызның гына надан вә заманнан хәбәрсез булып, безнең тәрәккыемезгә манигъ булып, юлымызны сәд[12] кылып торырлык кына булулары – милләтемез өчен ят вә гафу ителмәслек гөнаһтыр. Безнең белән бер йыл вә бер үк әхва-

[1] Тәкмиле – җитешү, җитештерү.
[2] Истигъмаль итсәләр – файдалансалар.
[3] «Әлислах»ның шушы ук санында Ризаэтдин бине Фәхретдин тарафыннан басылган «Җәүһәр Фәрд» мәкаләсе хакында сүз.
[4] Сәйярә – планета.
[5] Сәфаһәттән – начарлыктан, бозыклыктан.
[6] Хөкемнәрен – биредә: эшләрен мәгънәсендә.
[7] Зәмиләрдән – шелтәләрдән.
[8] Хәраҗәт – чыгымнар.
[9] Тарыз – рәвеш, ысул.
[10] Мөстәгыйд – сәләтле.
[11] Моктәдир – сәләтле.
[12] Сәд – киртә.

ле мәгыйшәт эчендә тора торган рус руханилары вә аларны хәзерли торган мәктәпләре нинди фәннәргә мохтаҗ булса, безнең мәктәпләргә дә шул ук нәрсәләр вә безнең руханиларымызга да шул ук белем вә хәзерлекләр кирәктер. Шуңар күрә дә хәзерге искелек исереклегеннән айнып, әтрафымызга аек күзләр белән карарга, яңа фәнни мәктәпләр ача башларга вә хәзердәге рухания мәдрәсәләремезне әсасларыннан ислах итәргә тиештер: мәдрәсәи руханияләремезне урта вә гали уларак ике кыйсемгә бүлеп, урта мәктәпләрен чын белерлек иттереп, гарәп, төрек вә татар телләре вә әдәбиятлары тәгълим ителгән өстенә хисап, җәбер, һәндәсә, табигыят[1], җәгърафия, тарих гомуми, дини вә милли һәм дә яхшы белерлек дәрәҗәдә рус теле укылырга кирәктер. Моның өстенә дә мөһиммате динияне[2] бик яхшы укый вә белерлек вакыт вә гомер каладыр. Голүме диниянең тәфсыйлятене вә фәлсәфәсене мәкятибе галиягә калдырып, урта дини мәктәпләрне бетергән кешеләр бу гали мәктәпләргә керергә мөстәгыйд булганнары өстенә, аннан чыгып, аз гына бер тәкмил белән башка мәкятибе галиягә дә керерлек булырга тиештер.

Менә безнең мәдрәсәләр ислахы кайда таба сәер итәргә һәм гакыйбәте[3] нәрсәгә барып чыгарга лязимдер! Бәлки безгә фән укыган кеше динне ташлый, фән вә дин бергә җыелмый, диярләр. Ләкин без бу кешеләргә әсасән җавап бирүдән элек, динне хәкаикъка мохалиф дип тәхкыйрь иткәнлекләре[4] өчен үземезнең мөселманлык сыйфатымыз белән протестовать итәмез һәм ул кешеләрне дин хакында әдәпсезлек иткән диянәтсезләр дип таныймыз.

*(«Әлислах», 1907, № 6, 12 ноябрь)*

*Басмага әзерләде:*
***Зәйниева Гөлнара Нургали кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

[1] Табигыят – табигать турындагы фән.
[2] Мөһиммат – әһәмиятле эшләр.
[3] Гакыйбәте – нәтиҗәсе.
[4] Тәхкыйрь иткәнлекләре – түбәнсеткәннәре.

УДК 003.332.5

***Г. Алпаров***

# ХАРИТОНОВ ХӘРЕФЛӘРЕ

В журнале «Мэктэп» в 1913 году была напечатана статья Г. Алпарова «Буквы Харитонова», которая стала рецензией автора на букварь И.Н. Харитонова «Подарок», изданный в 1912 году. Он на примерах показывает, что введенные новшества Харитонова в написании некоторых букв арабского шрифта разрушают основы арабских букв в татарской письменности и затрудняют процесс обучения детей. Поэтому Г. Алпаров рекомендует использовать букварь при работе с детьми уже знающими азбуку. Работу И.Н. Харитонова он рассматривает как один из проектов по реформе татарского шрифта с арабской графикой, которая была актуальной проблемой начала XX века. Известно, что в 1921, 1926 годах были организованы конкурсы на лучшие проекты типографских букв. По результатам конкурса в 1927 году для реализации в книгопечатании был выбран проект М. Идрисова.

**Ключевые слова:** И.Н. Харитонов, реформа арабского шрифта, татарская письменность, Г. Алпаров, азбука «Подарок».

An article by G. Alparov «Letters of Kharitonov» was published in the magazine «Mektep» in 1913 which became the author’s review of the primer by I.N. Kharitonov «Gift», published in 1912. He shows by examples that the innovations introduced by Kharitonov in writing some letters of the Arabic script destroy the foundations of Arabic letters in Tatar writing and make it difficult for children to learn. Therefore, G. Alparov recommends using the primer when working with children who already know the alphabet. He considers the work of I.N. Kharitonov as one of the projects for the reform of the Tatar script with Arabic graphics, which was an urgent problem at the beginning of the 20th century. It is known that in 1921, 1926 contests were organized for the best projects of typographic letters. According to the results of the contest in 1927, the project of M. Idrisov was chosen for implementation in book printing.

Keywords: I.N. Kharitonov, reform of the Arabic script, Tatar writing, G. Alparov, alphabet «Gift».

*1912 елда И.Н. Харитонов авторлыгында һәм аның типографиясендә «Бүләк» исемле татарча әлифба нәшер ителә. Әлеге әлифбаның төсле басмасы Милли музейда саклана. Әлифба техник эшләнеше, иллюстрацияләрнең күплеге белән үзенә җәлеп итә. Шулай ук китапта ишетмәүче балаларга ярдәм йөзеннән дактиль әлифба да урнаштырылган. Әйтергә кирәк, XX гасыр башы татар дәреслекләре арасында И.Н. Харитоновның «Бүләк» китабы – сәнгати югары дәрәҗәдә эшләнгән әлифбаларның беренчесе.*

*Дәреслекне татар җәмгыяте төрлечә кабул итә. Мәсәлән, олуг шагыйребез Г. Тукай «Сабитның укырга өйрәнүе» шигырендә әлеге әлифбаның эчтәлегенә, сәнгати эшләнешенә югары бәя бирә.*

*Шул ук вакытта хәрефләрнең бирелешенә, дәреслекнең төзелешенә карата вакытлы матбугатта тәнкыйди мәкаләләр дә басыла.*

*Шундый хезмәтләрнең берсе – Г. Алпаровның 1913 елда «Мәктәп» журналында басылган «Харитонов хәрефләре» дигән мәкаләсе. Г. Алпаров әлифбада хәрефләрнең язылыш үзенчәлекләренә туктала һәм аларны гарәп шрифтындагы татар язуының исляхына, ягъни реформасына автор тарафыннан тәкъдим ителгән хәреф үрнәкләре буларак кабул итә һәм бу хакта үз фикерләрен җиткерә.*

*Татарларда, гомумән төрки халыкларда басма гарәп хәрефләрен ислях итү – XX гасыр башында күтәрелгән төп мәсьәләләрнең берсе. Әлеге реформа кысаларында 1921 һәм 1927 елларда конкурслар үткәрелә. Конкурс нәтиҗәләре буенча полиграфист М. Идрисов проекты кабул ителә. 1928 елда типографияләрдә әлеге проект гамәлгә ашырыла башлый. Әмма 1929 елда латинга күчә башлау сәбәпле, моңа ихтыяҗ калмый.*

*Хәреф исляхы нәтиҗәсендә хәрефләрнең язылыш урыннарына карап кулланылган төрләре төшереп калдырыла. Хәрефләрнең басмада башлангыч язылышын гына куллану китап басу барышын икътисади яктан отышлы итә. Шулай ук хәреф җыючыларның хезмәтен дә күпкә җиңеләйтә.*

*И.Н. Харитонов тәкъдим иткән хәреф үрнәкләре белән Г. Алпаров килешми, авторның басма хәрефләрне генә түгел, язма хәрефләрне дә үзгәртүенә каршы килә.*

*«Мәктәп» журналы идарәсе әлеге мәкаләнең фикер алышу буларак басылуын да искәртеп үтә.*

Хәрефләребезне ислях итәргә[1] тиеш икәнлеге һәркемгә билгеле инде. Аңлырак кешеләребез аны күптәннән аңлап, төзәтү чараларына да керешә башладылар. Өченче ел Оренбурглы борадәр Рәмиевләрнең «Хатты тәбагать яхуд айры хәрефләр» исемле бик гүзәл, ислях ителеп күрсәтелгән хәрефләр белән басылган китаплары нәшер ителгән иде. Бу ел Казанда мәшһүр матбагачы И.Н. Харитонов җәнапларының шушы Рәмиев хәрефләрен бераз үзгәрткәләп ясаткан хәрефләр белән басылган «Бүләк» исемле китабы мәйданга чыкты.

Рәмиевләрнең күрсәткән хәрефләренә үз вакытында байтак ук күп һәм әсаслы тәнкыйть вә мәкаләләр язылган иде. Борадәр Кәримовлар һәм «Милләт» матбагаларының эшләткән хәрефләрендә ул мәкаләләр яхшы ук игътибарга алынган. Әмма Харитонов җәнапларының бу китапта күрсәткән хәрефләрендә ул матбугатта язылган фикерләргә һич тә дикъкать ителмәгән төсле күренә. Аның өстәвенә монда Харитонов җәнапларының үзе тарафыннан арттырылган әллә нинди, ят, бер дә кеше таный алмаслык хәрефләр дә байтак. Мисләә, ҩ о ö u ĩ ⊥̤ хәрефләре. Боларның әүвәлгесе сүз башындагы «او» хәрефе

[1] Ислях итәргә – үзгәртергә.

урынына алынган. *Уку, урам* дигән сүзләрнең башында шул хәреф язылган.

Икенчесе татарча нинди хәреф урынына йөридер – мин белә алмадым, китапта мисал урынына *Харитон, орел* дигән рус сүзләре генә күрсәтелгән.

Өченчедән. Ӧ галәмәте сүз башында килгән (ۋ) хәрефе урынына алынган. Мисләә, *өч* дигән сүз «چӧ» сурәтендә язылган. Бу бер тавышның сүз уртасында (ۋ) сурәтендә, сүз башында (ӧ) йөртелүеннән ни файда бар икән?... Без соң шул хәрефләребезнең бер тавышка берәр генә сурәттә калуы өчен тырышабыз түгелме?...

Дүртенчедән, «u» галәмәте *сары* дигән сүзнең ахырындагы «ы» тавышындарак ишетелгән хәреф урынына алынган. Әмма сүз уртасында килгән шул тавышка бу галәмәт куелмаган.

⊥̣ галәмәте русча (ё) хәрефе урынына алынган. «Бүләк»тә о белән ё дән башка рус хәрефләре күрсәтелмәгән! Монда ни хикмәт, нинди сер бардыр, мин төшенә алмадым!...

ا галәмәте бу көндә бөтен татар-төрк галәмендә могтәбәр «ہ – ئە» хәрефенә каршы рәкыйб (конкурент) булыр өчен чыгарылган. Харитонов хезмәтләренчә, *әтәч, кәҗә* дигән сүзләрне کاَجاَ , آتاَچ сурәтендә язарга тиеш була инде.

Бусы тагын бер хәл инде – ул гарәпчә хәрәкәле «اَ» хәрефе. Ә соң теге ɵн, о, u, ⊥̣ , хәрефләре безгә нигә кирәк? Боларда бит хатты куфигә[1] һәм гарәп хәрефләренә охшауның исе дә юк. Болар ни укырга, ни язарга уңайлы түгел...

Безгә үз тавышларыбыз өчен гарәп хәрефләрендәге хасиятләргә туры килгән хәрефләр кирәк иде. Без рус тавышларына хәрефләр табып бетерә алмабыз.

Бу хәрефләр урынына Харитонов җәнаплары татар телендә генә була торган, безгә һәрвакыт кирәкле, әлегә чикле могтәбәр булган хәрефләрне генә куйдырса яхшы булыр иде. Мисләә, хәзерге язуларыбызда һәрвакыт йөртелә торган (ئە ,ہ) хәрефләрдән эшләтергә кирәк иде.

Татар галәме имля мәсьәләсендә бер иттифакка килмәс борын, шушы элекке хәрефләрне генә койдырып торганда да ярар иде.

Мин хәрефләребезне болай төзәтергә димлим: без басма өчен элекке кулъязмада баш, урта, ахыр, ялгыз булып йөргән хәрефләрнең кайсысы асыл, кайсысы бер җирдә дә төшеп калмый языла торган булса, шунысын алырга кирәк, дим.

Бу хәреф – баш хәреф икәнен әз генә дикъкать ителгән кеше дә беләчәк. Ул хәрефләрнең бер җирдә дә төшеп калмый торган өлеше аларны бергә китереп тезеп язганда язу тәмам элекке язуга охшап чыга (ике төрле генә йөртелгән хәрефләрнең, әлбәттә, ялгызы асыл).

---

[1] Хатты куфи – куфи язуы, стиле.

Бүтән шәкелдәге хәрефләрдән төзелгән язулар элекке язуга охшамыйлар һәм аларны алганда язар өчен дә җиңел булып чыкмый. Мисләә, «Харитонов бабай хәрефләре» дигән сүзне язып карыйк.

*(Баш хәрефтән, урта, ялгыз, ахырда языла торган хәрефләр белән үрнәкләр китерелә.)*

Болар арасыннан матбага хәрефләренең берәр генә шәкелдә калуы, язуларыбызның элекке хәленнән үзгәрмәве өчен иң муафыйк булганы «баш хәрефләр» түгелме соң ә?! Төзәтелгән хәрефләребез элеккеге язуларыбызга бер дә охшап чыкмаса, язарга да авыр булырлык булса, халкыбызның андый хәрефләрне кабул итү ихтималы да юк. Һәм безгә андый хәрефләрне кабул итәргә дә тиеш түгел.

Безнең элекке хәрефләребез язарга, укырга тәмам уңайлы, тәмам җиңел булганча тәрәккый иткән – эшләнгән инде. Безнең элекке хәрефләребез язуыбыз кадәр җиңел була алмый. Безгә хәрефләребезнең мөмтаз хасиятләрен югалтмый сакларга гына тиеш. Матбага хәрефләрен бу шартларга туры китереп ислях итәр өчен, азрак матурлап, хәзергә баш хәрефләрне кабул итәргә тиеш кебек күренә. Шуңа бинаән[1], мин Харитонов җәнапларының ݣ, ڭ хәрефләрендә ک хәрефе сурәтендәрәк итеп, ک ның өстенә бер сызык яки өч нокта куеп кына ясауны үтенер идем. Чөнки ڭ, ݣ хәрефләре Рәмиевләр күрсәткән сурәттә булганда, башта һәм уртада килгәндә бик муафыйк булып чыкмыйлар.

Аннары ﺑ, ﭘ, ﺗ, ﺣ, ﺧ, ﻧ, ﻳ хәрефләрен дә баш хәрефләр сурәтендә алганда яхшы булыр иде. Ул чакта бу хәрефләр, кайсы җирдә килсәләр дә, килешеп торачаклар.

Мисләә, *Харитон* дигән сүз мин әйткән хәрефләр белән язылса, «خاریطون» сурәтендә булып чыга. (Үзегез башка сүзләрне дә язып тикшереп карагыз әле.) Безнең бит асыл максудыбыз хәрефләрне бер генә калдыру. Аларны русчага охшату түгел! Без «Хәрефләребезнең басмада берәр шәкелдән генә калуын, әмма язуыбызның үзгәрмәвен телибез».

Мадам ки[2], баш хәрефләр белән шул максудыбыз тәмам үтәлсә, без аны кабул итүдән бер дә чирканырга ярамый.

«Бүләк»тә күрсәтелгән хәрефләрдән иң муафыйклары:
آ, ا, ﺟ, ﭼ, د, ذ, ر, ز, ژ, ع, غ, ﻓ, ﻗ, ﻛ, ا, و, ۇ, ۋ хәрефләре.

*Син, шин, сад, дад, та, за* хәрефләренең дә сул тарафыннан бераз гына чыкынтылары булса, тәмам муафыйк вә гүзәл булып чыгар иде.

III

Харитонов җәнаплары бу «Бүләк»не балалар өчен әлифба китабы дип атаса да, исеме җисеменә дә муафыйк булып күренми. Беренче, рәсемнәргә карап, хәрефләрне табарлык түгел.

Мисләә, кысла сурәте астында «آكار», бөркет сурәтендә «مريل» дигән сүзләр язылган. Һәм дә бер турыда бер тавышта әллә ни чикле

[1] Бинаән – нигезләнеп.

[2] Мадам ки – чынлыкта.

төрле шәкелдә хәрефләр күрсәтелгән, хәрефләрне укыр өчен бер дә сүзләр һәм җөмләләр язылмаган. Шуның өчен мин аны язу таныган зуррак балаларга матур сурәтләрен һәм төрле хәрефләрен карар өчен генә сатып алырга тәкъдим итәмен.

Харитонов җәнаплары бу хәрефләре белән бергә татарча кульязма өчен дә яңа, русча кульязмага охшашлы Рукопись[1] нәмунәсе дә нәшер иткән. Бу төрле кульязма, хакыйкатән, һич аермасыз, рус язуларына охшап чыга.

Ләкин мин моны буш һиммәт[2], юкка вакыт әрәм итү кебек күрәм. Чөнки безнең кульязманың иң кыска һәм иң ансат язу икәнен бер мин генә түгел, башка игътибарлырак кешеләр дә бик күп яздылар инде.

Безнең элекке кульязмабызны рус язуларына охшамавы сәбәпле генә ямьсез диеп тә булмый. Моны фәкать рус һәм яурупалылар язуына күзләре иялəшкән кеше генә әйтсә әйтер. Безнең иң маһир хаттатларыбыз булган кебек, иң гүзәл һәм язар өчен җиңел – уңай хатларыбыз да бар. Мәсәлән, сөлс, нәсех, тәгъликъ, рокга язулары матурлык һәм ансатлык җәһәтеннән яурупа халкының язуларыннан бер дә калышырлык түгелләр. Моны сәламәт гакыллы һәрбер кеше игътибар итәр.

Харитонов җәнаплары күрсәткән бу язулар исә безнең кульязмабызны ике, өч мәртәбә кыенлаштырачак.

Мин бу турыда сүземне артык озайтмыйча, туры фикерле затларны минем бу мәкаләмә дикъкать итүләрен, әгәр ялгыш фикер булса, миңа аңлатуларын үтенеп, каләмемне туктатам.

Уку, укыту эшләрендә иң мөһим бер урын тоткан бу «хәрефләр» мәсьәләсендә мөгаллим әфәнделәр, әлбәттә, дикъкатьсез булмаслар дип ышанам.

*«Мәктәп», 1913, № 8.*

*Гарәп графикасыннан кириллицага күчереп, басмага әзерләде:*
***Мифтахетдинова Нурия Мидхәт кызы,***
*ТР Милли музее өлкән фәнни хезмәткәре*

---

[1] Кирилл хәрефләре белән.

[2] Һиммәт – тырышлык.

УДК 9-05

***Ф.Й. Йосыпов***

# В.В. РАДЛОВНЫҢ КАЗАН ЧОРЫ ФӘННИ, ПЕДАГОГИК ЭШЧӘНЛЕГЕ

*(дәвамы)*
*Башы журналның 2023 елның 1 нче санында*

В статье рассматривается Казанский период научной, педагогической деятельности одного из основателей русской тюркологической науки всемирно известного ученого Василия Васильевича Радлова (нем. *Фридрих Вильгельм Радлофф*), который в течение своей шестидесятилетней научной деятельности охватил практически все области тюркологии: диалектографию и диалектологию, лексикографию и лексикологию, сравнительную и историческую фонетику и грамматику тюркских языков, куманский язык, текстологию и издание тюркской письменности на руническом, уйгурском, арабском алфавитах, тюркский фольклор, этнографию, историю, археологию.
**Ключевые слова:** В.В. Радлов, Казанская учительская школа, тюркские языки, образцы народной литературы тюркских племен, диалектология татарского языка, памятники древнетюркской письменности.

W. Radloff, worldwide known Turcologist, has accomplished numerous important works on almost every field related to Turcology such as dialectography, dialectology, lexiocography, lexicology, comparative historical phonetics and grammar of Turkish, transcription and facsimile of Turkish texts written with Runic, Uigur and Arabic alphabets, Turkish folklore, Turksih ethnography, Turkish history and archaeology. This study elaborates W. Radloff’s scientific researches.
**Keywords:** W. Radloff, Kazan teaching skool, Turcology, the dialectology of Tatar Turkish, folklore, old Turkish Manuscripts.

**В. В. Радлов һәм Казан галимнәре даирәсе**

В.В. Радлов Казанга бик теләп килә. Ул заманнарда ук шәһәребез, Санкт-Петербург һәм Мәскәүдән кала, зур фәнни үзәк булып санала. 1804 елда Казан Император университеты ачылганнан соң, биредә күренекле галимнәр туплана башлый. 1828 елда университетта төрек-татар филологиясе кафедрасы оеша. В.В. Радлов Алтайда эшләгәндә үк үзенең иҗади планнарын шул өлкәдә хезмәт куючы галимнәр белән уртаклашу турында хыяллана торган була. Казанга килеп урнашу белән, ул үзенә фикердәшләр эзли башлый. Бәхетенә каршы, В.В. Радлов 1873 елда Казан Император университеты доценты И.А. Бодуэн де Куртенэ белән таныша. Бодуэн де Куртенэ 1875 елда Петербург университетында докторлык диссертациясе яклап кайта, 1876 елда Казан университеты профессоры булып раслана. Берлин, Йен, Лейпциг, Прага университетларында теоретик яктан ныклы хәзерлек алган И.А. Бодуэн де Куртенэ Казан университетында тел белеме өлкәсендә эшләгән талантлы яшьләрне үз тирәсенә туплый

башлый, тел белгечләренең теоретик түгәрәген җитәкли. Казан лингвистика мәктәбенә нигез салган әлеге түгәрәк эшчәнлегендә В.В. Радлов иң актив катнашучыларның берсе була [Бодуэн де Куртенэ, 1963. с. 146–202; Тенишев, с. 32–43; Закирова, с. 3], еш кына үзенең фәнни тикшеренү нәтиҗәләре турында чыгышлар ясый, бу аның киләчәктәге гыйльми эшчәнлегендә зур роль уйный. 1883 елда И.А. Бодуэн де Куртенэ Дерпт (Тарту) университетына күчкәннән соң, Казан лингвистика түгәрәген Н.В. Крушевский, В.А. Богородицкийлар белән бергә В.В. Радлов та җитәкли. Ул вакытта гомуми тел белеме өлкәсендә атаклы галимнәрнең берсе булган И.А. Бодуэн де Куртенэның һәм гомумән Казан лингвистика мәктәбе вәкилләренең В.В. Радловка йогынтысы бик зур була. Мәгълүм булганча, И.А. Бодуэн де Куртенэ һәм аның яшь грамматистлар даирәсе җанлы сөйләмне өйрәнүгә зур әһәмият бирәләр. Алтай чорында Көнбатыш Себердә яшәүче күп кенә төрки халыкларның сөйләм телләрен өйрәнгән В.В. Радлов Казан лингвистика мәктәбенең бу карашын хуплап кабул итә. Россия телчеләре арасында көннән-көн киңрәк таралыш алган бу фикерне В.В. Радлов 1881 елда Берлинда уздырылган Көнчыгышны өйрәнүчеләрнең V халыкара корылтаенда «Die Lautalternation und ihre Bedeutung für die Sprachentnwickung, belegt durch Beispiele aus denTürksprachen» дигән чыгышында күтәрә [Тенишев, с. 37; Байрамова, с. 16–18). Соңыннан мәкалә булып басылып чыккан бу хезмәтендә ул фонеманың асылын И.А. Бодуэн де Куртенэ фикерләренә якынаеп кабул итә. Билгеле булганча, фонема төшенчәсе, беренче буларак, Казан Император университеты профессоры И.А. Бодуэн де Куртенэ башында торган бер төркем галимнәр тарафыннан ачыклана. Хәзерге вакытта тел белемендә кабул ителгән караш буенча, фонема телнең мәгънә аера торган иң кечкенә берәмлеге булып санала. Казан лингвистика мәктәбенә нигез салган Бодуэн де Куртенэ билгеле бер телдәге аерым бер авазның, лексик, грамматик мәгънәсе булмауга карамастан, сүзләрнең, кушымчаларның мәгънәләрен үзгәртә алу сәләтенә ия булуына игътибар итә. Сүзләрнең мәгънәсе бер авазны икенче аваз белән алыштыруга бәйле булса, әлеге аваз берәмлеге шушы телнең мөстәкыйль аваз-фонемасы булып санала. Әгәр бер үк аваз үзенең тördәшләреннән бары тик яңгырашы белән генә аерылып торса, ул әлеге авазның фонетик варианты гына булып санала. Казан университеты, аерым алганда, Казан лингвистика мәктәбе вәкилләренең әлеге ачышы XX гасырда гомуми тел белеменең зур казанышларыннан санала. Мәсәлән, нинди дә булса бер телне фәнни өйрәнә башлаганда, сүзләрне формалаштыра торган күпсанлы авазлардан кешеләр арасында аралашу чарасын дөрес тәэмин итә торганнарын аерып чыгару әһәмиятле. Бу процесс өчен мөһим авазлар үзләренең фонетик вариантларыннан гадәттә нинди дә булса бер үзенчәлеге белән аерылып тора. Бу үзенчәлекнең, сүз составындагы авазның булу-булмавына карап, мәгънәсе дә үзгәрә. И.А. Бодуэн де Куртенэ, В.В. Радлов һәм аларның фикердәшләре кешенең авазлардагы бу әһәмиятле

үзенчәлекләрне сайлап алуын ике факторның эшчәнлегенә бәйләп аңлаталар. Аның беренчесе – физик (авазларны әйтү), икенчесе – психологик, ягъни кешенең эчке халәтенә бәйле рәвештә, авазларның мәгънә белдерү хосусиятләре. Шунлыктан әлеге шартларны белү телнең бу эшчәнлеген информантлардан турыдан-туры ишетү юлы белән генә өйрәнергә кирәк, дигән нәтиҗәгә китерә. Алар карашынча, бары тик тере (хәзерге) телләрне диалектлардагы барлык нечкәлекләре белән өйрәнү генә гомумхалык теленең ничек, ни рәвешле үсеш-үзгәреш кичерүен күзалларга мөмкинлек бирә. Биредә В.В. Радлов, Казан лингвистика мәктәбе вәкилләре тарафыннан нигезләнгән карашларга таянып, төрки телләрдәге фонетик үзгәрешләренең асылын аңлауга һәм аңлатуга ирешә. В.В. Радловның Казан чорына кадәр язылган хезмәтләренең берсендә дә аралашу процессында мәгънә аеруда кулланыла торган фонема турында сөйләнмәсә дә, аның югарыда аталган мәкаләсендә автор авазларның әлеге үзенчәлеген аңлауда Казан тел белеме вәкилләренә бик якын тора [Тенишев, с. 38]. Галим хезмәтләренең Казан лингвистика мәктәбе йогынтысы нәтиҗәсендә башка яңа фикерләр белән баюын без түбәндәге мисалда да күрә алабыз. «Die Lautalternation und ihre Bedeutung für die Sprachentwickung, belegt durch Beispiele aus denTürksprachen» (Берлин, 1881) дигән хезмәтен ул Н.В. Крушевскийнең фонетик үзгәрешләр, аваз күчешләренең теоретик нигезләрен аңлаткан «Über die Lautabwechslung» мәкаләсе белән танышканнан соң яза. Н.В. Крушевский авазлар арасында өч тип күчеш булуын ачыклый: 1) билгеле бер комбинатор процесслар нәтиҗәсендә барлыкка килә торган дивергенция – дивергентлар; 2) корреляция – коррелятлар; 3) морфологик шартларга бәйле рәвештә барлыкка килгән корреляция һәм коррелятлар. Аларның барлыкка килүен Н.В. Крушевский тарихи процесслар һәм телдәге закончалыклар нигезендә аңлата. Н.В. Крушевскийның авазлар күчеше өч тип аваз чиратлашуларыннан тора, дигән фикерен В.В. Радлов төрки телләр матералында сынап карый һәм әлеге күренешнең махсус рәвештә аңлап башкарыла торган психологик факторлар белән бәйләнмәгәнлеген искәртә. Галим фикеренчә, күп кенә очракларда бу процессларга экстралингвистик факторлар, әдәби тел, күрше телләр белән үзара бәйләнешләр дә тәэсир итәргә мөмкин.

В.В. Радлов үзенең мәкаләсендә Казан лингвистика мәктәбенең бу өлкәдәге карашларына зур бәя бирә. Аның әйтүенчә, бу хезмәт линвистика фәне үсешенә этәргеч бирә торган күп кенә яңа карашларга бай. Галим, шушы хезмәттәге фикерләреннән чыгып, беренче чиратта, үзенең, шулай ук гомуми тел белеме, аерым алганда, тюркология өлкәсендәге беренчел бурычларны билгели: 1) дивергенция барлыкка килү шартларын ачыклау өчен, авазлар табигатен тагын да тирәнрәк өйрәнүне дәвам итү; 2) дивергенция шартларының төрләрен төркемләп өйрәнү; 3) дивергенция тәэсирен (эффектын) булдыра торган көчләрнең нинди өлешләрдән торуын ачыклау; 4) дивергенциянең тарихи үсеш-үзгәрешен, аның төрле тел семьялыкларында барлыкка килү шартларын ачыклау, аларны чагыштырып өйрәнү; 5) аваз

үзгәрешләренең үзеннән-үзе (спонтан рәвештә) барлыкка килү моментларын өйрәнү (бу күренешләрнең нинди физик яки психологик сәбәпләрдән барлыкка килүен ачыклау; 6) аваз үзгәрешләренең үзеннән-үзе (спонтан рәвештә) алга таба хәрәкәт итәргә ярдәм итүче, комачаулаучы төрләрен, тарихын ачыклау; 7) кайбер телләр өчен хас булган аффилир (катлаулы) авазларны ачыклау, аларны чагыштырып өйрәнү; 8) авазларны төшереп калдыру; 9) коррелятив күренешләрне төркемләү, бу күренешләрнең сәбәпләрен ачыклау; 9) фонетик күренешләрнең морфология закончылыгына каршы килү очраклары; морфологик законнар нигезендә килеп чыккан фонетик үзгәрешләрне билгеләү [Байрамова, 2013, с. 18].

В.В. Радлов сөйләмдә телнең эчке кануннары буенча барлыкка килгән аваз үзгәрешләренең сәбәпләре итеп түбәндәгеләрне күрсәтә: 1) комбинатор шартлар; 2) авазның билгеле бер позициядә булуына бәйле шартлар; 3) басымга бәйле шартлар.

Югарыда В.В. Радлов санап үткән шартларда барлыкка килгән аваз үзгәрешләре фонеманың табигатен аңларга ярдәм итә торган хәзерге карашларга туры килә [Тенишев, с. 38; Закирова, с. 40].

Казан лингвистика мәктәбенә нигез салган И.А. Бодуэн де Куртенэ дусты һәм фикердәше В.В. Радловның фәнни иҗатына һәрвакыт игътибарлы булган. Аны Казан лингвистика мәктәбе галимнәре фикерләренең төрки һәм башка система телләрен өйрәнү тәҗрибәсендә ни рәвешле чагылыш табуы кызыксындыра. И.А. Бодуэн де Куртенэ В.В. Радловның «Einleitende Gedanken zur Darstellung der Morphologie der Türksprachen» дигән мәкаләсе басылу уңаеннан «Заметки на полях в сочинениях Радлова» дигән бәяләмәсе белән чыга. Ул аның телләрне морфологик төркемнәргә бүлү пргинципларын, нигездә, кабул итсә дә, хезмәттәшенең ул заман тел белемендә урнашкан карашларга ияреп, төрле типтагы телләрнең үсеше тәртибе турындагы фикерен шикләнеп кабул итә [Бодуэн де Куртенэ, 1963, с. 146–202].

И.А. Бодуэн де Куртенэ һәм В.В. Радлов гомерләренең ахырына кадәр фәнни һәм шәхси бәйләнешләрен саклыйлар. И.А. Бодуэн де Куртенэ В.В. Радловның Казан лингвистика мәктәбе карашларын кабул итүеннән канәгать була. «Николай Крушевский, его жизнь, научные труды», «Опыт теории научных альтернаций» хезмәтләрендә В.В. Радловның Казан линвистика мәктәбенең, шулай ук аның икенче күренекле вәкиле саналган Н.В. Крушевский тәкъдим иткән теоретик фикерләрне төрки телләр өлкәсендә уңышлы куллануын, аваз үзгәрешләренең сәбәпләрен билгеләүдә бер-берсенә бик якын торуларын, кайбер аерымлыкларның бары терминология өлкәсенә генә карагандыгын билгеләп үтә [Бодуэн де Куртенэ, 1963, с. 170].

В.В. Радлов Казанда яшәгән елларда Казан университеты каршындагы Археология, тарих, этнография җәмгыятенең хакыйкый әгъзасы була һәм аның эшчәнлегендә дә актив катнаша [Валеев, с. 180]. Җәмгыятьнең IV съезды (1877) эшендә катнашып, үзенең чыгышында Шиһабетдин Мәрҗанинең рус теленә үзе тәрҗемә иткән

«Гиләләт аз-заман фи тарих Болгар вә Казан» әсәре турында сөйли [Гайнуллин, б. 196; Закирова, с. 54]. 1884 елда ул съезд материалларында рус һәм татар телләрендә басылып чыга.

Казанның фәнни даирәләрендә В.В. Радлов үзен төрки телләрне өйрәнү өлкәсендә өлгереп җиткән, алыштыргысыз галим итеп таныта. И.А. Бодуэн де Куртенэ 1883 елда Казан университеты җитәкчелегенә В.В. Радловны фин-төрки филология кафедрасы лекторы итеп эшкә алуны сорап мөрәҗәгать итә [НА РТ, ф. 977, оп. ИФФ, д. 1249. л. 1–49; Закирова, с. 53–54] һәм аны Казанда бу вазифага лаеклы бердәнбер кандидатура дип атый. Әмма В.В. Радлов Император Фәннәр академиясенә сайлану сәбәпле, әлеге эшләр тормышка ашмый кала.

Шулай итеп, дистәләрчә еллар буе Көнбатыш Себердә яшәүче төрки халыкларның телләре буенча тупланган материалларны фәнни яктан дөрес итеп аңлатуда В.В. Радловның Казан лингвистика мәктәбе белән булган элемтәләре уңышлы нәтиҗәләргә килергә ярдәм итә. В.В. Радлов иҗатын өйрәнүчеләр хаклы рәвештә аның үзен дә Казан лингвистика мәктәбе күренекле вәкилләренең берсе дип бәяли [Юсупов, 2010, с. 4–7].

**Әдәбият**

*Ахметова-Урманче Ф.В.* По следам В.В. Радлова // Фәнни эзләнүләр юлында. Казан: Фикер, 2000. Б. 205–218.

*Әхмәтова-Урманче Ф.* Татар эпосы. Дастаннар. Казан: Раннур, 2004. 640 б.

*Әхмәтҗанов М.И.* Илдан белән Гөлдан дастаны хакында // Әдәби мирас. Икенче китап. Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. Б. 44 .

*Әхмәтҗанов М.И.* Себер ханлыгына кагылышлы билгесез татар чыганаклары // Фән һәм тел. 2003. № 2.

*Байрамова Л.К.* Научные контакты В.В. Радлова, И.А. Бодуэн де Куртенэ и Н. В. Крушевского // В.В. Радлов. Духовная культура тюркских народов. Первая международная интернет-конференция (21 марта 2012 года): Сборник трудов. Казань: Казанский университет, 2012. С. 16–18.

*Бартольд В.В.* Памяти В.В. Радлова. (1837–1918) // *Бартольд В.В.* Сочинения. Т. 9 (Работы по истории востоковедении). М.: Наука, 1977. Б. 175–186.

*Биккенин Р.* Мухаммед-Сафа Биккенин и Василий Васильевич Радлов: Из истории первого в Казанской губернии татарского начального училища // Гасырлар авазы = Эхо Веков. 2006. № 1. Б. 8–15.

*Бодуэн де Куртенэ И.А.* Заметки на полях сочинения В.В. Радлова (1909) // Живая Старина. 1909. Вып. 3. С. 191– 205.

*Бодуэн де Куртенэ. И.А.* Николай Крушевский, его жизнь и научные труды // Бодуэн де Куртенэ И.А. Избранные труды по общему языкознанию. Т. I. М., 1963. С. 146–202.

*Валеев Р.М.* Казанское востоковедение: истоки и развитие (XIX – 20-ые гг. XX в.). Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1998. 180 б.

*Гайнуллин М.Х.* Татарская литература XIX века. Казань: Татар. кн. изд-во, 1975. С. 307.

Джаным. Антология сибирских татар / Сост.: Ф.В. Ахметовой-Урманче и А.В. Преловского. М.: Новый Ключ, 2007. С.186–189.

*Загидуллин И.К.* Составлен со знанием дела, но имеет ряд существенных недостатков (Проект инструкции инспекторам татарских, башкрских, киргизских школ. 1876 г. // Гасырлар Авазы = Эхо веков. 2009. № 2. С. 47–52.

*Загидуллин И.К.* Татарская школа и русификаторская политика царизма во второй половине XIX в. // Народное просвещение у татар в дооктябрьский период. Казань, ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова, 1992. С. 60–68.

*Загидуллина Д.Ф.* Из истории преподавания татарской литературы в дооктябрьский период // Народное просвещение у татар. Казань ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова, 1992. С. 105–118.

*Закирова Л.И.* Василий Васильевич Радлов. Казанский период деятельности. Казань: Ихлас, 2013. С. 291.

*Ильминский Н.* Новые учебные руководства для татар магометан г. Радлова // Журнал Министерства народного просвещения. 1873. С. 370–374.

*Исхаки Г.* Василий Васильевич Радлов // Әлислах. 1909. № 68.

Казанская татарская учительская школа в 1976–1917 гг.: Сборник документов и материалов. Казань, 2005. 256 б.

*Каримуллин А.Г.* Татарская книга пореформенной России. Казань: Татар. кн. изд-во, 1983. 320 б.

*Катанов Н.Ф.* Предания тобольских татар о прибытии в 1572 г. мухаммеданских проповедников в г. Искер // Ежегодник Тобольского губернского музея. Тобольск, 1897. Вып. 7. С. 51–61.

*Кононов А.Н.* В.В. Радлов и отечественная тюркология // Тюркологический сборник. М.: Наука, 1972. С. 7–15.

*Махмутова А.Х.* Становление светского образования у татар (Борьба вокруг школьного вопроса 1861–1917). Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1982. С. 82.

*Мурадов В.* Ефим Малов о Ш. Марджани, К. Насыри, В.В. Радлове // Гасырлар Авазы = Эхо Веков. 1999. № 1/2. С. 152–160.

НА РТ (Татарстан Республикасының милли архивы), ф. 92, оп. I., д. 10290.

НА РТ, ф. 92, оп. I, д. 10290, л. 1–2.

НА РТ, ф. 92, оп. I, д. 13147, л. 24.

НА РТ, ф. 92, оп. I, д. 13147, л. 4, 24.

НА РТ, ф. 92, оп. I, д. 13147, л. 39.

НА РТ, ф. 977, оп. ИФФ, д. 1249, л. 1–49.

НА РТ, ф. 977, оп. ИФФ, д. 1249, л. 21.

НА РТ, ф. 92, оп. I, д. 15519, л. 4–7.

НА РТ, ф. 92, оп. I, д. 15539, л. 6–7.

*Радлов В.В.* Белек. Балалар укыр өчен чыгарылган китап. Казан: Казан ун-ты тип., 1872. 232 б.

*Радлов В.В.* Образцы народной литературы тюркских племен, живущих в Южной Сибири и Джунгарской степи. Часть IV. Наречия барабинцев, тарских, тобольских и тюменских татар / сост. д-р филол. наук Ф.Ю. Юсупов). Казань: Татар. кн. изд-во, 2012. 517 с.

*Радлов В.В.* Первая книга для чтения. Казань: Тип. Казан. ун-та, 1874. 171 с.

*Радлов В.В.* Грамматика русского языка, составленная для татар Восточной России. Часть. I. Этимология. Казань: Тип. Казан. ун-та, 1878. 114 с.

*Радлов В.В.* Материалы для разговорных уроков по способу наглядного обучения инородческих школ. Казань, 1978. 87 с.

*Радлов В.В.* Учебник немецкого языка по методу Лувье. Казань, 1872. 110 с.

*Радлов В.В.* О языке куманов по поводу издания куманского словря. СПб.: Тип. Имп. Академии наук. 1884. 53 с.

*Самойлович А.Н.* Радлов как турколог (речь, произнесенная в публичном заседании Российской Академии Наук 12 мая 1919 г.) // Новый Восток. Кн. вторая. М., 1922. С. 707–712.

*Тенишев Э.Р.* В.В. Радлов – фонетист и грамматист // Тюркологический сборник. М.: Наука, 1972. С. 32–41.

*Фәхретдинов Р.* В.В. Радлов җәнапларының илле еллык (1859–1909) бәйрәме // Шура. 1909. № 10.

*Ханбиков Я.* В.В. Радлов (1837–1918) // Русские педагоги Татарии и их роль в развитии просвещения и педагогической мысли татарского народа. Казань: Министерство просвещения РСФСР; КГПИ, 1968. С. 42–49.

*Хаҗиев В.* Талантлы тюрколог // Мирас. 2000. № 4. Б. 77–82.

*Шәрәф Г.* Төрек телләренең олуг галиме В.В. Радлов // Кояш. 1917. № 5, 10 гыйнвар.

*Шәрәфетдинов З.Т.* Казан лингвистика мәктәбе һәм аның педагогик традицияләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. Б. 103.

*Юсупов Ф.Ю.* В.В. Радлов – выдающийся тюрколог России // Татар халык иҗаты. Фәнни эзләнүләр һәм фольклор үрнәкләре: фәнни конференцияләр материаллары җыентыгы. Казан: Ихлас, 2011. Б. 136–185.

*Юсупов Ф.Ю.* В.В. Радлов – великий тюрколог России // Радлов В.В. Образцы народной литературы тюркских племен... Казань: Татар. кн. изд-во, 2012. С. 3–29.

*Юсупов Ф.Ю.* В.В. Радлов – основоположник Российской филологической науки // Научный Татарстан. 2012. № 2. С. 173–195.

*Юсупов Ф.Ю.* В.В. Радлов яркий представитель Казанской лингвистической школы // В.В. Радлов и духовная культура тюркских языков. Первая Международная интернет конференция. Сборник трудов. ИФИ. 21 марта 2012. Казань, 2012. С. 4–7.

*Юсупов Ф.Ю.* Деятельность В.В. Радлова в формировании российской тюркологической науки // «Занкиевские чтения»: материалы Всероссийской научно-практической конференции. Тобольск: ТГСПА им. Д.И. Менделеева, 2013. С. 152–157.

*Юсупов Ф.Ю.* В.В. Радлов – основоположник тюркологической науки России. Международный тюркологический симпозиум, посвященный памяти выдающегося тюрколога, доктора филологических наук, профессора, академика РАН Эдхяма Рахимовича Тенишева. Сборник статей. Казань, 2013. С. 85–88.

*Gronbech K.* Codex Cumanicus. Kopenhagen, 1936.

*Radloff W*. Vergleichende Grammatik der Türksprachen. Erster Teil. Phonetik der nördlichen Türksprachen» . Leipzig, 1882. 77 s.

*Yusupov Ferit Yusupoviç.* «Rusya Türkolojisinin Kurucusu – V.V. Radlov» (Çev. Fatih Ekici), Atatürk Üniversitesi Edebiyat Fakültesi Sosyal Bilimler Dergisi. S. 52, Erzurum 2014. S. 291–311.

*Yusupov Ferits Yusupovich*. Contemporary issues of textual analysis of turkic-tatar literary monuments of western Siberia (2013, World Applied Sciences Journal, 27 (13 A). P. 492–496).

***Йосыпов Феритс Йосыф улы,***
*филология фәннәре докторы, профессор*

УДК 81'1

***Г.Ә. Нәбиуллина,***
***З.Н. Кириллова***

# ФЛЕРА САФИУЛЛИНА: ФӘНГӘ БАГЫШЛАНГАН ГОМЕР

***(Тел галиме Ф.С. Сафиуллинаның тууына 85 ел тулу уңаеннан)***

В статье освещаются основные направления научно-исследовательской и научно-методической деятельности известного татарского языковеда профессора Ф.С. Сафиуллиной, труды которой внесли большой вклад в развитие современного татарского языкознания и тюркологии. Она посвящается 85-летию со дня рождения учёного.

**Ключевые слова:** ученый, Флера Садриевна Сафиуллина, татарское языкознание, научное наследие, филология, татарский язык.

The article highlights the main directions of research and scientific and methodological activities of the famous Tatar linguist Professor F.S. Safiullina, whose works have made a great contribution to the development of modern Tatar linguistics and Turkology. It is dedicated to the 85th anniversary of the scientist's birth.

**Keywords:** scientist, Fleura Sadrievna Safiullina, Tatar linguistics, scientific heritage, philology, Tatar language.

Флера Садрый кызы Сафиуллина – тел галиме, филология фәннәре докторы, профессор, Татарстан Республикасының атказанган укытучысы, Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе, Халыкара төрки академия академигы, татар тел белеме һәм тюркология өлкәсендәге фәнни хезмәтләре белән Татарстанда һәм Россиядә генә түгел, дөньяның күп илләрендә танылган галимә.

Ф.С. Сафиуллина Казан дәүләт университетының тарих-филология факультеты татар теле һәм әдәбияты бүлегендә белем ала. 1960 елда укуын кызыл диплом белән тәмамлагач, университетның яңа оешкан татар теле кафедрасында башта лаборант булып эшкә урнаша. Бер елдан ассистент вазифасын үти башлый. Ф.С. Сафиуллина, М.З. Зәкиев җитәкчелегендә аспирантура үтеп, 1966 елда «Татар телендә сүз тәртибе» дигән темага кандидатлык диссертациясен уңышлы яклый һәм филология фәннәре кандидаты дәрәҗәсенә ия була. Бу диссертация тагын да баетылып, 1974 елда «Татар телендә сүз тәртибе» дигән исем белән аерым китап булып басылып чыга. Хезмәттә сүз тәртибе мәсьәләләре, җөмләнең актуаль кисәкләргә бүленеше, грамматик кисәкләрнең урнашу тәртибе, инверсия, сүз тәртибенә нигезләнгән стилистик чаралар җентекләп анализлана.

1972 елдан Ф.С. Сафиуллина университетның татар теле кафедрасында доцент вазифасында эшли башлый. Ул төрле елларда

«Тел белеменә кереш», «Татар әдәби теленең синтаксисы», «Татар теленең тарихи синтаксисы», «Татар сөйләм теле синтаксисы», «Татар теленең лексикологиясе», «Тәрҗемә теориясе һәм практикасы», «Чит аудиториядә татар теленә өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре», «Текст стилистикасы» фәннәреннән дәресләр алып бара. Ф.С. Сафиуллина күпьеллык гыйльми тикшеренүләре һәм укыту тәҗрибәсе нигезендә уку-укыту кулланмалары һәм программалар бастырып чыгара.

1989 елда Казан дәүләт университетында татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләр факультеты ачыла. 1992 елда «Чит телле аудиториядә татар теле» кафедрасы төзелә һәм Ф.С. Сафиуллина шул кафедраның мөдире итеп билгеләнә. Ул тиз арада кафедраны аякка бастыра, укытучылар туплый, аспирантлар әзерли, диплом эшләре яздыра, күпсанлы кулланмалар һәм дәреслекләр яза. Кафедра белән 70 яшенә – 2008 елга кадәр җитәкчелек итә.

Галимә җитәкчелегендә чит ил һәм Россия университетлары белән фәнни-тикшеренү элемтәләре булдырыла. Ул Берлинның Азат университетындагы Тюркология институты белән хезмәттәшлек итә, алман студентларына татар теленнән дәресләр бирә, Хельсинкида яшәүче фин татарларына лекцияләр укый. Моннан тыш, Казан университетына тел өйрәнү максаты белән килгән бик күп чит ил – Алмания, Швейцария, Англия, Америка, Корея, Кытай, Монголия, Япония һ.б. илләр вәкилләренә, шулай ук университетның башка бүлекләрендә укучы студентларга татар теле өйрәтә. Шул рәвешле, галимә татар теленең дәүләт теле буларак яшәешенә, татар телен чит тел сыйфатында өйрәтүгә үзеннән зур өлеш кертә.

1990 елларда Ф.С. Сафиуллина «Идел», «Татарстан» журналларында, «Известия Татарстана» газетасында татар теленә өйрәтү дәресләре бастырып килә һәм үзөйрәткечләр, сөйләүлекләр төзү эшенә алына. 1991 елда кыска вакыт эчендә татар телендә аралашу күнекмәләрен үзләштерергә теләүчеләр өчен «Татар теле: үзөйрәткеч» дип исемләнгән кулланмасын төзеп бастыра. Бу үзөйрәткеч күнегүләр һәм биремнәр комплексын үз эченә алган 50 дәрестән тора, кушымтада татарча-русча сүзлекчә, ике телдә фразеологик берәмлекләр, татар мәкальләре, халык иҗаты үрнәкләре һ.б. бирелә.

Галимә 1994 елда «Татарский язык в диалогах: учебное пособие для изучающих татарский язык» уку-укыту кулланмасын чыгара. Китап татар телен өйдә, курсларда, эштә өйрәнергә теләүчеләр өчен билгеләнгән. Аның төп үзенчәлеге – дәресләр җанлы сөйләмгә нигезләнгән диалоглар мисалында алып барыла. Югарыда телгә алынган уку-укыту кулланмалары, фәнни-методик яктан тагын да баетылып, коммуникатив биремнәр, күнегүләр белән тулыландырылып, 2000 елда «Татарский язык на каждый день. Самоучитель» дигән исем астында дөнья күрә.

Ф.С. Сафиуллина 1998 елда К.С. Фәтхуллова, Ә.Ш. Йосыпова, Л.М. Ризванова белән берлектә уку йортлары студентлары һәм югары

сыйныф укучылары, шулай ук татар телен өйрәнергә теләүчеләр өчен «Татар теле: Интенсив курс» дәреслеген әзерләп бастыра. Тәкъдим ителгән дәреслектә 30 татар теле дәресе, грамматика, сөйләм этикеты элементлары һәм дәресләрдә кулланылган лексик берәмлекләрнең татарча-русча сүзлекчәсе бар. Һәр тема үз эченә грамматик, лексик минимум һәм монологик, диалогик сөйләмне үстерү өчен күнегүләр сериясен ала.

2001 елда Ф.С. Сафиуллинаның дистә еллар татар телен чит тел буларак укыту тәҗрибәсенә таянып язылган «Татар телен өйрәнүнең фәнни-методик нигезләре» монографиясендә татар телен чит тел буларак укытуның теориясе һәм практикасына караган актуаль мәсьәләләр яктыртыла. Анда татар һәм рус телләренең чагыштырма-типологик характеристикасы, телне өйрәтүнең лингвистик һәм методик нигезләре, татар телен өйрәтүне педагогик технологияләр нигезендә оештыру, сөйләм эшчәнлеге төрләренә өйрәтү һ.б. проблемаларга зур игътибар бирелә.

Ф.С. Сафиуллина – күптөрле сүзлекләр авторы да: ул, татар лексикографиясендә беренчеләрдән булып, синонимнар, антонимнар, омонимнар сүзлекләре, татарча-русча, русча-татарча кесә сүзлекләре, татарча-русча фразеологик сүзлек, татарча-русча лингвистик терминнар сүзлеге, балалар өчен рәсемле сүзлекләр, инглизчә-татарча-русча уку-укыту сүзлеге һ.б. дөньяга чыгара. 1996 елда нәшер ителгән «Татарча-русча һәм русча-татарча кесә сүзлеге» бик күп тапкырлар басылып, әлегә кадәр китап кибетләрендә еш сатыла торган басма буларак билгеләнә.

Татар тел белемендә беренче тәҗрибә буларак, 1997 елда Ф. Сафиуллина, Л. Ризванова белән берлектә, «Татарча-русча антонимнар сүзлеге» һәм «Татар теленең омонимнар сүзлеге»н төзеп дөньяга чыгара. Ике сүзлектә дә меңәр пар сүз туплап бирелә. Антонимнарның мәгънәләре татар халык мәкальләре аша аңлатыла. Икенче сүзлектә исә төп игътибар омонимнарның лексик төрләренә бирелә, шулай ук аерым грамматик омонимнар да урын ала. Капма-каршы мәгънәле сүзләрне тагын да күбрәк туплап, галимә 2003 елда «Татарча-русча, русча-татарча антонимнар сүзлеге»н чыгара, ике елдан соң исә хәзерге татар поэзиясе һәм мәкальләрдән тупланган мисаллар нигезендә күләмле «Антонимнар сүзлеге» дөнья күрә.

1998 елда Ф. Сафиуллина «Татарча-русча тел белеме терминнары сүзлеге»н төзеп бастыра. 1953 елдан бирле әлеге өлкәдә сүзлекнең булмавы, бу вакыт эчендә күпсанлы яңа терминнарның барлыкка килүе моңа этәргеч бирә. Шул ук елда «Балалар өчен русча-татарча рәсемле сүзлек» тә чыгарыла.

Ш.С. Ханбикованың 1962 елда чыккан «Синонимнар сүзлеге»н нигез итеп алып, ике галимә 1999 елда шул ук исемдәге сүзлек бастыралар. 2 мең сүз, 400 оядан гыйбарәт нигез сүзлек бу басмада 25 меңгә якын мәгънәдәш сүзне берләштергән 4500дән артык ояга кадәр үстерелә.

2001 елда дөнья күргән «Татарча-русча фразеологик сүзлек», гомумән, татар тел белемендә беренче тапкыр эшләнә. Анда 16 меңнән артык татар фразеологизмы рус телендәге эквивалентлары белән бирелә.

Әлеге сүзлекләрдән тыш, Ф. Сафиуллина «Китапханәләр, нәшриятлар һәм мәгълүмат оешмалары хезмәткәрләре өчен русча-татарча сүзлек» (1998, төз. Г.Г. Габделганиева, Г.Г. Шаһиәхмәтова, И.Г. Һадиев һ.б.); «Татарча-русча тамырдаш сүзләр сүзлеге» (2007, төз. З.Н. Кириллова, Ә.Ш. Йосыпова, И.Г. Мифтахова) һ.б. сүзлекләрне төзүдә дә катнаша.

Гомумән, тел белән бәйле кайсы гына тармакны карасак та, лексикология булсын, лексикография, тәрҗемә гыйлеме, уку-укыту методикасы яки лингвофольклористика фәне – нигезендә тел галиме Ф.С. Сафиуллинаның фәнни-теоретик хезмәтләре ята. Шулай да ул – беренче чиратта, синтаксист галим. Ул татар әдәби һәм сөйләм теленең синтаксик яссылыкта үсеш-үзгәреш динамикасын өйрәнеп, аның төп тенденцияләрен билгели. Номинатив җөмләләр, күзаллаулы баш килеш, парцелляция, өстәлмәләр кебек синтаксик күренешләрне аерып алып өйрәнү иң элек булып аның хезмәтләрендә башлана.

Ф.С. Сафиуллина яңа юнәлешкә – сөйләм теле синтаксисына нигез сала һәм «аны аерым фән дәрәҗәсенә күтәрә». Аның 1978 елда басылган «Синтаксис татарской разговорной речи» дигән күләмле монографиясендә сөйләм теле синтаксисын чагылдырган кабатлаулар, раслау һәм инкяр җөмләләр, эллиптик төзелмәләр, семантик тартылу кебек күренешләр тикшерелә.

Галимәнең 1990 елда язылган «Развитие синтаксического строя татарского языка в советский период (простое предложение)» дигән монографиясе татар теленең синтаксик төзелешен, аның үсеш закончалыкларын аңлатып язылган саллы фәнни хезмәт булып тора һәм татар тел белемендә генә түгел, гомумән, тюркологиядә югары бәяләнә. Хезмәттә ким җөмләләр, эллипсис, аерымланган кисәкләр, кереш сүзләр, керешмәләр, номинатив һәм сүз җөмләләр, күзаллаулы баш килеш, инфинитив җөмләләрнең активлаша баруы билгеләнә, шул нигездә гади җөмләләрнең төзелеше үзгәрә баруы дәлилләнә.

1993 елда Ф.С. Сафиуллинаның «Текст төзелеше» дип аталган монографиясе басылып чыга. Тел һәм әдәбиятның синтезын чагылдырган әлеге уникаль хезмәттә текст оешу закончалыклары һәм текст стилистикасына караган төп мәсьәләләр үзәктә тора. Галимә, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, Ә. Еники, Г. Исхакыйның поэтик синтаксисын тикшереп, татар теленең синтаксик байлыгын, аһәңен, егәрле, хисле булуын күрсәтә.

Урау юллар аша булса да, 2000 елны «Развитие синтаксического строя татарского литературного языка, XX в.» дигән темага фәнни доклад рәвешендә якланган докторлык диссертациясе төрки тел гыйлемендә югары бәяләнә.

Ф.С. Сафиуллинаның синтаксис өлкәсендәге хезмәтләре, әлбәттә, болар белән генә чикләнми, ул татар һәм рус телләренең чагыштырма синтаксисын өйрәнүгә дә зур өлеш кертә. Аның М.З. Зәкиев, К.З. Зиннәтуллина, С.М. Ибраһимов, Л.К. Бәйрәмова белән берлектә язган монографияләре, дәреслек-кулланмалары тел белгечләре, тәрҗемәчеләр өчен бүгенге көндә дә әһәмиятле.

Пунктуациянең төп кануннарын, кагыйдәләрен, принципларын барлауда, камилләштерүдә дә Флера Сафиуллина зур эш башкара.

Флера Садрый кызы Сафиуллина – Татарстан Республикасының атказанган укытучысы, татар мәгарифен үстерүдәге зур хезмәтләре өчен Каюм Насыйри исемендәге премия иясе, Халыкара төрки академия әгъзасы. 2000 елда ул «Хезмәтем – бәхетем» номинациясендә «Ел хатын-кызы» исеменә лаек була һәм «Сөембикә» журналының «Сөембикә беләзеге» белән бүләкләнә. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы телләр турындагы Законны гамәлгә ашыру комитеты әгъзасы, «Сөембикә», «Ялкын», «Мәгариф» журналларының редколлегия әгъзасы була.

Фәндә үз мөстәкыйль карашын, үз мәктәбен булдырган галимәнең күпсанлы монографияләрендә һәм фәнни мәкаләләрендә тел гыйлеменең хәзерге көндә дә гаять актуаль булган мәсьәләләре күтәрелә. Флера Садриевна яшь буынның, аспирантларының гаҗәеп остазы да була. Аның җитәкчелегендә татар тел белеменең актуаль мәсьәләләре буенча дистәдән артык кандидатлык диссертациясе яклана. Ярты гасыр дәвамында югары уку йортларында, педагогик көллиятләрдә, мәктәпләрдә татар теле Ф.С. Сафиуллинаның дәреслекләре, методик ярдәмлекләре нигезендә укытыла.

Ф.С. Сафиуллина шәхси сыйфатлары ягыннан да күркәм кеше иде: ул бик кешелекле, намуслы, тырыш, ачык күңелле, юмарт һәм кунакчыл булуы белән аерылып торды. Ягымлы тавышы белән бик матур итеп сөйли, моңлы итеп җырлый иде. Юкка гына аны татар язучысы Рафаил Сибат «чәчәк телле галимә» [Фәнгә багышланган..., 2008, б. 77; Казан университетында..., 2013, б. 5] дип атамагандыр.

Казан дәүләт университетында Флера Садриевнадан дәресләр алган студентлар аны бик яхшы укытучы, фәнни җитәкче, оештыручы буларак беләләр. Сөйләме, үз-үзен тотышы, кешелекле мөнәсәбәте белән ул студентларны үзенә гашыйк итә белә торган кеше иде. Тирән белеме, киң күзаллавы, заманча фикерләре, матур тавышы һәр студентны фән дигән серле дөньяга өнди, ул оештырган «Тел бәйгеләре», татар теле олимпиадалары, танылган галимнәр белән очрашулар, төрле кичәләр һәр студентның күңелендә озак еллар буе саклаНЫр.

Ф.С. Сафиуллина – бик күп укытучыларның, язучы, мөхәррир, журналистларның, тәрҗемәчеләрнең, галимнәрнең укытучысы, остазы. Бүгенге көндә ул тәрбияләгән белгечләр, фәнни-педагогик кадрлар, татар зыялылары республикабызда, Россиядә һәм чит илләрдә төрле урыннарда, төрле җаваплы вазифаларда хезмәт куя, зурдан-зур

уңышларга ирешә. «Кеше китә, җыры кала», – диләр. Олуг галимә бакыйлыкка күчсә дә, аның фәнни-методик мирасы яшәр, якты истәлеге мәңге сакланыр. Ярты гомерен тел гыйлеменә багышлаган мөхтәрәм профессор Ф.С. Сафиуллинаның эшчәнлеге, һичшиксез, шәкертләре хезмәтләрендә дәвам итәр.

**Әдәбият**


Казан университетында – ярты гасыр. Казан: Ихлас, 2013. 220 б.

*Кириллова З.Н.* Төрки тел белеменең күренекле вәкиле Флера Сафиуллина // Научное наследие В.А. Богородицкого и современный вектор исследований Казанской лингвистической школы: тр. и матер. междунар. конф. (Казан. федер. ун-т, 14–17 окт. 2018 г.): в 2 т. / под общ. ред. К.Р. Галиуллина, Е.А. Горобец, Э.А. Исламовой. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2018. Т. 1. С. 104–108.

*Нәбиуллина Г.Ә.* Ф.С. Сафиуллинаның синтаксис өлкәсендәге эшчәнлеге // Казан университетында – ярты гасыр. (Казан университеты галиме профессор Ф.С. Сафиуллинаның якты истәлегенә багышлана). Казан: Ихлас, 2013. Б. 30–33.

*Сафиуллина Ф.С.* Синтаксис татарской разговорной речи. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1978. 150 с.

*Сафиуллина Ф.С.* Татар теле: Интенсив курс» / соавторлары – К. С. Фатхуллова, А. Ш. Юсупова, Л.М. Ризванова. Казан: Хәтер, 1998. 272 б.

*Сафиуллина Ф.С.* Татар теле: үзөйрәткеч. Казан: Татар. кит. нәшр. 1991. 445 б.

*Сафиуллина Ф.С.* Татар телен өйрәнүнең фәнни-методик нигезләре. Казан: Хәтер, 2001. 432 б.

*Сафиуллина Ф.С.* Татар телендә сүз тәртибе. Казан: Татар. кит.нәшр., 1974. 150 б.

*Сафиуллина Ф.С.* Татарский язык в диалогах: Учеб. пособие для изучающих татар. яз. Казань: Магариф, 1994. 221.

*Сафиуллина Ф.С.* Татарский язык на каждый день. Самоучитель. Казан: Хәтер, 2000. 419 б.

*Сафиуллина Ф.С.* Развитие синтаксического строя татарского языка в советский период (простое предложение). Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1990. 230 с.

*Сафиуллина Ф.С.* Сопоставительный синтаксис русского и татарского языков. Казань: Татар. кн. изд-во, 2007. 230 с. Соавторы: М.З. Закиев, С.М. Ибрагимов, К.З. Зиннатуллина.

*Сафиуллина Ф.С.* Текст төзелеше. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1993. 263 б.

Фәнгә багышланган гомер. Казан, Казан ун-ты нәшр., 2008. 213 б.



***Нәбиуллина Гүзәл Әмир кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Казан (Идел буе) федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты доценты*

***Кириллова Зоя Николаевна,***
*филология фәннәре кандидаты, Казан (Идел буе) федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты доценты*

УДК 792.071

***Г.И. Каюмова***

# ОЛЫ СӘХНӘ ЙОЛДЫЗЫ
## (Фатыйма Камалованың тууына 120 ел тулу уңаеннан)

В статье рассматривается сценическая деятельность народной артистки ТАССР, заслуженной артистки РСФСР Ф. Камаловой, актрисы с широким диапазоном, чьей творческой манере свойственны виртуозная техника перевоплощения, жизненная достоверность, точность и выразительность в отборе характерных деталей при создании того или иного образа.

**Ключевые слова:** Ф. Камалова, актриса, драма, комедия, сцена, образ.

The article examines the stage activity of the People's Artist of the TASSR, the Honored Artist of the RSFSR F. Kamalova, an actress with a wide range whose creative manner is characterized by a virtuoso technique of reincarnation, vital authenticity, accuracy and expressiveness in the selection of characteristic details when creating an image.

**Keywords:** F. Kamalova, actress, drama, comedy, stage, image.

Драма актрисасы, ТАССРның халык (1954), РСФСРның атказанган артисты (1957) Камалова (Хәлиуллина) Фатыйма Хәйрулла кызы 1903 елның 12 декабрендә Оренбург шәһәрендә йөкче Хәйрулла агай белән Газзә ханым гаиләсендә дөньяга килә. Алар вак һөнәрчеләр шәһәре саналган Оренбург читендәге бер урамда иске генә йортта фатир алып көн күрәләр. Гаиләләре ишле, тормышлары авыр була. Фатыйманың әнисе Газзә дә төрле эшләр башкара: байларда кер дә юа, асрау булып та хезмәт итә, аларның балаларын да карый. Тормыш авыр булганлыктан, Фатыймага да өлеш чыга, билгеле. Кул арасына керә башлауга, ул әнисенә капчыклар ямаша, эне-сеңелләрен караша, йорт эшләрендә булыша. Кечкенәдән китап укырга ярата, сәнгатькә гашыйк була... Аның бала вакыты, үсмер чагы һәм сәхнә эшчәнлегенең тәүге еллары Оренбургта үтә. Оренбург театрында күп кенә талантлы профессиональ артистлар арасында эшләү яшь актрисаны чыныктыра, иҗат тәҗрибәсенең көннән-көн ныгуына көчле йогынты ясый. Гомер юлын Камаллар гаиләсе белән бәйләгәч, аңа сәхнә эшчәнлегендә ире Габдулла Камал I һәм аның абыйсы Г. Камал зур таяныч була, һәм бу аны иҗат эшенә тагын да рухландыра. 1920 еллар ахырында Оренбург һәм Урта Идел тирәләрендәге шәһәрләрдә, авылларда яшәүче театр сөючеләр арасында Ф. Камалова үзен «театр сәнгатендә реалистик юнәлешне тирән чагылдыручы сәләтле артистка итеп танытып өлгерә» [Рахманкулов, Галимова, 1964, б. 149].

Сәхнә эшчәнлеген 1918 елда Оренбургта яшьләр тарафыннан оештырылган татар драма түгәрәгендә башлап җибәргән Ф. Камалова шул рәвешчә 1919–1922 елларда – Оренбург «Шәрык» театрында, 1922–1923 елларда – Казанда Татар дәүләт театрында (хәзер Татар

дәүләт академия театры), 1923–1925 елларда – Әстерхан татар театрында, 1925–1927 елларда – Ташкентта Үзбәк музыкаль-драма театрында, 1933–1936 елларда – Оренбург татар драма театрында, 1927–1928 һәм 1939–1963 елларда Татар академия театрында эшли. Ул үзенең сәхнә эшчәнлегендә татар театрының Габдулла Кариев, Зәйни Солтанов, Габдулла Камал I, Бари Тарханов, Гөлсем Болгарская, Нәгыймә Таждарова, Әшрәф Синяева, Нәфига Арапова кебек беренче «карлыгач»ларының реалистик традицияләренә гомере буе тугры була.

Ф. Камалованың сәхнә эшчәнлеген яктырткан хезмәтләр юк диярлек, булганнары да, нигездә, 1950–1960 елларда матбугатта актрисаның юбилейлары уңаеннан басылган мәкаләләр, шулай ук Ш. Рахманкуловның аның сәхнә иҗатына багышланган кечкенә күләмле китабы (1965) белән генә чикләнә. Сәхнә таланты, башкару осталыгы белән яшь буын артистларга үрнәк актрисаларның берсе буларак, аның иҗаты бүген дә актуальлеген югалтмый. Бу исә актрисаның якынлашып килүче юбилее хөрмәтеннән, югарыда билгеләп үтелгән чыганакларга, шулай ук Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының 100 еллыгы уңаеннан дөнья күргән саллы хезмәткә (2009) һәм башка язмаларга таянып, ихтирамга лаек иҗатын кабаттан барлау ихтыяҗы тудырды.

Ф. Камалова – киң диапазонлы, күпкырлы актрисаларның берсе; милли характерны гәүдәләндергән мәгънәле, тирән эчтәлекле рольләр башкару, комик образлар тудыру остасы. Аның башкаруына тормышчанлык, ышандыру көче хас; образ иҗат иткәндә үзенчәлекле һәм мәгънәле детальләр сайлый белә, персонажның рухи дөньясына тирәнтен үтеп кереп, аның хис-кичерешләрен ачык яктырта. Образга керүнең «виртуоз техникасы, сөйләү осталыгы, алымнар байлыгы һәм төрлелеге актрисаның һәр чыгышын уңышлы театраль күренешкә әверелдерә» [Татар энциклопедиясе, 2012, б. 241]. Аның иҗат мирасын Биби, Гөлҗиһан (Г. Камал. «Бәхетсез егет», «Банкрот»), Мәрфуга (К. Тинчурин. «Зәңгәр шәл»), Гайнавал, Ханзафа, Сәхибә (Т. Гыйззәт. «Ташкыннар», «Изге әманәт»), Мәймүнә, Сәлимә (М. Әмир. «Миңлекамал», «Тормыш җыры»), Әйшә (Н. Исәнбәт. «Зифа»), Ниса (Һ. Такташ. «Югалган матурлык»), Җиһан (У. Хаҗибәков. «Аршин мал алан»), Кабаниха, Пелагея Егоровна (А. Островский. «Яшенле яңгыр», «Ярлылык гаеп түгел»), Нәгыймә (Ш. Камал. «Хаҗи әфәнде өйләнә»), фрау Миллер (Ф. Шиллер. «Мәкер вә мәхәббәт»), Елизавета (Б. Полевой. «Сүнмәс ялкын»), Харитонова («Б. Лавренёв. Диңгездәгеләр өчен») һ.б. үзенчәлекле рольләр тәшкил итә.

Актриса иҗатының башлангыч чорында сәхнәдә, нигездә, уңай образларны гәүдәләндерә. Тәүге роле – ике яшь йөрәкнең ихлас мәхәббәтен һәм бу мәхәббәтнең мәгълүм тормыш шартларында фаҗигалы язмышын яктырткан «Галиябану» (М. Фәйзи) драмасы буенча куелган спектакльдә (1919, 1922) Галиябану образы. Фатыйма бу рольне бик уңышлы башкара һәм киң җәмәгатьчелекнең их-

тирамын яулый. Шул чор вакытлы матбугатында аның уены югары бәяләнә, киләчәктә өметле актриса булачагы турында үтемле фикерләр әйтелә. Яшь актрисаның театр сәхнәсендә Галиябану образын тормышчан һәм табигый итеп гәүдәләндерү осталыгын Ш. Камал, М. Җәлил кебек мәшһүр әдипләр, шулай ук Губерна халык мәгарифе бүлеге мөдире Ф. Хәсәнов та билгеләп үтәләр. [Рахманкулов, Галимова, 1964, б. 150]. Ш. Камалның «Козгыннар оясында» әсәре буенча сәхнәләштерелгән спектакльдә (1922) ул Фәхрия ролен башкара. «Фәхрия – энисе белән кешеләргә керләр юып, хәләл көче белән көн күрүче кыз. Ул ярлы шахтёр егетне сөя һәм саф мәхәббәтенә тап төшерми. Ирекка омтылучы, саф күңелле Фәхрия образын тамашачыга җиткерү өчен мин бик тырышып эшләдем һәм теләгемә ирештем: Фәхрияне тамашачылар җылы кабул иттеләр» [Камалова, 1965, б. 2], – дип искә ала актриса. Чыннан да бу рольне Фатыйма шул дәрәҗәдә камил башкарган булса кирәк, әсәрнең авторы, үзе аңа хөрмәтен һәм рәхмәтен белдереп, драмасының кульязмасын бүләк итә. Анда: «...Сез әсәремнең йолдызы булдыгыз. Киләчәктә Фәхрия образы шикелле күп образлар иҗат итүегезгә ышанып, кабилиятегезгә, талантыгызга багышлап яңа әсәр язарга сүз биреп, ихтирам белән баш иеп, Шәриф Камал» [Камалова, 1965, б. 2], – дип язылган була. Инглиз драматургы У. Шекспирның «Отелло» трагедиясе буенча куелган спектакльдәге (1922) Дездемона роле тәҗрибә туплау җәһәтеннән актриса өчен зур мәктәп булып тора. Ф. Камалова сәхнәгә заман идеяләре белән рухланып яшәүче, гаделлек, хаклык өчен көрәшүче, яктылыкка омтылган уңай образларны да алып чыга һәм сәнгатьчә югарылыкта гәүдәләндерә. Шундыйларның берсе – А. Островскийның «Ярлылык гаеп түгел» комедиясендәге Пелагея Егоровна образы. Ул – тормыш тарафыннан кыерсытылган, «самодур» сәүдәгәрләр мохитендә иза чиккән, үз кызына ана булу хокукыннан мәхрүм ителеп кимсетелгән, шулай да кешелек сыйфатларын җуймаган, киң һәм йомшак күңелле, ачык йөзле ана. Дини тыюлардан куркып, иренең күз карашыннан ук өркеп торган хатын, кызын сөйгән егете белән кавыштырып бәхетле итү өчен, аларның саф хисләренә киртә булып калыккан иренә каршы күтәрелергә җөрьәт итә. Актриса «шушы басынкы, йомыкый хатында кешелек горурлыгының баш калкытуын, шул хиснең яшәп килүче тәртипләргә каршы көчле ризасызлыкка кадәр үсеп җитүен» [Рахманкулов, 1965, б. 34] оста яктырта. Г. Насрыйның «Кадерле минутлар» әсәре буенча куелган спектакльдә Ф. Камалова башкарган Мәрфуга – шулай ук уңай образларның берсе. «Миңа үз гомеремдә бик күп ана образлары өстендә эшләргә туры килде. Ә менә Мәрфуга – бөтенләй башка, йөрәккә якын, киң күңелле, һәрберебезнең олы ихтирамына лаек ана. Бу образны мин яшьләрнең уңышларын уртаклашучы, киләчәкләре турында кайгыртучы олы йөрәкле ана, яшь буынны Ватаныбызга тугрылыклы, чын патриот итеп тәрбия итә белүче безнең заман анасы итеп күрсәтергә тырыштым» [Рахманкулов, 1965, б. 34], – дип яза актриса. Сәнгатьчә

камил эшләнешле, идея-эстетик үзенчәлекләре белән аерылып торган Луиза (Ф. Шиллер. «Мәкер вә мәхәббәт»), Амалия (Ф. Шиллер. «Юлбасарлар»), Сәрвәр (К. Тинчурин. «Сүнгән йолдызлар»), Гөлйөзем (Т. Гыйзззәт. «Наёмщик») образлары шулай ук актрисаның уңай образлар галереясын тулыландыра.

Мәгълүм булганча, Ф. Камалова ире – режиссёр һәм актёр Габдулла Камал белән берлектә үзбәк милли театрын үстерүгә дә зур өлеш кертәләр. Бу уңайдан, актрисаның, үзбәк телен өйрәнеп, шул телдә үзбәк мәдәнияте үсешендә гаять зур урын тоткан Хәмзә Хәкимзадә Ниязи әсәрләреннән «Бай һәм батрак» пьесасы буенча куелган спектакльдә Җәмилә, «Мәйсәрәнең хәйләсе» комедиясендәге Мәйсәрә, казакъ драматургы М. Әүэзовның «Айман-Чулпан» драмасы буенча сәхнә күргән спектакльдә Тәңкә кебек баш рольләрне уңышлы башкаруы турында да әйтеп китү урынлы булыр. Ташкентта яшәгәндә Камаллар гаиләсе белән Хәмзә арасында зур дуслык урнаша. Иҗат омтылышларының уртаклыгына нигезләнгән бу дуслык озак еллар дәвам итә. Үз халкының театр сәнгатен алга җибәрүдә булышлык күрсәткән татар артистларына Хәмзә зур хөрмәт белән карый. Ф. Камалова һәм Габдулла Камал Үзбәк театрында Үзбәкстан ССРның халык артистлары Алим Турдыев, Маннон Уйгур, Ятим Бобаджанов, СССРның халык артистлары Шукур Бурханов, Алим Ходжаев белән бергә хезмәт куялар [Гобәйдуллин, 1963].

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры (Татар академия театры) сәхнәсендә Ф. Камалова күп кенә оригиналь һәм тәрҗемә әсәрләр буенча куелган спектакльләрдә төп рольләрне башкара. Ул иҗат иткән образлар спектакль ансамблен тулыландырып торулары, тирән логикалы булулары, төгәл эшләнешләре, реаль җирлектә чишелеш алулары белән зур әһәмияткә ия. 1922–1923 елларда актриса Казан сәхнәсендә Сәрвәр (К. Тинчурин. «Сүнгән йолдызлар»), Балдыз (Г. Кутуй. «Балдызкай»), Күгәрчен (Г. Кутуй. «Күк күгәрчен») кебек җитди образлар иҗат итә. Үз вакытында матбугат битләрендә бу образларның сәнгатьчә башкарылуы хакында күп языла.

Ф. Камалова тудырган хатын-кыз образлары галереясында тискәре типлар зур урын алып тора. Алар арасында мал колы булган абыстайлар һәм карчыклар, азгын күңелле сәүдәгәр хатыннар, караңгылык, томаналык корбаннары булган хатын-кыз образлары бар. Шуларның кайберләренә тукталып үтик. М. Горькийның «Васса Железнова» драмасы буенча куелган спектакльдә (1937, 1939) Ф. Камалова Васса образы аша «иҗтимагый формацияләрнең алышынуы чорында буржуаз сыйныфның эчтән череп таркалу сәбәпләрен ышандырырлык итеп күрсәтә» [Рахманкулов, 1965, б. 28]. Күп еллар дәвамында бар энергиясен байлык туплауга сарыф иткән пароход компаниясе хуҗасы, акчалы һәм абруйлы, нык холыклы Васса Железнова гомеренең заяга узуына яхшы төшенә. Ул үзе башлаган эшне дәвам итәрдәй кешеләр юклыгын аңлый: балалары, рухи яктан «гарип» булу сәбәпле, эстафетаны кабул итеп ала алмыйлар. Шулай да бирешергә

теләми, юлында очраган каршылыклар белән үзенчә көрәшә, ләкин, тарихи-социаль үзгәрешләргә бәйле рәвештә «үлемгә» хөкем ителгән сыйныф вәкиле буларак, бу ханым көчсез дә, мескен дә. Ф. Камалова, «әлеге персонаж язмышындагы һәм характерындагы күпкырлы һәм каршылыклы сыйфатларны зур осталык белән ачып, татар театрын үзенчәлекле бер образ белән баета» [Рахманкулов, 1965, б. 28]. Шушы роле белән актриса 1937 елда Сталинград шәһәрендә унлап коллектив катнашында уздырылган конкурста беренче премияне ала. А. Островскийның иҗтимагый яңгырашы белән татар тормышы җирлегенә аваздаш, шул чорның социаль каршылыкларын, ачы фаҗигаларын ачык яктыртучы «Яшенле яңгыр» пьесасы буенча куелган спектакльдә (1944) Ф. Камалова башкарган «караңгылык патшалыгы» хуҗасы Кабаниха явызлыгы, томаналыгы белән аерылып тора. «Камалова-Кабаниханың хәрәкәтләре алдан ук уйланылган, ул үз корбанын салкын кан белән эзәрлекли, аның канын акрынлап суыра» [Рахманкулов, 1965, б. 30]. Ш. Рахманкулов фикеренчә, Васса Железнова белән Кабаниха образлары арасында эчке бер бәйләнеш бар. Алар икесе дә бер үк сыйныф вәкилләре, икесенең дә максатлары уртак. Аерма шунда ки, бу ике образ ике чорның социаль катлавын гәүдәләндерә. Кабаниха ышанычлырак җирлектә тора, ул әле үзен дөньяның чын хуҗасы итеп тоя [Рахманкулов, 1965, б. 29]. «Артистка Кабаниха образын спектакльдән спектакльгә үстерә, тулыландыра барды. Нәтиҗәдә, ул «караңгылык патшалыгы»ның иң катлаулы, иң куркыныч вәкиленә кадәр күтәрелде. Ул тамашачы алдына иске тормышның, домостройчылыкның үзенә күрә бер теоретигы булып килеп басты» [Рахманкулов, 1965, б. 30], – дип ассызыклап үтә автор. М. Хәсәнов сүзләрендә дә шуңа охшаш фикер уздырыла: «Кабаниха образын тудыру артистканың иҗатында яңа бер этапка күчү чоры булды. «Караңгылык патшалыгы»ның төп вәкиле, явызлыкның чигенә җиткән һәм яңалыкны җаны-тәне белән күралмаучы бу образны талантлы артистка яңа бер үзенчәлек белән онытылмаслык итеп гәүдәләндерде» [Хәсәнов, 1954, б. 119].

Татар сәхнәсенә классик драматургиянең реалистик һәм гуманистик принципларын алып килгән һәм дәвам иткән Г. Камалның милли драматургия һәм театр үсешендә аерым бер урын алып торган, аң-белем, дөрес тәрбия, хакыйкый кыйммәтләр зарурлыгын яктырткан, «татар буржуасы көнкүрешендәге черек якларны бөтен каршылыклары эчендә күрсәтеп, тормышны аяусыз бер кыюлык белән, чын дөреслегендә, үткен конфликтлы итеп ачып биргән» [Исәнбәт, 1955] «Бәхетсез егет» пьесасы буенча куелган спектакльдә (1955) Ф. Камалова яучы карчык Биби ролендә гаҗәеп оста уйный. Актриса башкаруында бу образ яңача шәрехләнә, аның социаль асылы тулырак ачыла, «әүвәл үзе фахишә, ә хәзер исә шул фахишәләр акчасына яшәгән хатынның бар тәрҗемәи хәле күп мәгънәле, тәэсирле итеп күрсәтелә. Бибинең үз-үзен тотышы, ым-ишарәләре, сөйләме табыш алу тәмам бозып бетергән хатынны күз алдына китерә дә куя» [Галиәсгар

Камал исемендәге.., 2009, б. 35]. Спектакльнең премьерасыннан соң драматург Н. Исәнбәт шул уңайдан болай дип яза: «Бу картинаны баеткан тагын бер яңалык булса, ул – Фатыйма ханым Камалованың Биби карчык ролен башкаруы. Мәгълүм ки, әсәрдә бу роль бик кечкенә булып, анда ул гади генә итеп дөнья хәле сөйләшеп утырудан узмый. Ф. Камалова бу рольне типик бер тәтәй дәрәҗәсенә күтәрә алган һәм ул аны танымаслык оста, чынлыклы итеп башкара» [Исәнбәт, 1955]. «Шундый үткен, шундый хәйләкәр, шундый оста яучы... Акча күрсә, ул берни алдында тукталып калмый: типтерә, байларның кәефен күтәрә, җырлый, кирәк икән, гармунын да уйный, авызыннан тәтенен чыгарып, ашардай булып гаптәшенең күзенә төбәлә. Әнә шулай тышкы яктан да кешелек сыйфатларын җуйган иттереп бирү актрисага образны тулысынча ачып бетерергә, тамашачыда аңа карата нәфрәт уятырга мөмкинлек тудыра» [Татар совет театры, 1975, б. 222]. Шул рәвешчә, театр сәхнәсендә ачык сатирик буяулар белән гротеск дәрәҗәсендә күпертеп күрсәтелгән әлеге образ «буржуаз җәмгыятьне аяусыз гаепләүгә юнәлдерелгән» [Галиәсгар Камал исемендәге.., 2009, б. 35], тамагын туйдырыр өчен «алла юлында» йөрүче Биби «капитализм дөньясының кызганыч корбаны булып күз алдына килеп баса» [Рахманкулов, 1965, б. 32]. Спектакльне шул чор тәнкыйте «милли классиканы яңача үзләштерүдәге мөһим, мәгънәле адым» [Галиәсгар Камал исемендәге.., 2009, б. 35], дип бәяли.

Тискәре образларны гәүдәләндергәндә, Ф. Камалова үткен сәхнә алымнарыннан иркен файдалана, теге яки бу образның эчке дөньясын камил ачу максатында төгәл штрихлар, дөрес интонация сайлый белә. Актрисаның мещанлык сыйфатларын яхшы ук үзләштергән тар карашлы, сай фикерле Кадрия (Ф. Хөсни. «Еллар һәм юллар»), Әйшә (Н. Исәнбәт. «Зифа»), эчкерле һәм мәкерле Мәймүнә (М. Әмир. «Миңлекамал») образлары шулай ук тормышчан оста эшләнешләре белән аерылып торалар.

Бөек рус язучысы Н. Гогольнең «иң мөкәммәл» әсәрләреннән саналган, «ул замандагы рус чиновникларының наданлыкларыннан, ришвәтчелекләреннән, ваклыкларыннан ачы көленгән, аларның һәрбер сәлби[1] яклары ачып бирелгән» [Кәрам, 1967, б. 105] «Ревизор» комедиясендәге (1949) Анна Андреевна ролен Ф. Камалова сәхнәдә үтемле һәм ышандырырлык итеп башкара. Н. Исәнбәтнең «Хуҗа Насретдин» комедиясе буенча куелган спектакльдә (1940) Хуҗаның хатынын уйнаган актрисаның Гөлбануы, еш кына үзалдына мыгырданып йөрсә дә, үзенчә мөлаем, юаш, акыллы, ирен ярата-хөрмәт итә торган яхшы кеше буларак ачыла, «гадилеге, һәр сүзгә балаларча ышануы белән истә кала» [Кумысников, 1958]. Г. Камалның «байлык өчен шашкан бөтен сәүдәгәрләр дөньясының, буржуаз җәмгыятьнең берсеннән-берсе ямьсез күренешләрен күз алдына бастырган» [Галиәсгар Камал исемендәге.., 2009, б. 43] «Банкрот» комедиясе буенча

[1] Сәлби – кире, тискәре.

спектакльдә (1944) ул гәүдәләндергән Гөлҗиһан образы заман кимчелекләрен, аерым бер чор кешеләре холкына хас китеклекләрне ачуга булышлык итә. М. Хәсәнов билгеләп үткәнчә, Ф. Камалованың, «артистка буларак, иң төп уңай сыйфатларының берсе – аның үзе эшләгән образларының характерын дөрес һәм аңлаешлы итеп бирүе...» [Хәсәнов, 1954, б. 119]. Ул, Ф. Камалова уенындагы уңай якларның берсе итеп, хәрәкәт белән сүзләр, хис-кичерешләр арасындагы бердәмлекне дә ассызыклап үтә: «Аның хәрәкәтләре һәрвакытта да образның эчке тойгылары, хисләре белән бер үк ритмда, бер үк темпта була, образның эчке дөньясына тулысынча буйсына» [Хәсәнов, 1954, б. 119]. Актрисаның югарыда каралган рольләреннән чыгып, бу сүзләрнең дөреслеккә туры килүе турында ышанып әйтергә мөмкин.

Оптимист рухлы, тормышны, кешеләрне яратучы талантлы актриса Ф. Камалова җәмәгать эшләрендә дә актив катнаша. Бөек Ватан сугышы елларында шефлык комиссиясе рәисе булып эшли, хезмәт ияләре тарафыннан рәттән дүрт тапкыр Казан шәһәр советы депутаты итеп сайлана. Ф. Камалова белән бер театрда 1949 елдан эшли башлаган һәм шушы эштә үз алдына «аннан үрнәк алырга дигән бурыч куйган» артистка Асия Хәйруллина Фатыйма ханымның халык мәхәббәтенә, аның тирән хөрмәтенә ирешүенең төп сәбәбен «үз эшен сөючән талантлы артистка» булуында, «үзе иҗат иткән образларның эчке дөньясын дөрес ача» белүендә, «сәхнә эшенә бөтен көчен, бөтен дәртен куеп, эшеннән тәм табып, янып-көеп эшләве»ндә күрә [Хәйруллина, 1963, б. 19].

Танылган драма актёры һәм режиссёр, профессиональ татар театрына нигез салучыларның берсе – Габдулла Камалның (Камал I) тормыш иптәше, сәхнә юлдашы Ф. Камалова 1974 елның 9 гыйнварында вафат була. Татар сәхнәсендә ул тудырган образ-характерлар тирән мәгънәле, бай эчтәлекле, күңел җылысын биреп психологик яктан нечкә эшләнгән булулары, холык-фигыль үзенчәлекләре белән истә кала һәм актрисаның иҗат йөзен билгели, аның якты исемен мәңгеләштерә.

### Әдәбият

*Арсланов М. Г.* Татар театры: энциклопедик сүзлек-белешмә. Казан: «Заман» нәшр., 2014. 584 б.

Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры. Йөз ел. 2 томда. Спектакльләр / авт.-төз.: Л. Шакирҗан, Г. Гыйматова. Казан: Заман–Татар. кит. нәшр., 2009. 1 т. 568 б. = Татарский государственный академический театр имени Галиасгара Камала. Сто лет. В 2-х томах. Спектакли / авт.-сост.: Л. Шакирзян, Г. Гиматова. Казань: Заман–Татар. кн. изд-во., 2009. Т. 1. 568 с.

*Гобәйдуллин Х.* Дуслык хисләре белән рухланып (театр тарихыннан) // Социалистик Татарстан. 1963. 16 октябрь.

*Илялова И.* Г. Камал театры артистлары: Биогр. белешмәлек = Артисты театра им. Г. Камала: Биогр. справочник. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. 334 б.

*Исәнбәт Н.* «Бәхетсез егет» // Совет Татарстаны. 1955. 29 гыйнвар.

*Камалова Ф.* Истә калганнардан // Азат хатын. 1965. № 5. Б. 2.

*Кәрам Г.* Артист Кариев иҗаты турында. «Ревизор» // Габдулла Кариев турында истәлекләр / төз. Хәсән Гобәйдуллин. Казан: Татар. кит. нәшр., 1967. Б. 99–106.

*Кумысников Х.* Актриса из народа // Советская Татария. 1963. 24 декабря.

*Кумысников Х.* Фатыйма Камалова // Совет Татарстаны. 1958. 16 март.

*Рахманкулов З., Галимова Ш.* Сәхнәдә кырык ел // Совет әдәбияты. 1964. № 2. Б. 149–150.

*Рахманкулов Ш.* Олы иҗат юлы // Социалистик Татарстан. 1963. 24 декабрь.

*Рахманкулов Ш.* Фатыйма Камалова. Казан: Татар. кит. нәшр., 1965. 38 б.

Татар совет театры (очерклар) / редкол.: Б. Гыйззәт, И. Илялова, Һ. Мәхмүтов, А. Әхмәдуллин. Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. 495 б. (ил. белән 528 б.).

Татар энциклопедиясе: 6 томда / баш мөх. Ә.М. Мазһаров, җаваплы мөх. Г.С. Сабирҗанов. Казан: «ТР ФАнең Татар энциклопедиясе ин-ты» дәүләт учреж-се, 2012. 3 т.: К–Л. 716 б.

*Хәйруллина А.* Фатыйма Камалова // Азат хатын. 1963. № 12. Б. 18–19.

*Хәсәнов М.* Сәхнә остасы // Совет әдәбияты. 1954. № 1. Б. 118–120.

***Каюмова Гөлия Илдус кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Татар энциклопедиясе*
*һәм төбәкне өйрәнү институты Энциклопедистика үзәгенең*
*өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 82-1(=512.145)

***Ф.И. Габидуллина***

## ӘДӘБИЯТ ФӘНЕНӘ ҖИТДИ ӨЛЕШ
## (Ә.М. Закирҗановның «Туфан Миңнуллин драматургиясе» китабына (Казан: ТӘһСИ, 2022) бәяләмә)

В работе дается оценка новой монографии литературоведа А.М. Закирзянова. Определена концептуальная основа исследования, сделан последовательный обзор содержания книги. Автор разделяет творческое наследие драматурга Т. Миннуллина на три этапа, и анализирует его в контексте с литературным процессом. В статье дается высокая оценка монографии, указывается ее значительный вклад в литературоведение.

**Ключевые слова:** татарская драматургия, литературный процесс, этап, традиция, новаторство, форма, прием.

The paper evaluates the new monograph of literary critic A.M. Zakirzyanov. The conceptual basis of the study is defined, a consistent review of the book’s content is made. The author divides the creative heritage of the playwright T. Minnullin into three stages and analyzes it in the context of the literary process. The article gives a high assessment of the monograph, indicates its significant contribution to literary criticism.

**Keywords:** Tatar drama, literary process, stage, tradition, innovation, form, reception.

Туфан Миңнуллин (1935–2012) исеме татар җәмәгатьчелегенә яхшы таныш булып, шәхесе, күпкырлы эшчәнлеге һәрдаим зур кызыксыну уята. Әдипнең вафатыннан соң ун елдан артык вакыт үтсә дә, аның Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышларындагы чыгышлары, газета-журналлардагы язмалары, истәлек-хатирәләре, бай иҗади мирасы әдәби җәмәгатьчелек теленнән әле дә төшми. Алай гына да түгел, язучының тирән мәгънәле, фәлсәфи эчтәлекле фикерләре, афоризм буларак, теге яисә бу мәсьәләне ачыклау, дәлилләү, нәтиҗә ясау өчен таяныч-терәк буларак кулланыла. Шуңа да олы әдип, фәлсәфәче, иҗтимагый эшлекле Т. Миңнуллинның тормышын һәм иҗатын өйрәнү, күпкырлы эшчәнлегенең үз заманы һәм бүгенге көн өчен әһәмиятен ачыклау, татар сәхнә әдәбияты үсешенә керткән өлешен бәяләү заман таләбе булып тора. Әдәбият галиме Ә.М. Закирҗановның «Туфан Миңнуллин драматургиясе» дип исемләнгән монографиясенең кыйммәте әнә шуның белән аңлатыла да. Автор әлеге хезмәткә җитди әзерлек белән килә. Галимнең драматург иҗатын төрле яклап яктырткан мәкаләләре, конференцияләрдә ясаган чыгышлары күпләребезгә таныш [Закирҗанов, 2019; Закирҗанов, 2019; Закирзянов, Хабутдинова, 2016; Zakirzyanov, Ghilazov, 2016]. Монографиядә әдипнең бай иҗатын үзара тыгыз бәйләнештә һәм бөтенлектә, үсеш-үзгәреш этапларына бәйле тикшерү максат итеп куела.

Аның концептуаль нигезен Т. Миңнуллинның әдәби мирасын XX гасырның икенче яртысы һәм XXI гасыр башы сәхнә әдәбияты үзенчәлекләренә нисбәтле бәяләү аша сәнгати фикерләү үзенчәлеген ачу тәшкил итә. Бу исә әдипнең төрле чорда иҗат ителгән пьесаларын әлеге дәвер татар драматургиясендә барган әдәби-эстетик эзләнүләр яссылыгында өйрәнү, алып килгән яңалыгын, табышларын ачыклау мөмкинлеге бирә.

Монографиянең кереш өлешендә хезмәтнең максат-бурычлары, драматург иҗатының өйрәнелү дәрәҗәсе, фәнни-гамәли яңалыгы билгеләнү белән бергә, әдип шәхесен аңларга, бәяләргә ярдәм иткән бай материал урын ала. Язучының истәлекләренә, көндәлекләренә нигезләнеп, безнең каршыда аның тормыш юлы, олы иҗатка килүе, аннан да бигрәк шәхес буларак формалашуына йогынты ясаган кешеләр, хәл-күренешләр ачыла. Булачак язучының балалык еллары, әти-әнисенең аңа тәэсире, күңел төпкелендә сакланып калган хатирәләре, шулай ук олы тормыштагы беренче адымнары, чирәм җирләрне эшкәртүдә катнашуы һ.б. фәнни хезмәткә лиризм, публицистик аһәң алып килә, укучыны язучы шәхесенә якынайта. Ә.М. Закирҗанов фикеренчә, Т. Миңнуллинның 50 елга сузылган иҗаты чорның иҗтимагый, мәдәни шартларына, әдәбиятның эчке закончалыкларына нисбәтле үзгәрешләр кичерә. Алар тема-мотивларда, күтәрелгән проблемаларда, чишелеш юлларын эзләүдә, шул максатта кулланылган алым-чаралар төрлелегендә һ.б. чагылыш таба. Әнә шулардан чыгып, әдипнең бай мирасы өч этапка бүлеп тикшерелә һәм хезмәттә аерым бүлекләр буларак урын ала.

«1960–1980 еллар татар драматургиясендә яңа тенденцияләр һәм Т. Миңнуллин иҗаты» дип аталган беренче бүлектә драматургның башлангыч иҗат тәҗрибәләреннән алып тарихи шәхесләрне сурәтләүгә кадәр үткән юлы тикшерелә. Т. Миңнуллин сәхнә әдәбиятына «Хрущев җепшеклеге» дулкынында килә. Җәмгыятьтәге үзгәрешләр, идеологик басымның кимүе, билгеле бер дәрәҗәдә фикер төрлелегенә юл ачылу шартларында мәдәни тормышта җанлану, әдәбиятның сыйфаты үзгәрү күзәтелә. Ул «милли һәм гомумкешелек кыйммәтләрен яклау, халыкның яшәү рәвешен, традицияләрен, гореф-гадәтләрен саклау һәм шулар аша чорның актуаль мәсьәләләрен киң җәмәгатьчелек алдына кую һәм аларны бай сәнгати алымнар ярдәмендә сурәтләү» [Закирҗанов, 2022, б. 27] белән бәйле була. Хезмәттә чорның танылган драматурглары Х. Вахит, А. Гыйләҗев, Ш. Хөсәенов, Ә. Баян, Р. Хәмид пьесалары мисалында татар сәхнә әдәбиятында реалистик сурәтлелекнең өстенлек алуы, аның тормышчанлык юнәлешендә үсә барып, кеше шәхесенә игътибарның артуы һәм шуңа бәйле заман типлары, үзенчәлекле характерга ия геройлар мәйданга чыгу дәлилләнә. 1960–1980 еллар драматургиясендә күзәтелгән сыйфат үзгәрешләренең нигезен татар милли яшәешенә игътибар арту, шул сәбәпле милли тематиканың көчәеп китүе, шәхес һәм җәмгыять мөнәсәбәтенең моңа кадәр читтә калып килгән якларын сурәтләү тәшкил итә. Бу исә

пьесалардагы конфликтның тирәнәюенә һәм баюына китерә. Автор фикеренчә, драматургларның эзоп теле ярдәмендә җәмгыятьтәге каршылыкларны ачуы бу чор әдәбиятындагы җитди яңалыкларның берсе булып тора. Монографиядә әлеге еллар татар әдәбиятында көчәеп киткән романтик юнәлешнең сәнгати үзенчәлекләре аерып чыгарыла һәм И. Юзеев, Ә. Баян, Ә. Гаффар пьесаларын бәяләү аша кешенең эчке дөньясына, рухи яшәешенә игътибар арту ассызыклана.

Ә.М. Закирҗанов билгеләп үткәнчә, Т. Миңнуллин башлангыч тәҗрибә чорын бик тиз үтеп, сәхнәгә менгән «Нигез ташлары», «Миләүшәнең туган көне» пьесалары яшәешнең җитди проблемаларын уңышлы тотып алуы, тормышчан конфликты һәм башкаларны кабатламаган геройлары белән игътибарны җәлеп итә. Алдагы елларда драматургны киң җәмәгатьчелеккә таныткан пьесалары мәйданга чыга: «Дуслар җыелган җирдә», «Диләфрүзгә дүрт кияү», «Ай булмаса, йолдыз бар» һ.б. Шуларны тикшерү аша, монография авторы драматургның сәнгати фикерләү үзенчәлеген билгеләүче сыйфатларны аерып чыгара. Бу – кеше яшәешен туган җире, туган туфрагы белән бәйләп карау; халыкчан рухның өстенлек итүе; шәхес буларак формалашуны әдәп-әхлакка тугрылык, хезмәткә мөнәсәбәт белән бәйләп карау; әсәрләрдә жанр ачыклыгы, үз йөзе белән аерылып торган геройларны сәхнәгә чыгару һ.б. Т. Миңнуллинның тормышчан конфликтка йөз тотып иҗат итүе һәм нәтиҗәдә татар драматургиясен яңа геройлар белән баетуы аеруча җитди яңалык буларак бәяләнә. Тормышчанлыкка әдип яңа тема һәм проблемаларга мөрәҗәгать итүе һәм гыйбрәтле хәл-ситуацияләр тудыруы, әдәби детальләрдән, образ-символлардан уңышлы файдалануы белән ирешә. Хезмәттә билгеләп үтелгәнчә, «Нигез ташлары»нда «нигез» символы, «йорт» мотивы; «Миләүшәнең туган көне», «Дуслар җыелган җирдә», «Хушыгыз» трилогиясендә «ялгызлык» мотивы, «уен» алымы; «Ай булмаса, йолдыз бар» да хатын-кызны әхлакый һәм социаль шартларда сынау; шулай ук җитди иҗтимагый мәсьәләләрне интеллектуаль эчтәлек аша ачу һ.б. бу әсәрләрне киң яңгырашлы, күп мәгънәле итә, шуңа да алар бүген дә сәхнәләрдә уңыш белән куелып килә.

Хезмәттә Т. Миңнуллинның яңа жанр формалары өлкәсендәге эзләнүләренә дә киң урын бирелә. Драматург XX гасыр башында ук формалашкан жанр формаларын үстерә, баета барып, аларның яңа сыйфатларын ачуга килә. Пьесалары, автор ассызыклаганча, «жанр чикләрен үтеп чыгулары, бертөрле генә бәяләнмәүләре, төрлечә укылышка урын калдырулары» [Закирҗанов, 2022, б. 65] белән игътибарга лаек. Хезмәт авторының «Диләфрүзгә дүрт кияү» водевиленә аерым урын бирүе дә тулысынча аклана. Әсәрдә әлеге жанр формасының төп билгеләре – үзенчәлекле интрига, җыр-музыкага нигезләнү, юмор-шаянлыкка киң урын бирелү, оптимизм һ.б. – бөтен тулылыгында чагылыш таба. Пьеса сәхнәдә куелганнан соң, водевильнең татар драматургиясендә бермә-бер активлашуы, аның музыкаль драма жанры үсешенә уңай йогынты ясавы да шул турыда сөйли.

Т. Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» пьесасы 1960–1980 еллар иҗатында үзенчәлекле урын алып тора. Ә.М. Закирҗанов әлеге моңсу комедияне «феномен» дип атый, ягъни аның татар драматургиясендә үзгә бер күренеш булуын ассызыклап үтә. Әсәрнең үз вакытында ук югары бәяләнүе һәм менә ярты гасыр дәвамында сәхнәдән төшми уйналуы да шул турыда сөйли. Хезмәттә пьесаның драматург иҗатында гына түгел, бәлки бөтен татар драматургиясендә үзенчәлекле күренеш булуы билгеләнә һәм моның сәбәпләре түбәндәгеләр белән аңлатыла: яңа тип милли геройны мәйданга чыгару; көнкүреш вакыйгаларын шартлылык алымы ярдәмендә ачып, яшәү мәгънәсен ачыклауга килү; авыл кешеләре образлары аша татар менталитетына хас сыйфатларны аерып чыгару; халык мифологиясе белән чынбарлык күренешләрен үзара үреп сурәтләү; кеше бөеклегенә дан җырлау; комедия һәм драма, реаль чынбарлык һәм романтик рух үзара кушылып киткән пьесаның укучы-тамашачыда өмет, ышаныч хисе тәрбияләве һ.б.

Т. Миңнуллин укучы-тамашачы ихтыяҗына сизгерлеге белән аерылып тора. Бу чорда милли мәсьәләләргә игътибар арту татарның тарихи шәхесләре белән кызыксынуга китерә. Шуңа нисбәтле драматургның Бәхтияр Канкаев, Габдулла Тукай, Муса Җәлил турындагы пьесалары язылып, алар тарихи шәхесләрнең әдәби образларын ачудагы яңалыгы белән киң яңгыраш ала. Ә.М. Закирҗанов хезмәттә әлеге тарихи-биографик драмаларны тарихилык һәм заманчалык принцибыннан чыгып тикшерә. Тарихи шәхесләрне халыкның теләге, азатлыкка омтылышы белән бәйләнештә сурәтли. Автор фикеренчә, М. Җәлилнең тормышы, фашизмга каршы көрәше һәм үлемсез иҗаты васыятенә турылык үрнәге булып тора, ә инде Тукай үз халкыннан аерылмаган, аның борчу-сызлануларын үзенеке итеп кабул иткән шагыйрь буларак ачыла.

«Т. Миңнуллинның XX гасыр ахыры иҗатында әдәби-эстетик эзләнүләре» дип аталган икенче бүлектә иҗтимагый һәм мәдәни тормыштагы үзгәрешләрнең драматург иҗатына йогынтысы тикшерелә. Хезмәттә әлеге чор драматургиясендә барган сәнгати эзләнүләр, дөнья сурәте үзгәрү мәсьәләләренә җентекле күзәтү ясала. Автор фикеренчә, яшәеш кыйммәтләре үзгәрү белән сәхнә әдәбиятында эстетик күптөрлелек урнаша. Моңа кадәр өстенлек иткән реалистик һәм романтик сурәтлелек янәшәсендә модернистик һәм постмодернистик алымнар активлаша. Драматурглар, яшәеш каршылыкларын чагылдыруның үзгә юлларын эзләүгә киләләр. Бу исә мифопоэтик алымнарга, метафора булып килгән күренешләргә, кешене чиктәш халәттә сурәтләүгә, вакыт-чорларны коллаж рәвешендә бирүгә, «аңсызлык», «саташу», җүләрләнү» кебек мотивларга нигезләнүгә китерә. Ә.М. Закирҗанов әйдәп баручы драматурглар Т. Миңнуллин, И. Юзеев, Р. Хәмид, З. Хәким, Ю. Сафиуллин, М. Гыйләҗев, Д. Салихов, Г. Каюмов һ.б. иҗатына күзәтү аша, тематик һәм жанр төрлелеген, сәнгати эзләнүләрдәге табыш һәм югалтуларны, традицион

алымнарны һәм яңачалыкларны эзлекле барлап, әлеге чор сәхнә әдәбиятының яңа бер этапка күчүен дәлилли. Аның нигезен, «тормышны тулылыгында, күптөрлелегендә, каршылыгында чагылдыру, шуларны укучы-тамашачыга җиткерүнең яңа юлларын эзләү омтылышын» [Закирҗанов, 2022, б. 128] билгели.

Драматургиядә урын алган әлеге һәм башка үзенчәлекләргә нигезләнеп, автор Т. Миңнуллинның ХХ гасыр ахыры иҗатына хас яңалыкларны, беренче чиратта, чор һәм шәхес концепциясенә нисбәтле ача. «Илгизәр плюс Вера», «Хушыгыз», «Шәҗәрә», «Эзләдем, бәгърем, сине» һ.б. пьесаларны тикшерү аша «үзгәртеп кору» чорының каршылыклы, кешенең өмет һәм өметсезлек, еш кына чарасызлык хәлендә калуы, шуңа да әсәрләрне экзистенциализм (сызлану) фәлсәфәсе иңләп үтүе турындагы нәтиҗәгә килә.

Драма әсәре бертөрлелекне кабул итми, драматург чынбарлыкны чагылдыруның яңадан-яңа юлларын, формаларын, алым-чараларын эзли башлый. Т. Миңнуллинның әлеге чор пьесаларындагы стиль үзенчәлеген һәм сәхнә әдәбиятына алып килгән яңалыгын Ә.М. Закирҗанов көтелмәгән метафора («Сөяркә»), образ-символ («Илгизәр плюс Вера»), шартлылык («Җанкисәккәем») кебек сурәт чараларының вакыйгалар катламында мөһим урын алып торуында һәм еш кына төп идеяне ачуга хезмәт итүендә күрә. Бу уңайдан авторның «Саташу» драмасына бәяләмәсе тирәнлеге һәм тулылыгы белән аерылып тора. Чорны ул кара, шыксыз яшәеш буларак сурәтли һәм «шул шартларда тулы бер «югалган буын»ның мәйданга килүен, аның фаҗигасын ача» [Закирҗанов, 2022, б. 170]. Автор фикеренчә, Т. Миңнуллин әсәрдә яңа, гаять гыйбрәтле образлар иҗат итә. Ата-анасын судка биргән Гүзәл үз-үзенә таба алмыйча бәргәләнүче маргинал герой буларак ачыла. Пьесадагы тышкы каршылык исә Саташкан әбинең эш-гамәлләренә бәйле бирелеп, җәмгыятькә, кешене шундый хәлгә куйган системага бәя булып тора.

«Т. Миңнуллинның XXI гасыр башы пьесаларында сурәтләнгән дөнья» дип аталган өченче бүлектә драматургның соңгы чор иҗаты өйрәнелә һәм бәяләнә. Ә.М. Закирҗанов яңа гасыр башы сәхнә әдәбиятына күзәтү ясап, әлеге төрнең билгеле бер дәрәҗәдә торгынлык кичерүен һәм моның пьесалар сыйфаты белән бәйле булуын билгели. Бу елларда үткәрелгән «Яңа татар пьесасы» конкурслары да шуны раслый. Автор фикеренчә, әлеге конкурслар драматургларны активлаштырып кына калмыйча, драматургиягә И. Зәйниев, Й. Миңнуллина, Р. Мөхсинова, С. Гаффарова, Э. Гыйззәтова, А. Шәйдуллин кебек яшьләрнең килүенә юл ача. Хезмәттә драма төренең жанр һәм жанр формалары өйрәнелә һәм әйдәп баручы драматургларның сәхнәләрдә уңыш белән барган әсәрләренә күзәтү ясалып, табыш-югалтулар билгеләнә. XXI гасыр башы драматургиясен яңа этап буларак аерып чыгаруга нигез буларак, Ә.М. Закирҗанов түбәндәгеләрне аерып чыгара: яшәеш мәсьәләләрен укучы-тамашачы күңеленә җиткерүнең яңа юлларын эзләү максатында, шартлы алымнарның реалистик һәм

романтик күренешләр белән үрелеп баруы; үткәннең мәдәни эзләрен активлаштыру – интертекстуальлек аша бүгенгегә бәя бирү; жанр чикләренең җуелуы, ягъни бер әсәрдә төрле жанр формаларына хас билгеләрнең урын алуы; вакыйгаларда «аңсызлык», «җан хәрәкәте», «шизоанализ» күренешләрен сурәтләү аша кеше психологиясенең тирән катламнарын ачу һ.б.

Ә.М. Закирҗанов фикеренчә, бу чор татар драматургиясендә барган үзгәрешләрдә Т. Миңнуллин иҗаты үзгә урын алып тора. Драматург сәхнә әдәбияты традицияләрен үстерә, баета барып, еш кына яңа тормыш материалына мөрәҗәгать итә, гыйбрәтле сюжетлар алып килә, шуларга туры килердәй формалар эзли. Яңа жанр формларына йөз тоту әдип өчен һич тә үзмаксат түгел, бәлки замандашның катлаулы рухи дөньясын ачуга хезмәт итү чарасы булып тора. Хезмәттә шуның уңышлы үрнәкләре урын ала. «Тәнзиләкәй» монодрамасы яшәеш фәлсәфәсен шартлы һәм ассоциатив алымнар аша ачуның уңышлы үрнәге булса, «Галиябану, сылуым-иркәм» пьесасында интертекстуальлек һәм уен алымнары ярдәмендә чагылган яңа эчтәлек бәяләнә.

Т. Миңнуллинның бөтен иҗаты милли эчтәлек белән сугарылган, шуңа да әдип өчен чорның милли характерын торгызу җитди бурыч булып санала. Автор билгеләп үткәнчә, «Т. Миңнуллинның иҗат эволюциясе аеруча шәхес концепциясендә тулы чагылыш таба» [Закирҗанов, 2022, б. 204]. Шуңа да аның иң яхшы пьесалары нәкъ менә милли характер буларак ачылган геройлары белән хәтердә кала. Әдипнең XXI гасыр башында дөнья күргән «Саташу», «Эзләдем, бәгърем, сине», «Галиябану, сылуым-иркәм», «Дивана», «Мулла», «Нәзер», «Төш» кебек пьесалары, форма-стиль яисә сурәт чаралары һәм гыйбрәтле геройлары белән җитди яңалык алып килә. Монографиядә билгеләп үтелгәнчә, Т. Миңнуллин, берәүне дә кабатламыйча, чорның яңа геройларын мәйданга чыгара. Алар арасында замандашның нык ихтыярлы көчле шәхесләре (Рәхмәтулла – «Алты кызга бер кияү» һәм Әсфәндияр – «Мулла»), язмыш сынауларын уза алмыйча, аптырап калган геройлар (Гүзәл, «Саташу»), яшәеш каршылыкларын күңел сызлануы аша кабул итүчеләр (Вил, «Дивана») бар. Драматург иҗатында гына түгел, әлеге чор сәхнә әдәбиятында казаныш буларак бәяләнгән «Мулла» драмасына автор үзенчәлекле якын килә. Ул, бер яктан, Әсфәндияр язмышы белән Мөхәммәд пәйгамбәр (с.г.в.) тормышы охшашлыгына нигезләнсә, икенче яктан, әлеге геройның үзен табуын традицион өлгереп җитү йоласы аша аңлата. Бу исә пьесадагы дини карашларны, татар авылының хәзерге хәлен, халык һәм хакимият мөнәсәбәтен, милли традицияләрне һәм тормышка үтеп кергән яңалыкларны яшәеш кыйммәтләре яссылыгында бәяләү мөмкинлеге бирә.

Хезмәттә Т. Миңнуллинның балалар өчен язылган пьесаларына да эзлекле күзәтү ясалып, драматургның бу өлкәдәге табышяңалыклары билгеләнә. Театрның яшь буынны тәрбияләүдәге зур ролен яхшы аңлаган драматург аеруча ике гасыр чигендә балалар

өчен актив иҗат итә. Ә.М. Закирҗанов билгеләп үткәнчә, күпсанлы пьесалары белән мәктәп укучыларын театр залларына кайтарырга ярдәм итә.

Гомумән, Ә.М. Закирҗановның аерым әдип иҗатын бөтенлекле тикшерүне максат иткән яңа монографиясе фәнни-теоретик эзләнүләре, гамәли юнәлтелгән булуы һәм татар драматургиясенең мөһим бер дәверен системага салып тикшерүе белән татар әдәбият фәнен баетуга хезмәт итә.

**Әдәбият**

*Закирҗанов Ә.М.* Туфан Миңнуллин драматургиясе: монография. Казан: ТӘһСИ, 2022. 252 б.

*Закирзянов А.М.* Мифопоэтическая основа драмы Т. Миннуллина «Мулла» // Башкирский народный эпос «Урал батыр» и духовное наследие народов мира: Материалы Международной научно-практической конференции, посвященной со дня рождения выдающегося ученого-фольклориста, доктора филологических наук, профессора А.М.Сулейманова (24 мая 2019 года). Ч. 1. Уфа: Изд-во БГПУ, 2019. С. 148–153.

*Закирҗанов Ә.М.* Т.Миңнуллинның XX гасыр ахыры иҗатында әдәби-эстетик эзләнүләр // Фәнни Татарстан. 2019. № 2. Б. 57–64.

*Закирзянов А.М., Хабутдинова М.М.* Новое прочтение женской темы в спектакле «Без луны, звезда нам светит» по одноименной пьесе Т. Миннуллина (2015) (реж. Р.Р. Фазлыев) // Филология и культура. Philology and culture. 2016. №1 (43). С. 198–204.

*Zakirzyanov A.M, Ghilazov T.S.* Tufan Minullin drama: The synthesis of eastern and western traditions // Man in India. 2016. Vol. 96, Is. 7. P. 2357–2365.

***Габидуллина Фәридә Имаметдин кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Казан (Идел буе) федераль университетының Алабуга институты доценты*

# А.М. ГАЙНЕТДИНОВНЫҢ «КАЗАННЫҢ ЯҢА ТАТАР БИСТӘСЕ ЗИРАТЫ ЭПИГРАФИК ИСТӘЛЕКЛӘРЕ» КИТАБЫНА (Казан: Конверс, 2023) РЕЦЕНЗИЯ

Соңгы елларда Татарстан Республикасында тарихи-мәдәни мирасны өйрәнүгә һәм саклауга зур игътибар бирелә башлады, җәмгыятебез үзенең матди һәм рухи-рухани үткәненә сакчыл мөнәсәбәт таләп ителүне аңлады. Шуңа күрә төрле һәйкәлләр, тарихи-архитектура объектлары күпләп торгызыла һәм реставрацияләнә. 2009 елда Казанда Бөтенроссия тарихи һәм мәдәни истәлекләрен саклау иҗтимагый оешмасының Татарстан бүлеге ачылды, 2018 елда Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты оештырылды. Алар республикада яшәүче халыкларның мәдәни мирасын саклау, файдалану, популярлаштыру өлкәсендә зур эшчәнлек алып баралар.

Шунысын әйтергә кирәк: Татарстанның тарихи некропольләрен өйрәнү һәм аларның тарихи-мәдәни кыйммәтләрен ачыклау буенча да активлык сизелә. Болар белән Казанның кайбер фәнни оешмалары шөгыльләнә, шул исәптән, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, А. Халиков исемендәге Археология институты һәм Татарстан Республикасы Милли китапханәсе әлеге проблемага махсус игътибар биреп килә.

Гарәп графикасында язылган борынгы кабер ташлары тарихи-мәдәни мирасыбызның әһәмиятле бер өлеше булып саналганга күрә, Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты 2015 елдан аларны җентекләп өйрәнү белән шөгыльләнә. Нәтиҗәдә, эпиграфикага багышланган байтак хезмәтләр дөнья күрде. Аларның күбесе Яңа тарих бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре А.М. Гайнетдинов тарафыннан әзерләнде. 2016 елда аның «Арча районы эпиграфик истәлекләре», 2017 елда «Әтнә районы эпиграфик истәлекләре», 2018 елда «Казанның Бишбалта бистәсе эпиграфик истәлекләре» һәм «Ш. Мәрҗани белән бәйле эпиграфик истәлекләр», 2019 елда «Яшел Үзән районы эпиграфик истәлекләре» һәм «Казанның Дары бистәсе эпиграфик истәлекләре» дип аталган китаплары нәшер ителеп, 3,5 меңгә якын эпиграфик истәлек тасвирланып, аларның текстлары фәнни әйләнешкә кертелде.

2017 елда республика җитәкчелеге карары буенча Казанның мемориаль зиратларын тикшерү эше башланды. Алар арасында Казанның Яңа Татар бистәсе зираты аерым урын алып тора, нәкъ менә монда татар халкының иң бөек затлары соңгы сыену урыны тапкан. Габдулла Тукай һәм Фатих Әмирхан, Шиһабетдин Мәрҗани һәм Каюм Насыйри, Салих Сәйдәшев һәм Марсель Сәлимҗанов кебек исемнәрне генә искә төшерү дә бу некропольнең милли пантеон статусын йөртүен аңлау өчен җитә. Зиратлар – шәһәрләр өчен иң традицион һәм актуаль истәлекле урыннар һәм халыкның рухи тормышы белән бәйле шәһәр

мохитенең төп элементлары. Тарихи некропольләргә мөнәсәбәт җәмгыятьнең әхлакый үсеш дәрәҗәсен характерлый, аның тарихы һәм мәдәнияте тамырлары төшенчәсен символлаштыра.

2017 елның апреленнән июленә кадәр дәвам иткән фәнни экспедициядә Тарих институтының Татарстан Республикасы халыкларының тарихи-мәдәни мирасы бүлеге хезмәткәрләре А.М. Гайнетдинов, А.И. Ногманов, С.Р. Хәмидуллин һәм О.О. Владимиров, тарихи кыйммәткә ия булган кабер ташларын ачыклау максатыннан, Яңа Татар бистәсе зиратында фронталь тикшеренүләр уздырды. Әлеге экспедиция барышында 1813–1929 елларга караган, гарәп һәм латин графикасында язылган 1500 гә якын эпиграфик истәлек табылды. Алар А.М. Гайнетдинов тарафыннан атрибуцияләнде һәм фәнни эшкәртелде.

Мәгълүм булганча, әлеге зиратта XX гасыр башына кадәр татар милләте үсешенә зур өлеш керткән күренекле мәгърифәтчеләр, педагоглар, дин әһелләре, сәүдәгәрләр, җәмәгать эшлеклеләре җирләнгән. Моңарчы Яңа бистә зиратының тулысынча тикшерелмәве әлеге эшнең актуальлеген арттыра. Танылган эпиграфист галимнәребез татар яшәгән бик күп төбәкләрдәге татар зиратларына мөнәсәбәтле зур фәнни эшләр башкарганнар. Шул ук вакытта татар халкының әлеге иң әһәмиятле зиратының эпиграфик истәлекләрен өйрәнүгә игътибар бирелеп бетмәгән.

Дөрес, Казанның Яңа Татар бистәсе зираты XX гасырның икенче яртысында аерым галим-эпиграфистларның өйрәнү объекты була. Мәсәлән, М.И. Әхмәтҗановны билгеләп үтәргә кирәк, ул төрле экспедицияләр барышында 140 ка якын гарәп язулы кабер ташларын ачыклаган һәм тасвирлаган. 1990 елларда Р.Р. Салихов һәм Р.Р. Хәйретдинов ТАССРда һәм Татарстанда яшәгән 198 мәшһүр шәхеснең каберләрен ачыклаганнар һәм теркәгәннәр. Шулай ук Һ.В. Йосыпов, И.Г. Һадиев, В.М. Усманов кебек башка эпиграфистлар да зиратны өйрәнүгә үз өлешләрен керткәннәр. Ләкин барыбер тикшеренү эшләре ахырына җиткерелмәгән. 2017 елгы экспедиция вакытында табылган материаллар – XIX гасыр – XX гасыр башына караган кабер ташлары – археограф, эпиграфист, тарихчы А.М. Гайнетдинов тарафыннан эшкәртелде. Эшенең нәтиҗәсе буларак, А.М. Гайнетдиновның «Яңа Татар бистәсе зираты эпиграфик истәлекләре» дип аталган 800 битле хезмәте (Гайнетдинов А.М. Казанның Яңа Татар бистәсе зираты эпиграфик истәлекләре. – Казан: «Конверс», 2023. – 800 б.) басылып чыкты.

Анда Яңа бистә зиратында бүгенге көнгә хәтле сакланып калган гарәп язулы татар эпиграфик истәлекләренең фотолары, үлчәмнәре, тулы текстлары, хәзерге татар әдәби теленә күчермәләре китерелгән. Китаптан күренгәнчә, материалларны туплау, эшкәртү, системалаштыру, гарәп графикасындагы текстларны кириллицага һәм хәзерге телгә күчерү эшләренең барысы да фәнни таләпләргә туры китерелеп эшләнгән. Хезмәттә 1813 елдан алып 1929 елга кадәр куелган гарәп язулы 1425 кабер ташы исәпкә алынган. Бу, әлбәттә, гаять зур сан, чөнки бу кадәр күп материал табылган татар зиратлары сирәк очрый.

Эпиграфист А.М. Гайнетдинов хезмәтендә Яңа Татар бистәсе зиратында җирләнгән бик күп атаклы шәхесләрнең кабер ташларындагы гарәп язулы эпитафияләр тәкъдим ителгән һәм фәнни әйләнешкә кертелгән. Мәсәлән, олуг галимнәребез Ш. Мәрҗани, Г. Баруди белән бәйле кабер ташлары, шулай ук Аитовлар, Апаковлар, Апанаевлар, Әҗимовлар, Борнаевлар, Замановлар, Субаевлар, Үтәмешевләр, Юнысовлар, Яушевлар һ.б. мәшһүр татар нәселләренә нисбәт ителгән затларның ташбилгеләрен саклаган зиратка игътибар бирү урынлы. 2017 елгы тикшеренү боларның барысын исәпкә алып башкарылды, эш барышында элегрәк Е.В. Липаков һәм Е.В. Афонина тарафыннан бөтенләй югалган дип саналган эпиграфик истәлекләр (мәсәлән, педагог Ш. Әхмәров, сәүдәгәр И. Юнысов һ.б.ның кабер ташлары) дә ачыкланды.

А.М. Гайнетдиновның китабы Яңа Татар бистәсе зиратын өйрәнү нәтиҗәләре хакында язылган бүлектән башлана, аннаң соң ташъязмаларның фотолары белән бергә тасвирламалары бирелә. Теге яки бу кешенең ташбилгесен табарга җиңел булсын өчен, зур зират территориясе, андагы аллеяларга һәм сукмакларга нигезләнеп, 37 участокка бүленгән һәм аларның план-схемасы ясалган. Бу исә, зиратка баргач, кабер ташларын табуны җиңеләйтә. Иң мөһиме, китапта җирләнгән шәхесләр, ташка язу осталары, эпитафияләрдә очраган дәрәҗә-вазифалар, титуллар, кәсепләр, географик атамалар күрсәткечләре дә бар, шулай ук кабер ташларының хронологик күрсәткече урнаштырылган. «Яңа Татар бистәсе зираты эпиграфик истәлекләре» китабының кушымта өлешендә бүгенге көндә төрле сәбәпләр аркасында юкка чыккан кайбер борынгы эпиграфик истәлекләрнең текстлары һәм XX гасыр башында вафат булган күренекле затларның яңартылган ташлары тәкъдим ителгән.

Китапта кабер ташларының текстларын бирү ысулы да бик төгәл эшләнгән. Фәндә гарәп җөмләләрендәге саф гарәп сүзләрен татарчага якынлаштырып язуда төрлелек бар. Биредә автор-төзүченең аларны тәҗвид кагыйдәләренә туры китерелгән формада бирүе бик отышлы. Чыннан да, гарәп теленең фонетикасын бозмау җәһәтеннән, бу – уңышлы алым. Китапта ташбилгеләр текстларының хәзерге татар әдәби телендә бирелүе, сүзләрнең татар теленә тәрҗемәдә тәкъдим ителүе укучылар аудиториясен киңәйтә, чөнки иске татар телен, нигездә, галимнәр генә белә. Шул ук вакытта китапта ташъязманың транслитерациясе дә китерелгән һәм теләгән кеше оригинал текстларның ни рәвешле язылуын карый һәм китерелгән фоторәсемнәр белән чагыштыра ала. Китапта кайбер шәхесләр хакында кыскача мәгълүмат бирелгән һәм аларның фәнгә билгеле шәҗәрәләре күрсәтелгән.

А.М. Гайнетдиновның «Яңа Татар бистәсе зираты эпиграфик истәлекләре» хезмәте тиз арада татар халкының тарихи һәм мәдәни мирасы белән кызыксынучы белгечләрнең өстәл китабына әверелер, дип ышанып калабыз.

***Хәмидуллин Сайрус Руслан улы,***
*ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты фәнни хезмәткәре*

# «ВИКТОР ФЁДОРОВ. МОНУМЕНТАЛЬНОЕ ИСКУССТВО, ЖИВОПИСЬ, ГРАФИКА. К 80-ЛЕТИЮ СО ДНЯ РОЖДЕНИЯ» КИТАБЫНА (Казань: «Заман», 2022) РЕЦЕНЗИЯ

Альбом-каталог XX гасырның икенче яртысы Татарстан сынлы сәнгатендә әйдәп баручы осталарның берсе, рәссам-монументалист, нәкышче, график һәм шагыйрь Виктор Кронидович Фёдоровның (1940–2001) иҗатын беренче мәртәбә киң һәм тулы күләмдә тәкъдим итә.

В.К. Федоровның монументаль әсәрләре – витражлар, мозаикалар һәм дивар рәсемнәре – Казанның һәм Татарстандагы башка шәһәрләрнең күп кенә иҗтимагый биналары экстерьерларын һәм интерьерларын бизи, шәһәр мохитен формалаштыра, республика халкының күпмилләтле характерын чагылдырган патриотик, һөнәри, гражданлык идеяләрен гамәлгә ашыра. В.К. Федоров халыкка үзенең тарихи полотнолары белән дә яхшы таныш. Аларда Россия һәм Татарстан тарихының төрле чорлары ачыла, илебездә яшәүче татар, рус һәм башка халыкларның язмышы бергә үреп тасвирлана. В.К. Федоровның күпсанлы портретларында аның туганнары һәм якыннары, республиканың мәдәният, фән, сәнгать һ.б. өлкәләре эшлеклеләре, җәмгыятьнең төрле катлау вәкилләре сурәтләнгән.

Останың күпсанлы рәсемнәре ул монументаль әсәрләр һәм нәкыш, китап бизәү (Татарстан китап нәшриятында В.К. Федоров бизәлешендә күпсанлы китаплар нәшер ителә) өстендә эшли башлар алдыннан, ягни әзерлек этабында иҗат ителгән. Югары дәрәҗәдәге үзенчәлекле иҗаты, актив рәвештә күргәзмәләр оештыруы яшь рәссамны 1974 елда СССР рәссамнар Союзына кабул итү өчен җирлек була, ә күпьеллык хезмәте өчен 1978 елда аңа Татарстан АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исем бирелә.

Рәссамның күпкырлы иҗаты басманың структурасында да чагылыш тапкан. Альбом 6 бүлектән тора: монументаль-декоратив сәнгать, тарихи нәкыш, нәкыш (бу бүлек портрет, пейзаж, көнкүреш жанрларын үз эченә ала), китап графикасы, шигырьләр. Һәр бүлек рәссам иҗатының тиешле өлешен анализлаган кереш мәкалә белән ачыла.

Китап Казан шәһәренең танылган сәнгать белгече Д.К. Вәлиеваның «Я ведал свет небесной высоты» дигән мәкаләсе белән ачыла, ул 2010 елда рәссамның юбилее уңаеннан оештырылган күргәзмә каталогы өчен язылган [Виктор Фёдоров, 2010, с. 7–9], әмма андагы нәтиҗәләр бүген дә актуальлеген югалтмый. Мәкаләдә автор рәссамның иҗат юлы этапларын ача, монументаль һәм иң элек станоклы нәкышенә мөрәҗәгать итә. Башта Казан сәнгать училищесында, ә аннан соң И.Е. Репин исемендәге Нәкыш, скульптура һәм архитектура институтында төпле сәнгати белем алган һәм «чынбарлыкка ачык гуманистик мөнәсәбәте булу, ил тарихын тирәнтен аңлавы белән аерылып торган» сәнгатькяр булып өлгереп, яңадан туган шәһәренә әйләнеп

кайткан яшь рәссам иҗатының башлангыч этабы тасвирлана. Ул Казанның сәнгать тормышында кайный. Республика, бөтенроссия һәм бөтенсоюз күргәзмәләрендә катнаша, әмма иң элек төп белгечлеге буенча рәссам-монументалист буларак эшли башлый, монументаль рәсем сәнгатенең төрле техникаларында сынала, үзенең шәһәр корылмаларындагы композицияләрендә «XX гасырның 70 нче елларындагы оптимизм белән сугарылган идеяләрне» чагылдыра [Виктор Фёдоров, 2022, с. 4].

Д.К. Вәлиева билгеләп үткәнчә, рәссамның алга таба иҗатын станоклы нәкыш билгели; ул монументаль әсәрләрендәге идеяләрне дәвам итә. Бу бигрәк тә тарихи жанрга кагыла: рәссам Татарстан сәнгатендәге 1960–1970 еллар бушлыгын безнең төбәкнең борынгы тарихына караган вакыйгаларга мөрәҗәгать итеп тулыландыра. Д.К. Вәлиева В.К. Федоровның «Русь колыбельная» тарихи полотносының рәссам иҗатында тирән сәнгатьчә гәүдәләнеше, колористик чишелеше буенча иң уңышлы әсәрләрнең берсе булуын ассызыклый. Остаңы Идел буенда яшәгән төрле халыкларның язмышы бергә үрелгән тарихи вакыйгалар кызыксындыра. В.К. Фёдоров әсәрләрендә («Пугачёв һәм Бәхтияр Канкаев», «Сәйяр труппасы» («Тукай сүзе»), «Камил Якуб», «Маяковский и Гадел Кутуй» һ.б.) һәрвакыт Идел буенда элек-электән бергә яшәгән татарларның һәм русларның бердәм ватанлы булуын, ике халыкның тыгыз үзара мөнәсәбәтен аңларга омтылу ярылып ята. Рәссам бу бәйләнешларга сәяси, социаль һәм дини каршылыклар да киртә була алмаганлыгын күрсәтә [Виктор Фёдоров, 2022, с. 5].

Д.К. Вәлиева портретларны рәссам иҗатының мөһим катламы дип саный: аларның һәркайсында ул шәхес психологиясен тирәнтен ача, аның индивидуаль сыйфатларын – интеллектын, эчке культурасын, талантын, шат күңеллелеген, якты характерын ассызыклый. Ул рәссам иҗат иткән портрет образларының күптөрлелеген билгеләп үтә. Рәссам гаилә әгъзаларының – ата-анасы, балалары, хатын-кыз идеалын гәүдәләндергән хатыны, аннан язучылар, галимнәр, актёрлар, музыкантлар, замандашлары, шулай ук тарихи шәхесләрнең (Ш. Мәрҗани һ.б.) портретларын бердәй яратып иҗат итә. Мәкалә авторы В.К. Федоровның төрле пландагы сюжетлы, кырыс стилистикалы, тыенкы колоритлы, хәрәкәт тулы композицияле, тирән психологик характерга ия геройларны сурәтләгән картиналары Татарстан сынлы сәнгате классикасы булып калачак, дигән нәтиҗәгә килә.

Ф.М. Миңнегулованың «Монументаль-декоратив сәнгать» дип исемләнгән мәкаләсе альбомның икенче өлешен тәшкил итә. Анда В.К. Федоров иҗаты 1960–1970 елларда моңарчы күрелмәгән күтәрелеш кичергән совет монументаль сәнгате кысаларында карала. Автор фикеренчә, В.К. Федоровның монументаль эшләрендә совет сәнгатенең төп темалары: балачак һәм яшүсмер чор, коткару һәм яклау, иҗат һәм уку, фән һәм спорт, төзелеш һәм бакчачылык чагылыш тапкан һәм алар «сами по себе являются памятниками эпохи с её основными ценностными категориями – гуманизм, созидание, социальная направленность» [Виктор Фёдоров, 2022, с. 10].

Бүлекнең альбом өлешен В.К. Фёдоровның иң атаклы әсәре – «Казан – Совет Татарстаны башкаласы» панносы ача. Ул Казан шәһәренең үзәк тимерьюл вокзалы бинасына урнаштырылган. С.М. Бубеннов белән берлектә язылган бу панно Татарстанның төп символларының берсе булып тора, анда сурәтләнгән татар гүзәле 45 елдан артык инде башкалабыз кунакларын серле елмаеп каршы ала. Альбом өлешендә 1960–1980 елларның сакланып калган әсәрләре («Татарстан» кунакханәсе, «Оргсинтез» бассейны мозаикалары, С. Сәйдәшев исемендәге Мәдәният үзәге, М. Горький һәм Ф. Шаляпин музее, Казан федераль университеты витражлары һ.б.). Алар басма өчен махсус фотога төшерелде. Шулай ук рәссам архивыннан алынган документаль фоторәсемнәрдә генә урын алган, бүгенге көндә сакланмаган объектлар (Яшьләр үзәге бинасындагы рәсем һ.б.) тәкъдим ителгән.

Альбомда В.К. Федоровның нәкыше ике бүлектә күрсәтелгән: рәссам иҗатында бөтенләй яңача үсеш алган тарихи жанр аерым бүлек итеп бирелгән. Әлеге бүлеккә язылган мәкалә авторы Д.И. Әхмәтова түбәндәгеләрне билгеләп үтә: рәссамның тарихи полотнолары аның дөньяга караш белән бәйле тирән эзләнүләрен, актуаль көн тәртибе, Россия һәм туган җир тарихы белән кызыксынуын чагылдыра, аны милли, төбәк тарихының «икона» белән әллә ни бәйле булмаган сюжетлары җәлеп итә: Емельян Пугачёв, Пушкинның Пугачёв восстаниесе белән бәйле урыннар буйлап сәяхәте, «Сәйяр» татар театры тарихы, шулай ук күренекле тарихи шәхесләр һәм мәдәният эшлеклеләре Ш. Мәрҗани, Г. Тукай, Г. Кутуй һ.б. Сәнгать белгече билгеләп үткәнчә, «вытянутые пропорции персонажей, некоторая «бесплотность», существенно романтизировали историю, лишая её налета социальной актуальности, идеологической повестки» [Виктор Фёдоров, 2022, с. 37]. Альбом өлешендә В.К. Федоровның төп тарихи, шул исәптән төрле дәверләрнең революцион хәрәкәтен чагылдыручы (Париж коммунасыннан һәм Казанда беренче марксистик түгәрәкләрдән башлап Африка халыкларының милли-азатлык көрәшенә кадәр) картиналары тәкъдим ителгән. Д.И. Әхмәтова болай дип ассызыклый: «...художник наполняет своё творчество глубоко личными, искренне прожитыми чувствами о тех вечных и неизменных категориях добра и зла, через которые проходит человек на протяжении всей своей жизни, о непобедимости человеческого духа» [Виктор Фёдоров, 2022, с. 37].

Портрет, пейзаж һәм көнкүреш жанрлары алдагы «Нәкыш» бүлегендә тәкъдим ителгән. Зур булмаган мәкаләсендә Д.И. Әхмәтова төп игътибарны В.К. Федоровның иң яратып язылган портретларына бирә, һәм рәссамның рухи яктан үзенә якын кешеләр, гаилә әгъзалары, шулай ук язучылар, галимнәр, актёрлар, рәссамнар, сәнгать белгечләре образларын тудыруын билгеләп үтә. Шул ук вакытта ул «заказ буенча» портретлар иҗат итүгә дә рәссамның формаль рәвештә генә якын килмичә, үзенең модельләрен тулаем һәм симпатия белән өйрәнүен билгеләп үтә. Аңа бигрәк тә сурәтләнүченең характерын һәм эшчәнлеген ачып биргән «сөйләүче» детальләр белән эш итүче жанрлы портрет

якын. Альбом өлешендә рәссам каләме белән язылган дистәләрчә портретлар тәкъдим ителгән, алар арасында җырчы Ренат Ибраһимовның портреты аерылып тора, бу – әлеге жанрның 1980 еллар башы эстрада йолдызының артистлык табигатен ачкан иң гадәти булмаган һәм кыю әсәрләреннән берсе [Виктор Фёдоров, 2022, с. 65]. Д.И. Әхмәтова 1970–1980 елларда популяр булган автопортрет жанрын аерып чыгара, анда авторның сәнгатьчә үз «мин»е формалашу чагылыш тапкан, ди. Альбом өлешендә илнең төрле почмакларына сәфәр кылудан алган тәэсирләр буенча язылган күпсанлы пейзажлар да урын алган.

Альбомда беренче мәртәбә В.К. Федоровның график иҗаты киң һәм тулы итеп ачылган. Ул «Рәсем» һәм «Китап графикасы» бүлекләрендә күрсәтелгән. Ике бүлек тә В.К. Федоров графикасының жанр һәм стилистик үзенчәлекләрен анализлаган О.Л. Улемнова мәкаләләре белән ачыла. Сәнгать белгече рәссам иҗатының чишмә башын һәм аның иҗаты кичергән йогынтыларны да өйрәнгән. Нәкыш һәм монументаль әсәрләр иҗат иткәндә, беренче чиратта, әзерлек этабы булып хезмәт иткән рәсемнәрдә (булачак картина һәм панноларның контур һәм детальләре билгеләнгән этюд, эскиз, өстән-өстән генә ясалган караламаларда) О.Л. Улемнова рәссам иҗатының иң мөһим өлешен күрә. Альбомда тәкъдим ителгән күпсанлы эскизлар һәм караламалар В.К. Федоровның иҗади эш процессын, рәссам уйфикерләренең нияттән чынга ашуга таба хәрәкәтен чагылдыра [Виктор Фёдоров, 2022, с. 145]. Сәнгать белгече совет чорына караган һәм безнең көннәргә кадәр сакланмаган монументаль әсәрләрнең һәм Россия тарихының төрле чорларын чагылдырган, әмма язылмыйча калган полотноларның эскизларына аерым игътибар бирә. О.Л. Улемнова ассызыклавынча, В.К. Федоровның әлеге рәсемнәре әзерлек этабын чагылдыруга карамастан, алар мөстәкыйль һәм бәһалы әсәрләр буларак кабул ителә. Бу, беренче чиратта, рәссам Н.И. Фешин һәм аның мәктәбе традицияләрен дәвам иткән портрет жанрына карый.

«Китап графикасы» бүлегендә төзүчеләр рәссамның 1950 еллар ахырыннан алып 1980 еллар уртасына кадәр Татарстан китап нәшрияты белән хезмәттәшлек итү чорында иҗат ителгән эшләрен тәкъдим иттеләр. Болар – татар язучылары һәм шагыйрьләре әсәрләренә ясалган иллюстрацияләр, китап макетлары, тышлык эскизлары. Аларда совет чоры татар китап графикасының үсеш этаплары, совет сәнгате эволюциясен, үз заманы һәм үз буыны рухын чагылдырган индивидуаль сәнгать теле чагылыш тапкан [Виктор Фёдоров, 2022, с. 223]. Шул ук бүлеккә В.К. Федоровның бер үк вакытта әдәбиятка һәм тарихи жанрга караган һәм Сергей Аксаков, Николай Чернышевский, Максим Горький, Габдулла Тукай белән бәйле картиналары да кертелгән. Аларда Казан шәһәре белән бәйле әлеге атаклы язучыларның тормыш һәм эшчәнлек эпизодлары ачып бирелгән. Казандагы әдәби-мемориаль музейлар (М. Горький музее һәм Г. Тукай музее) өчен иҗат ителгән бу серияләр биографик романнарга яки автобиографик әсәрләргә нигезләнеп эшләнгәннәр һәм асылда иллюстрацияләрдән торалар.

Әмма әдәби канвага тугрылыклы калып, В.К. Федоров музей залларына куюю өчен станоклы картиналар яза [Виктор Фёдоров, 2022, с. 224]. Альбомда шулай ук рәссамның талантын ихтирам иткән кешеләргә яхшы таныш һәм Татарстан язучылары тарафыннан лаеклы бәяләнгән шигъри иҗаты да тәкъдим ителгән. Шигырьләр рәссамның үзе ясаган иллюстрацияләре белән бирелгән: җиңел һәм нәфис рәсемнәрдә В.К. Федоров үз шигъри әсәрләренең лирик образларын сурәтләгән.

Төзүче-авторлар сәнгатькярнең Казан, Чабаксар, Владимир шәһәрләре дәүләт музейларында, шәхси коллекцияләрдә, гаиләсендә сакланган нәкыш һәм графикасын, тәрҗемәи хәлен һәм иҗат процессын ача торган, шулай ук сакланмаган әсәрләре теркәлеп калган документаль фоторәсемнәрдән торган гаҗәеп бай материал туплаганнар.

Альбомны әзерләү барышында рәссамның әсәрләрен, шул исәптән Казанда гына түгел, республиканың башка шәһәрләрендә дә күрсәтелгән монументаль-декоратив сәнгатен ачыклау һәм фотога төшерү буенча зур эш башкарылган. Сәнгать фәннәре кандидатлары Ф.М. Миңнегулова, О.Л. Улемнова (графика бүлеге) катнашында зур тикшеренү эше үткәрелү нәтиҗәсендә, альбомның каталог өлешендә 700 әсәрнең фәнни тасвирламасы бирелгән, останың тормыш һәм иҗат юлындагы әһәмиятле даталарны, төп күргәзмәләрен, библиографияне үз эченә алган белешмә аппараты да гаять киңкырлы.

В.К. Федоров иҗади мирасын тирән фәнни өйрәнү, күп еллар дәвамында сәнгать буенча китаплар бастырып чыгаруда махсуслашкан «Заман» нәшриятының югары профессиональ эшчәнлеге, үзенчәлекле дизайн, югары сыйфатлы полиграфия альбом-каталог уңышының нигезендә ята. Югары зәвыклы, затлы бу китап сәнгать белгечләренә, рәссамнарга, культурологларга, тарихчыларга, төрле буын һәм төрле катлау вәкилләренә адреслана.

**Әдәбият**

Виктор Фёдоров. Живопись. Рисунок. Каталог выставки произведений к 70-летию со дня рождения / сост. кат. М.Р. Газизова и др. Казань: Заман, 2010. 60 с.: ил.

Виктор Фёдоров. Монументальное искусство, живопись, графика. К 80-летию со дня рождения. Альбом-каталог / авт.-сост. А.И. Фёдорова, Ф.М. Миннигулова, О.Л. Улемнова. Казань: Заман», 2022. 288 с. :

***Герасимова Наталья Владимировна,***
*сәнгать фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Сәнгать белеме үзәге фәнни хезмәткәре*

**2023 елның 24–25 апрелендә** татар әдәбияты классигы, танылган публицист һәм җәмәгать эшлеклесе Гаяз Исхакыйның тууына 145 ел тулу уңаеннан «Парадигмалар алмашыну шартларында татар белеме: теория, методология, гамәл» дигән темага III Халыкара фәнни-гамәли семинар үткәрелде. Әлеге чараның төп оештыручысы – Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты. Фәнни-гамәли семинар эшенең төп юнәлешләре буларак, түбәндәгеләр билгеләнгән иде: тарихи-мәдәни һәм иҗтимагый-сәяси контекстта Г. Исхакый шәхесе һәм иҗаты; Г. Исхакый һәм төрки дөнья: әдәби, тел, мәдәни аспектлар; Г. Исхакый һәм аның замандашлары – татар милләтенең лидерлары; милли мәдәниятләр үсешендә лидерларның роле; тикшеренү проблемасы буларак диаспора; милли телләрне, мәдәниятләрне, әдәбиятны өйрәнү методологиясе.

Фәнни-гамәли семинар эшендә онлайн режимда чит илләрдән (Азәрбайҗан, Казакъстан, Кыргызстан, Төркия), шулай ук Мәскәү, Санкт-Петербург, Казан, Новосибирск, Уфа, Яр Чаллы, Чабаксар, Ижевск, Алабуга һ.б. шәһәрләрдән галимнәр катнашты. «Гаяз Исхакый һәм XX–XXI гасырлар татар дөньясы» темасына фәнни-гамәли семинар материаллары, шулай ук «Гаяз Исхакый. Көндәлекләр. 1 китап (1919–1920)» һәм «Гаяз Исхакый. Милли куәтләр бардыр = Есть сила в нации» җыентыклары нәшер ителде.

**2023 елның 24 апрелендә** Г. Исхакыйның тууына 145 ел тулу уңаеннан Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә татар әдәбияты классигының яңа китапларын тәкъдим итү чарасы үткәрелде. Киң җәмәгатьчелеккә тәкъдим ителгән беренче китап – Исхакый Г. Милли куәтләр бардыр = Есть сила в нации / Д.Ф. Заһидуллина редакциясендә; төз. М.И. Ибраһимов. – Казан, 2023. – 324 б.: ил. Әлеге басмада язучының Россиядә һәм эмиграциядә татар теле, әдәбияты, тарихы мәсьәләләренә багышлап язылган публицистик хезмәтләре, туплап, татар һәм рус телләрендә бирелгән.

Икенче китап – Исхакый Г. Көндәлекләр: 3 китапта. 1 нче китап: 1919–1920 / төз., текст., иск. һәм аңл. әзерл.: Ә.Х. Алиева, Ф.Г. Фәйзуллина, Г.М. Ханнанова; кереш сүз авт. Д.Ф. Заһидуллина. – Казан: ТӘһСИ, 2023. – 300 б. Тәүге тапкыр нәшер ителгән әлеге көндәлекләрдә Г. Исхакыйның мөһаҗирлектә яшәгән вакыттагы тормышы тасвирлана: әдипнең 1919–1920 елларда Япониядә, Кытайда, Көньяк-көнчыгыш Азия илләрендә булуы һәм диңгез юлы аша Европага сәяхәте вакыйгалары урын алган.

**2023 елның 26 апрелендә,** Туган тел көнендә, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәгенә Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Нургали улы Миңнеханов килде. Язма мирас үзәге буенча экскурсия барышында аның җитәкчесе, филология фәннәре кандидаты Илһам Гомәров Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнехановны «Мирасханә» эшчәнлеге белән

таныштырды, аерым алганда, Г. Тукай, М. Җәлил, Ш. Мәрҗани, К. Насыйри һ.б. күренекле татар зыялыларының монда сакланган шәхси фондларыннан материаллар, төрки-татар халкының кульъязма мирасын популярлаштыру проектлары, шул исәптән гарәп хәрефләре белән бастырылган текстларны кириллицага күчерүче уникаль программа («Miras-Tat») турында сөйләде. Шулай ук Россия Фәннәр академисе Санкт-Петербург Тарих институты директоры А.В. Сиренов һәм Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Археология институты директоры А.Г. Ситдыйков «Европа цивилизациясе язу тарихы» проектын тәкъдим итте.

Соңыннан Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов Казан Кремленең «Манеж» күргәзмә залында татар зыялылары белән очрашты. Р.Н. Миңнеханов аларны Туган тел көне һәм бөек татар шагыйре Габдулла Тукайның тууына 137 ел тулу белән котлады, татар теле, милли традицияләр һәм мәдәният мәсьәләләренә республикада зур игътибар бирелүен билгеләп, халыкның тарихын, бай мирасын саклауга зур өлеш кертүләре өчен, катнашучыларга рәхмәт белдерде.

**2023 елның 24–26 апрелендә** Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты «Ак калфак» татар хатын-кызлары оешмасы белән берлектә III Бөтендөнья татар хатын-кызлары съездын уздырды. Съездга Татарстан Республикасы районнарыннан, Россия Федерациясенең илледән артык төбәгеннән, уннан артык ерак һәм якын чит илләрдән биш йөздән артык делегат чакырылган иде. Пленар утырыш «Корстон» сәүдә-күңел ачу үзәгендә оештырылды, биредә кул эшләре остаханәсе (күргәзмә-ярминкәсе) тәкъдим ителде. Моннан тыш, өч юнәлештә дискуссион мәйданчыклар эше оештырылды: татар гаиләсендә өч буын һәм җиде буын хәрәкәте; татар гаиләсендәге тәрбия (татар халкының гореф-гадәтләре, йолалары, бәйрәмнәре, уеннары нигезендә бала тәрбияләү); татар гаиләләрендә эшмәкәрлек. Съезд делегатлары Казан мәктәпләре, Казан (Идел буе) федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты эшчәнлеге белән танышты, Г. Тукай һәйкәленә чәчәкләр салу тантанасында, «Сөембикә» журналының 110 еллыгына багышланган тантаналы кичәдә, «Адымнар» полилингваль белем бирү комплексында узган «Калфак туе» чарасында катнашты.

**2023 елның 27 апрелендә** Тубыл шәһәрендә чираттагы «Зәнкиев укулары» узды. Педагог, язучы һәм җәмәгать эшлеклесе, Бөек Ватан сугышы ветераны, Татарстан Республикасы Язучылар берлеге әгъзасы, Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты Я. Зәнкиев исемен йөртүче бу чара милли мәгарифне саклау һәм үстерү; себер татарларының телен, әдәбиятын, тарихын һәм үзенчәлеген фәнни яктан тикшерү максатында уздырыла. Әлеге традицион Халыкара фәнни-гамәли конференция агымдагы елда Педагог һәм остаз елы уңаеннан заманча белем бирү киңлегендә фән һәм практиканы интеграцияләү темасына багышланган иде.

Аның эшендә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе

Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре дә катнашты. Филология фәннәре докторы, ТӘһСИ директорының фән буенча урынбасары О.Р. Хисамов пленар утырышта Идел-Урал һәм Себер татарларының тел һәм этник уртаклыгы турында доклад белән чыгыш ясады һәм чарада катнашучыларның күпсанлы сорауларына җавап бирде. Институтның милли мәгариф бүлеге хезмәткәрләре этномәдәни компонентлы мәктәпләрдә тел һәм әдәбиятны укыту методикасы проблемаларына багышланган секция эшендә катнаштылар. Филология фәннәре кандидаты, доцент Мөслимә Шәкүрованың чыгышы туган тел (татар теле) предметыннан әзерләнгән УМК ярдәмендә этномәдәни компетенция формалаштыруга багышланган иде. Филология фәннәре кандидаты, милли мәгариф бүлеге мөдире Гөлназ Мөхәрләмова татар әдәбияты буенча яңа УМКларның этномәдәни өлеше турында сөйләде.

**2023 елның 26–28 апрелендә** Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты һәм «Татарстан Республикасы мәдәният өлкәсендә инновацияләрне кертү һәм традицияләрне саклау ресурс үзәге» белән берлектә Сабантуй бәйрәмен оештыручылар һәм режиссерлар өчен семинар-практикум үткәрде. Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Сәнгать белеме үзәге мөдире, сәнгать белеме докторы Рауза Солтанова әлеге семинарда Сабантуй этнографик утарын декоратив-гамәли сәнгатьнең традицион төрләре һәм халык кәсепләре үзенчәлекләрен исәпкә алып оештыру үзенчәлекләре турында чыгыш ясады. Чарада Россия Федерациясе төбәкләреннән һәм чит илләрдән илледән артык вәкил катнашты.

**2023 елның 27–28 апрелендә** Санкт-Петербургта Европа университеты тарафыннан оештырылган «Вне столиц. Художественные выставки в регионах Российской империи» дип аталган Халыкара конференция узды. Аның эшендә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Сәнгать белеме үзәге хезмәткәрләре катнашты һәм XIX гасырда Казанда оештырылган күргәзмәләр турында докладлар белән чыгыш ясады. Сәнгать белеме кандидаты Людмила Шкляева XIX–XX гасырларда Казан губернасында узган күргәзмәләренең типологиясе турында сөйләде, сәнгать белеме кандидаты Наталья Герасимованың доклады – XIX гасырның икенче яртысы – XX гасыр башында шәхси коллекцияләрдәге сәнгать әсәрләре күргәзмәләренә, сәнгать белеме кандидаты Ольга Улемнованың чыгышы XX гасыр башында Россия сәнгать берләшмәләренең Казанда оештырылган күргәзмәләренә багышланган иде. Конференция Европа университетының Сәнгать һәм мәдәни мирас мәктәбе профессорлары һәм аспирантлары тәкъдиме белән 2021 ел ахырында эшли башлаган «Собирать и выставлять в Российской империи» проекты кысаларында оештырылды.

**2023 елның 3–6 маенда** Казан (Идел буе) федераль уни-

верситетының Филология һәм мәдәниятара коммуникацияләр институтында «Синтез документального и художественного в литературе и искусстве» дигән IX Халыкара конференция узды. Аның эшендә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Сәнгать белеме үзәге фәнни хезмәткәрләре дә катнашты. Сәнгать белеме кандидаты Ольга Улемнова «Совет һәм советтан соңгы чорлар татар китабында фотомонтаж» дигән темага пленар утырышта чыгыш ясады. Сәнгать белеме докторы Рауза Солтанова Ю. Әминевнең «Умырзаялар» спектаклендә чагылыш тапкан Гражданнар сугышы вакыйгаларының сәхнә интерпретациясенә багышланган доклады белән «Документ в драме, игровых и изобразительных видах искусства» секциясе эшендә катнашты. Филология фәннәре кандидаты Елена Шевченко (««Документаль әкият» буларак Маргарита Кадацкаяның «Шварц, Кеше, күләгә» пьесасы»), үзәк аспирантлары Рената Галиева («Совет чоры татар плакатында фотомонтаж») һәм Фирүзә Җумаеваның («Татарстан рәссамнары иҗатында Ибн Фадлан язмалары сюжетлары чагылышы») чыгышлары шул ук секция кысаларында яңгырады.

**2023 елның 7 маенда** татар халкының күренекле җырчысы Рәшит Ваһаповның туган авылы Актукта (Түбән Новгород өлкәсе) аның туган көне уңаеннан тантаналы чара үтте. Җырчының 115 еллыгы рәсми рәвештә ачык дип игълан ителгән әлеге чарада Казаннан Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Разил Зиннәтуллин, Р. Ваһапов фонды җитәкчесе Рифат Фәттахов, танылган сәнгать әһелләре, җырчылар катнашты.

**2023 елның 12 маенда** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Гаилә һәм демография үзәге «Татарстан Республикасы халкының гаилә-үзәкчел торышы габитусы: милли практикалар» темасына түгәрәк өстәл үткәрде (2020 елгы Бөтенроссия халык санын алу нигезендә). Чарада дәүләт оешмалары вәкилләре, галимнәр, киң җәмәгатьчелек катнашты.

**2023 елның 15 маенда** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президиумы утырышында президент Мәкъзүм Саләхов 2022 елда Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Диссертация советында диссертацияләрен уңышлы яклаган диссертантларга филология фәннәре докторы, филология фәннәре кандидаты гыйльми дәрәҗәсен бирү турында дипломнар тапшырды. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директорының фән буенча урынбасары Хисамов Олег Ришат улы, Институт директорының инновацион эшчәнлек һәм тышкы элемтәләр буенча урынбасары Шәрипова Алсу Сәмигулла кызы, гомуми лингвистика белеме бүлегенең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре Мирхәев Рифат Фирдинат улы – докторлык, Татарстан Республикасы Милли китапханәсе китапханәчесе Хөсәенова Гөлнирә Рәдиф кызы кандидатлык дипломнары алды. Хезмәттәшләребезне әлеге мөһим вакыйга белән котлыйбыз һәм чын күңелдән сәламәтлек, алга таба да фәнни уңышлар һәм һөнәри казанышлар телибез!

**2023 елның 18–19 маенда** Казанда «Татарлар һәм ислам дөньясы» фәнни форумы узды. Чара «Россия – ислам дөньясы» стратегик караш төркеме утырышы кысаларында оештырылды. Ул татар интеллектуалларының Россия ислам социаль институтларын үстерүгә керткән өлешләрен аңлауга, шулай ук ислам белеме, Көнчыгышны өйрәнү һәм этногуманитар өлкәләрдә тикшеренүләрнең хәзерге торышы белән танышуга юнәлдерелгән иде.

Форум кысаларында күренекле татар мәгърифәтчесе, дин һәм төрки тел белеме галиме, тарихчы һәм педагог Хөсәен Фәезхановның (1823–1866) тууына 200 ел һәм аның остазы Шиһабетдин Мәрҗанинең (1818–1889) тууына 205 ел тулуга багышланган «Хөсәен Фәезханов һәм Шиһабетдин Мәрҗани – бөек галимнәр, дин белгечләре һәм мәгърифәтчеләр» VIII Россиякүләм фәнни-гамәли конференция үтте.

**2023 елның 18 маенда** «Хөсәен Фәезханов һәм Шиһабетдин Мәрҗани – бөек галимнәр, дин белгечләре һәм мәгърифәтчеләр» VIII Россиякүләм фәнни-гамәли конференциясе кысаларында Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә түгәрәк өстәлләр һәм дискуссияләр оештырылды. «Татарлар: цивилизацион дөнья юллары» түгәрәк өстәленә филология фәннәре кандидаты, ТӘһСИнең чагыштырма татар тел белеме лабораториясе мөдире Марсель Ибраһимов һәм педагогик фәннәр кандидаты, «Вести ФМ» радиостанциясенең сәяси күзәтүчесе Марат Сәфәров модераторлык итте. Идел-Урал макрорегионының гарәп графикалы эпиграфик һәйкәлләре буенча яңа тикшеренүләргә багышланган түгәрәк өстәл филология фәннәре кандидатлары ТӘһСИнең Язма мирас үзәге җитәкчесе Илһам Гомәров һәм шул ук үзәкнең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре Азат Ахунов модераторлыгы астында узды.

Заманча археография проблемалары һәм перспективалары темасына фикер алышу барышында З. Исмәгыйлев исемендәге Уфа дәүләт сәнгать институты галимнәре, Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге, ТӘһСИ Язма мирас үзәге, Казан (Идел буе) федераль университеты, Болгар ислам академиясенең Ислам мирасы үзәге һ.б. фәнни оешмалардан галимнәр чыгыш ясады.

**2023 елның 19–21 маенда** Бөтендөнья татар конгрессы Казан шәһәрендә «Милли тормыш һәм дин» XIII Бөтенроссия татар дин әһелләре форумын үткәрде. Форумга Россия Федерациясенең 70 тән артык төбәгеннән, шул исәптән Татарстан Республикасыннан барлыгы мең дин әһеле һәм кунак чакырылган иде. Делегатлар 19 май көнне «Kazan Expo» Халыкара күргәзмәләр үзәгендә «Russia Halal Expo 2023» күргәзмәсе белән таныштылар. 20 май көнне «Kazan Expo» Халыкара күргәзмәләр үзәгендә Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов катнашында пленар утырыш узды. «Казан» агросәнәгать паркында «Russia Halal Expo 2023» күргәзмәсе оештырылды. Соңрак Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә XIII Бөтенроссия

татар дин әһелләре форумының пленар утырышы дәвам итте. 21 май көнне Форум делегатлары Татарстанның Спас районы Болгар шәһәрендә Изге Болгар җыенында катнашты.

**2023 елның 19 маенда** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында Азәрбайҗан Республикасы Чит телләр университеты ректоры киңәшчесе, филология фәннәре докторы, профессор Галей Алиевич Аллахвердиев белән очрашу узды. Чарада Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе вице-президенты, филология фәннәре докторы Д.Ф. Заһидуллина, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры, филология фәннәре докторы К.М. Миңнуллин, директорның инновацион эшчәнлек һәм тышкы элемтәләр буенча урынбасары, филология фәннәре докторы А.С. Шәрипова һәм институтның гыйльми сәркатибе, филология фәннәре докторы Л.М. Гыйниятуллина катнашты. Очрашу барышында Институт эшчәнлеге, фундаменталь хезмәтләр тәкъдим ителде, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты һәм Азәрбайҗан Республикасы Чит телләр университеты арасындагы хезмәттәшлек турында сүз барды.

**2023 елның 21 маенда** Болгарда Изге Болгар җыены үтте. Бу бәйрәм Идел Болгарстанының ислам динен рәсми кабул итүенә багышлана һәм 1989 елдан бирле ел саен зурлап уздырыла. Быелгы чарада 40 меңгә якын кеше, шул исәптән, «Россия – ислам дөньясы: KazanForum» XIV Халыкара икътисади форумы кунаклары һәм XIII Бөтенроссия татар дин әһелләре форумы вәкилләре катнашты. Чараның ачылышында, катнашучыларны сәламләп, Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов Изге Болгар җыенының – бик зур тантана, Болгарның безнең нигезебез булуы, Болгар булганда, безнең телебез, динебез, гореф-гадәтләребез яшәячәге турында сөйләде.

**2023 елның 22 маенда** Мөхәммәд пәйгамбәр (с.г.в.) һәм аның сәхабәләренең ядкярләре экспозициясе ике көнгә Казанның «Кол Шәриф» мәчетенә урнаштырылды. Мөхәммәд пәйгамбәрнең һәм аның сәхабәләренең ун ядкярен беренче тапкыр Татарстанга Дагстаннан Идел буе Болгар дәүләтендә ислам дине кабул ителгән көн һәм Изге Болгар жыены уңаеннан китерделәр.

Экспозициядә Мөхәммәд (с.г.в.) пәйгамбәр, аның гаилә әгъзалары һәм сәхабәләренең кыйммәтле әйберләре тәкъдим ителде. Алар арасында Мөхәммәд пәйгамбәрнең касәсе һәм кылычы, сәхабә Билал радыйаллаһу ганһу, пәйгамбәрнең хатыны Гайшә радыйаллаһу ганһа һәм кызы Фатыйма радыйаллаһу ганһа чүлмәкләре, шулай ук аның кул тегермәне, Халид бин Әл-Вәлид радыйаллаһу ганһуның поход фляжкасы һәм Әбү Бәкер әс-Сиддыйк радыйаллаһу ганһу пычагы, Кәгъбәнең Кара ташы бар иде. Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте җитәкчелеге Дагстан мөфтие Әхмәт әфәндегә Идел буе Болгар дәүләтендә ислам дине кабул ителгән көн уңаеннан Татарстан мөселманнарына ясаган бүләк өчен

рәхмәт белдерде. Күргәзмәне Татарстан Республикасы Рәисе ярдәме белән республиканың Мәдәният министрлыгы оештырды.

**2023 елның 24 маенда** Татар әдәбияты классигы Гаяз Исхакыйның 145 еллыгы уңаеннан Мәскәүдә Татар мәдәнияте үзәгендә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан әзерләнеп нәшер ителгән яңа басмалар тәкъдим ителде. Институт галимнәре – директор урынбасары, филология фәннәре докторы О.Р. Хисамов, чагыштырма татар белеме лабораториясе мөдире, филология фәннәре кандидаты М.И. Ибраһимов, текстология бүлеге фәнни хезмәткәре Ф.Г. Фәйзуллина Институт эшчәнлеге, татар әдәбияты классиклары иҗатын өйрәнү һәм популярлаштыру буенча проектлар, Г. Исхакыйның яңа китаплары (язучының беренче тапкыр басылган көндәлекләре һәм публицистик әсәрләр җыентыгы) турында сөйләделәр. Чара Татарстан Республикасының Россия Федерациясендәге Тулы вәкаләтле вәкиллеге ярдәмендә оештырылды.

**2023 елның 25 маенда** Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында танылган этномузыколог Илгиз Кадыйров һәм фольклорчы, филология фәннәре докторы Илсөяр Закирова тарафыннан басмага әзерләнгән «Татар халкының музыкаль-эпик иҗаты. Себер ареалы» китабы тәкъдим ителде. Институт директорының фән буенча урынбасары, филология фәннәре докторы О.Р. Хисамов үзенең чыгышында татар фольклорын өйрәнүнең мөһимлеге, аның халык бердәмлеген саклаудагы әһәмияте турында сөйләде. ТӘһСИнең фәнни хезмәткәрләре, тарихчылар, музыка белгечләре, фольклорчылар, музыкантлар катнашында узган әлеге чарада басмага югары бәя бирелде, аның хәзерге укучыга халыкның музыкаль-эпик фольклорын күзалларга мөмкинлек бирүе, авторлар башкарган тикшеренүләрнең актуальлеге билгеләп үтелде.

**2023 елның 26 маенда** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә «Жанр буларак әдәбият тарихы: проблемалар һәм перспективалар» дип исемләнгән ачык дискуссия узды. Чарада Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан әзерләнәчәк биш томлык рус телле «Татар әдәбияты тарихы» проектының концепциясе каралды. Дискуссия катнаш (офлайн һәм онлайн) форматта узды. Җанлы фәнни бәхәс барышында Казан, Мәскәү, Уфа, Стәрлетамак әдәбият белгечләре тәкъдим ителгән концепциягә карата фикерләрен җиткерделәр.

**2023 елның 31 маенда** «Литературная газета»да татар язучыларының шигырьләре дөнья күрде. Газетаның «Многоязыкая лира России» рубрикасында Татарстанның халык шагыйре, Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты Ренат Харисның һәм шагыйрә, публицист Фәүзия Солтанның шигырьләре Россия Федерациясе укучыларына тәкъдим ителде.

**2023 елның 1 июнендә** Россия Федерациясе фән һәм югары белем министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе базасында Д 72.1.001.02

шифрлы кандидатлык һәм докторлык диссертацияләре яклау советы ачылу турында карар кабул ителде.

Диссертация советы түбәндәге белгечлекләр буенча эшлиячәк:

5.9.1. Рус әдәбияты һәм Россия Федерациясе халыклары әдәбияты.

5.9.4. Фольклористика.

5.9.5. Рус теле. Россия халыклары телләре.

Тулырак мәгълүмат белән Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе сайтында танышырга мөмкин: http://www.antat.ru/ru/activity/dissertatsionnyy-sovet/.

**2023 елның 4 июнендә** Ташкент шәһәрендә татар халкының милли бәйрәме – Сабантуй узды. Ташкентта ел саен оештырыла торган әлеге чара Үзбәкстанның төрле почмакларыннан үзенә меңләгән милләттәшләребезне һәм башка милләт вәкилләрен җыйды. Кунакларны рәсми рәвештә Үзбәкстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы чит илләр белән милләтара мөнәсәбәтләр һәм дустанә элемтәләр комитеты рәисе Рөстәмбәк Корбанов, Россиянең Үзбәкстандагы гадәттән тыш һәм тулы вәкаләтле илчесе Олег Мальгинов, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенең беренче урынбасары Илнур Гарипов, Башкортстан Республикасы Башлыгы Администрациясе җитәкчесенең эчке сәясәт буенча беренче урынбасары Урал Кильсенбаев сәламләде. Бәйрәмдә Татарстан Республикасыннан килгән артистлар чыгыш ясады.

**2023 елның 4 июнендә** Мәскәүнең «Октябрь» кинотеатрында татар режиссеры Илшат Рәхимбайның «Микулай» фильмы тәкъдим ителде. Картина сценарийлар авторы һәм драматург Мансур Гыйләҗевның шул исемдәге пьесасы буенча төшерелгән. Этнотриллер ил кинотеатрларында зур прокатка 22 июньдә чыкты. Проектка Россиянең Виктор Сухоруков, Иван Добронравов һәм Варвара Шмыкова кебек танылган актерлары да җәлеп ителгән, рольләрнең бер өлешен Татарстан артистлары башкара.

**2023 елның 5 июнендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтында «Татарстан Республикасы халыклары тарихында Көнбатыш Кама аръягы» темасына түгәрәк өстәл узды. Анда ТР Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты, А.Х. Халиков исемендәге Археология институты һәм Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре катнашты. Анда Көнбатыш Кама аръягының тарихи үткәне, Идел буе Болгар дәүләте тарихы һәм аның Татарстан Республикасы халыклары мәдәниятенә һәм этногенезына йогынтысы мәсьәләләре турында сүз барды.

**2023 елның 6 июнендә,** Рус теле көне һәм бөек рус шагыйре А. Пушкинның 224 еллыгы уңаеннан республикада тантаналы чаралар узды. Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин шагыйрь һәйкәленә чәчәкләр салдылар. Бәйрәм Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театрында тантаналы концерт белән дәвам итте.

**2023 елның 6 июнендә** Мәскәүдә татар әдәбияты классигы Әмирхан Еники прозасы мотивлары буенча төшерелгән «823 нче километр» фильмының премьерасы булды. Кинокартина язучының «Матурлык», «Кем җырлады?» һәм «Бер генә сәгатькә» хикәяләренә нигезләнгән. Тамашачылар шулай ук фильмны төшерүчеләр белән оештырылачак иҗади очрашуда да катнашты.

**2023 елның 7–9 июнендә** Казанда мәгариф министрларының Халыкара форумы узды. Чара Россия Мәгариф министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан оештырылды. Форумда Мисыр, Сенегал, Мали, Зимбабве, Үзәк Африка Республикасы, Сүрия Гарәп Республикасы, Берләшкән Гарәп Әмирлеге, Пакистан, Мьянма, Шри-Ланка, Куба, Венесуэла, Белоруссия, Кыргызстан, Таҗикстан, Төрекмәнстан, Казакъстан һәм башка илләрдән мәгариф министрлары катнашып, актуаль мәсьәләләр буенча фикер алышты.

**2023 елның 20 июнендә** Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә тарих һәм хәрби фәннәр докторы, профессор, Россия Федерациясенең атказанган фән хезмәткәре Мәхмүт Гәрәевнең тууына 100 ел тулу уңаеннан «Мәхмүт Гәрәев: хәрби, галим һәм җәмәгать эшлеклесе» Бөтенроссия фәнни конференциясе узды.

**2023 елның 19–30 июнендә** ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан Мордва Республикасы территориясендә татарлар күпләп яши торган Ләмбрә һәм Ромоданово районнарына комплекслы фәнни экспедиция үткәрелде. Экспедиция составында халык иҗаты (экспедиция җитәкчесе, филология фәннәре кандидаты И.И. Ямалтдинов һәм филология фәннәре кандидаты Р.Ф. Сафиуллина), лингвистика (филология фәннәре кандидаты Ә.К. Булатова), этномузыкология (Г.Г. Гыйлемҗанова), халык һөнәрчелеге һәм кәсепләре (сәнгать белеме кандидаты Л.М. Шкляева), эпиграфика (В.М. Усманов) буенча белгечләр эшләде. Кыр тикшеренүләре барышында Ләмбрә һәм Ромоданово районнары татарларының тел үзенчәлекләре, халык авыз иҗаты, традицион музыка мәдәнияте, татар халык сәнгате үрнәкләре тупланды, каберташ язмалары өйрәнелде.

**2023 елның 23 июнендә** Татарстан Республикасының Санкт-Петербург шәһәрендәге даими вәкиллегендәТатарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре катнашында «Сынлы сәнгатьтә Тукай топослары» дигән темага түгәрәк өстәл узды. Чара кысаларында Институт галимнәре – Сәнгать белеме үзәге мөдире, сәнгать фәннәре докторы Рауза Солтанова, чагыштырма татар белеме лабораториясе мөдире, филология фәннәре кандидаты Марсель Ибраһимов һәм милли мәгариф бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре, филология фәннәре докторы Ләйсән Надыршина ТӘһСИнең эш юнәлешләре, соңгы елларда дөнья күргән фәнни хезмәтләре белән таныштырдылар, өч томлык «Габдулла Тукайның тормыш һәм иҗат юлы хроникасына материаллар» хезмәтен тәкъдим иттеләр.

Научное издание

**НАУЧНЫЙ ТАТАРСТАН**

На татарском языке

Фәнни басма

**ФӘННИ ТАТАРСТАН**

2023. № 2

Бизәлеш авторы – А. Шляпкин
Компьютерда биткә салучы – Н. Абдуллина

Басарга кул куелды: 29.06.2023. Басылды: 07.07.2023.
Офсет ысулы белән басыла. Гарнитура «Times».
Кәгазь форматы 70×108 1/16.
Басма табак 12. Тираж 300 данә. Заказ

Журнал ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать
институтында әзерләнде

Редакция адресы:
420111, Казан шәһ., К. Маркс ур., 12
«Фәнни Татарстан» журналы редакциясе
Тел. (843) 590-55-93
E-mail: f_tatarstan@mail.ru

Журнал Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе
нәшриятында басылды
(нәшрият адресы – 420111, Казан шәһ., Бауман ур., 20)

Журнал бушлай таратыла